ЯНӘШӘБЕЗДӘГЕЛӘР ҺӘМ ЯКЫНДАГЫЛАР ТУРЫНДА

ТАТАРСТАН

TATARSTAN

№10 (405)
ОКТЯБРЬ 2025

1920 ЕЛДАН НӘШЕР ИТЕЛӘ

ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ БАСМА

МӨГАЛЛИМНӘРГӘ ЗАМАН БЕЛӘН БЕРГӘ АТЛАРГА НӘРСӘ БУЛЫША

4 612750 670011

№10 (405)
ОКТЯБРЬ 2025

16+

Редакция:
Адрес: 420066, Россия,
Татарстан Республикасы,
Казан, Декабристлар ур., 2,
тел. (843) 222-09-79
tatarstan@tatmedia.com

Баш мөхәррир: Татьяна Николаевна Вафина,
vafina@tatmedia.com
Шеф-редактор: Әскәр Сабиров,
sabirov@tatmedia.com
Баш мөхәррир урынбасары: Фәридә Әхмәтҗанова
Әдәби мөхәррир: Луиза Янсуар
Бүлек мөхәррирләре: Руфия Фазылова, Николай Коновалов, Евгения Чеснокова, Дмитрий Сивков
Авторлар: Олеся Бондаревская, Фәнзилә Җәүһәрова, Николай Крушинин, Михаил Рябинин, Ксения Сёмина, Наилә Хәйретдинова, Айдар Шәйхин, Әхмәт Шакиров
Фотографлар: Александр Ефремов, Анна Арахамия, Лилиана Вәлитова, Айдар Мөшәрәпов, Ната Смирнова, Әхмәт Шакиров
Дизайн-макет: Олег Бурилов
Вёрстка: Анастасия Хатыйпова
Препресс: Игорь Глушков
Корректор: Айсылу Корманова
Тышлыкта: Камил Арсланов, Казан федераль университетының юридик факультеты профессоры, гражданлык хокукы кафедрасы мөдире.
Александр Ефремов фотосы

Журнал 1920 елдан нәшер ителә
1977 елда Халыклар дуслыгы
ордены белән бүләкләнә

ММЧ исеме: ТАТАРСТАН TATARSTAN

Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәттә теркәлгән. Теркәлү таныклыгы ПИ № ФС 77 – 66045, 10.06.2016.

Тираж:
2 400 данә
Бәясе ирекле

Редакциянең язма рөхсәтеннән башка «Татарстан» журналындагы материалларны күчереп бастыру тыела. Күчереп бастырганда, журналның исемен күрсәтү мәҗбүри. Автор фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Реклама материалларының эчтәлеге өчен редакция җавап бирми.

«Татарстан» журналы шулай ук рус телендә 2350 данә тираж белән чыга.
Гомуми тираж: 4750 данә.
Реклама 16+

Журнал «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы типографиясендә басылды. Адрес: 420066, Россия, Татарстан Республикасы, Казан, Декабристлар ур., 2

Заказ №: М-2050
Басарга кул куелды: 13.10.2025
Чыгу көне: 17.10.2025

Коммерция директоры:
Рәшит Хәйретдинов,
тел.: (843) 222-09-76, +7-9600-487-900
Коммерция директоры урынбасары:
Алина Майорова,
тел.: (843) 222-09-76, +7-9033-132-741
Дистрибуция һәм трафик бүлеге җитәкчесе:
Ирина Захарова, irinamoroz10@mail.ru
Бухгалтерия:
Ольга Басаркина, тел.: (843) 222-09-80

РЕДАКЦИЯДӘН

ИҢ ЯХШЫ ДИГӘННӘР – УЛ ӘЗЕР РЕКЛАМА. БЕРНИНДИ ДӘ ЧЫГЫМНАРСЫЗ

Кемгәдер «Татарстан» журналының әлеге саны реклама белән артык шыплап тулган кебек тоелыр. Әмма без бу шикләрегезне куып таратырга киңәш итәбез. Алдыбызда ике бик шәп октябрь вакыйгасы – Укытучылар көне һәм «Киләчәк юнәлешләре» Туристик форумы. Беренчесе – мәктәп тормышына күмелер, анда балаларыбызны нинди яңача, заманча алымнар белән укытуларын тирәнрәк белер өчен менә дигән мөмкинлек. Икенчесе – җаныгыз теләгәнчә сәяхәт итәргә өйрәнер өчен бер форсат. Якын һәм ерак киләчәккә туристик маршрутларны сайлап кую, нәрсә, начармы әллә?

Журналның бу санында урын алган әлеге ике вакыйга каһарманнарының бүлешер нәрсәләре җитәрлек: бүгенге мәгариф системасындагы алгарышлар, Татарстанның бөек шәһәрләре тарихыннан гаҗәеп мизгелләр... Ә алар, әйтергә кирәк, үз заманында хәтта Лондон белән Париждан да зуррак калалар булган...

Озын сүзнең кыскасы, «Татарстан» һәрвакыттагыча республиканың визит карточкасы ул: иң яхшы тәҗрибәләр, үрнәкләр һәм казанышлар – безнең уч төбендә. Ә «иң яхшы» дигәннәр – үзеннән-үзе әзер реклама! Бернинди дә чыгымнарсыз!

Сезнең октябрь редакциягез

Редакция советы:
АЛЕКСАНДРОВСКАЯ Ирина Алексеевна
ӘХМӘТШИН Равил Кәлимуллович
БЕЛЯКОВ Роман Юрьевич
БИКЧӘНТӘЕВ Фәрит Рәфкатович
БОЛЬШАКОВ Андрей Георгиевич
ВӘЛИЕВА Зилә Рәхимҗановна
ГАЛИЕВ Марат Гадыевич
СӘЛАХОВ Мәгъзүм Хәлимуллович
ФАЗЛЫЕВА Ләйлә Ринатовна
ФӘЙЗУЛЛИН Равил Габдрахманович
ХӘКИМОВ Рафаэль Сибгатович
ХОМЕНКО Вадим Васильевич

Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла

Басма Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча федераль агентлык ярдәмендә нәшер ителә

ТАТ МЕДИА

Гамәлгә куючы: «ТАТМЕДИА» АҖ
Нәшер итүче: «ТАТМЕДИА» АҖ
Адрес: 420097, Россия,
Татарстан Республикасы, Казан,
Академическая ур., 2

«Татарстан» журналына ТРның барлык элемтә бүлекләрендә язылырга мөмкин:
Индекс **П2381** – татар телендә ярты елга
Индекс **ПА468** – татар телендә бер елга

Индекс **П2378** – рус телендә ярты елга
Индекс **ПА471** – рус телендә бер елга

2026 елның ярты еллыгына ТР буенча язылу бәясе:
1998 сум 00 тиен китереп бирешле,
1939 сум 20 тиен соратып алганда.
2026 елга ТР буенча язылу бәясе:
3995 сум 90 тиен китереп бирешле,
3878 сум 29 тиен соратып алганда.

«Татарстан» журналына РФ буенча онлайн-язылу:
Индекс **П7077** – татар телендә
Индекс **П7076** – рус телендә

«ТАТАРСТАН» ЖУРНАЛЫНА 104 ЯШЬ

ТАТАРСТАННЫҢ 100 җәүһәре

барытик ТАТАРСТАНДА

ТЫЙНАК ИЛЬИЧ

Татарстан башкаласының төп мәйданында басып торган Ильич хәзергедән өч мәртәбә зуррак була алган икән. Бу хакта бик азлар белә. Ерак 1940 елда хөкүмәт Татарстан башкаласында эшче-крестьяннарның якты тормышына нигез салучыга лаеклы һәйкәл куярга ниятли. Унбиш метрлы гигант Ленинны урнаштыру өчен өч мәйданчык карала. Беренчесе – хәзер Мулланур Вахитов һәйкәле калкып торган тау итәге. Икенчесе – 1 Май мәйданы. Өченчесе – бүгенге көндә Министрлар Кабинеты бинасы урнашкан урын.

Бу колачлы планнарны чынга ашырырга сугыш комачаулый. Әмма шулай да расланган проект буенча 1951 елда бөек юлбашчының алгаем зур фигурасын ясарга заказны скульптор Вениамин Пинчук ала. Әмма ике ел узгач, заказчы* контрактны өзә, гәрчә эшнең бер өлеше инде башкарылган булса да. Скульптор Петр Яцыно эшләгән сын Сталин премиясенә лаек дип табылгач, артык чыгымнар нигә кирәк? Шулай итеп, Казанның Ирек мәйданында инде безнең ничә буынга бик яхшы таныш булган Ильич һәйкәле урнаша**. Яцыно әзерләгән Ильич әллә никадәр гигант түгел һәм бу, әйтергә кирәк, аны юлбашчының башка сыннарыннан шактый аерып тора. Бәлки, шуңа күрә дә монументның язмышы башка дистәләгән бронза Ильичларга караганда күпкә бәхетлерәктер?

© «Татарстан» журналы

** СССР Министрлар Советы каршындагы Сәнгать эшләре буенча комитет.*
*** Ялтада да нәкъ шундый ук сын тора.*

WWW.PROTATARSTAN.RU

ЭЧТӘЛЕК

акыллы гамәлләр

4. Көндәшләргә форсат калдырмыйча
Татарстанда сайлауларның нәтиҗәсен нәрсә билгеләде

6. Бәя артыннан куып
Ни өчен кырларга соя һәм майлы җитен утыртыла

14. «Физика-математика буенча алга китеш»
Ул мәгарифне ничек үзгәртә

18. Хокук һәм тәҗрибә
Ни өчен вузда укыту практика белән бәйләнергә тиеш

22. Барлык телләр – туган тел кебек
Кайда полиглотлар үстерәләр

40. Җир шарын колачлап буламы? Һичшиксез!
Хыялланырга ничек өйрәтергә

46. Игелеклелек королевасы
Ул нинди социаль әһәмиятле бизнес оештыра

игелекле эшләр

54. Фронт сызыгында
Лисичанск һәм Рубежное шәһәрләре ничек яши

67. Пирамидалар чорына караган пот
Алексеевскоедагы музейда нинди раритетны күрергә мөмкин

70. Гасырлар аша оештырылган сәфәр
XIII гасырдагы кайсы шәһәр Париждан зуррак булган

мәңгелек кыйммәтләр

76. Онытылмас исемнәр
Габдулла Зөлкарнәев кем булган

81. Сәнгать дөньясы
Ни өчен Альберт Әсәдуллин Татарстанга сирәк кайта

86. Китап киштәсе
Нобель –2025 кемнеке

88. Татарстан авыллары
Касай авылы ничек яши

96. Казанның агач архитектура һәйкәлләре
Исәнбаевлар йорты ничек сакланган

Тулырак мәгълүмат түбәндәге сайтта:
protatarstan.ru

Фото: MarSaf

Акыллы гамәлләр

25.09

Илсур Метшин, Казан мэры, – БРИКС Яшүсмерләр фестивалендә катнашучы илләр вәкилләре белән очрашуда:

– Һәрбер ил, аның мәдәнияте белән теле – кабатланмас, һәркайсының нинди дә булса көчле ягы бар. Бу – искиткеч! Без берберебездән бик күпне өйрәнә алабыз, дигән сүз. Мәсәлән, бер илдә кешеләр уникаль робот җыйган, ди, икенчесендә универсаль дару уйлап тапкан, өченчесендә югары технологияле йортлар торгызырга өйрәнгән. Без бу белемнәребез һәм осталыкларыбыз белән уртаклаша алабыз, димәк, бергәләп дөньяны яхшыртуга йөз тотабыз.

Игелекле эшләр

17.09

Евгений Маргулис, җырчы, җырлар авторы, гитарада уйнау остасы, – Казанда «Аксенов-фест» әдәби-музыкаль фестивале ачылышында:

– Без бу фестивальне 2007 елда ачтык, ул Василий Павловичның 75 еллыгы уңае белән оештырылган иде. Күпләгән уртак дусларыбыз җыелды, без җырлаштык та, биедек тә. Дөресен генә әйткәндә, ул җыенның шушындый киң колач аласын һәм ел да уза торган масштаблы акциягә әйләнәсен башыма да китермәдем. Безне – беренче булып аны ачып җибәргән кешеләрне искә алып чакырулары күңелне җылытты. Зур рәхмәт! Шәһәр дә матур, фестиваль дә, барысы да – бик югары дәрәҗәдә!

Мәңгелек кыйммәтләр

12.09

Ольга Любимова, Россия Федерациясенең мәдәният министры, – 2026 елда «Казан – ислам дөньясының мәдәни башкаласы» программасын әзерләү һәм уздыру буенча оештырылган комитет утырышында:

– Казан чын мәгънәсендә Россиянең горурлыгына гына әйләнеп калмыйча, дөньядагы барлык мөселманнар тартылган урын булып та тәгаенләнә. Европа белән Азия кисешкән ноктада урнашкан бу шәһәр – ислам һәм православие традицияләрен гармонияле рәвештә яшәтә ала торган үзәк.

Фото: tatar-inform.ru

игелекле эшләр

акыллы гамәлләр

мәңгелек кыйммәтләр

Бу санда тәкъдим итәбез:

Республика программалары нәтиҗәләре сайлауларда **ничек** булыша

Татарстан терлекчелегенә **ни өчен** бернинди дә санкцияләр куркыныч түгел

Матди стимуллар ярдәмендә бөек алгарышларга **ничек** ирешергә

Ясалма фәһем **ни өчен** яхшы юристны алыштыра алмый

Социаль әһәмияткә ия бизнес балаларга **ничек** булыша

ТР РӘИСЕ: «ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ КҮПМИЛЛӘТЛЕ ХАЛКЫНА ТУГРЫЛЫКЛЫ ХЕЗМӘТ ИТӘРГӘ ТАНТАНАЛЫ ТӨСТӘ АНТ ИТӘМ»

Михаил Рябинин

Күптән түгел генә республика халкы Татарстан Рәисен сайлады. Әлеге сайлауларга характеристика биргәндә, аның нәтиҗәләренең күпмедер дәрәҗәдә алдан билгеле булуын әйтергә кирәктер. Рөстәм Миңнехановның республика башлыгы вазыйфасына бердәнбер реаль кандидат булуына хәтта аның оппонентлары да шикләнмәгәндер, гәрчә сайлау бюллетеньнәрендә алар дүртәү булса да.

Сайлауларга килгән татарстанлыларның үз лидерлары өчен биргән 88,09 процент тавышы күптәннән де-факто булганны де-юре терки: Рөстәм Миңнеханов – республика халкының күпчелеге ышаныч белдергән җитәкче. 88,09 процент – 1,96 миллионнан артык тавыш дигән сүз. Исегезгә төшерәбез, сайлауларда барлыгы 2,23 миллионнан артык кеше катнашты.

КУРС ЭЛЕККЕЧӘ – АЛГА

Рөстәм Миңнехановның бер генә көндәше дә хәтта биш процент тавыш та җыя алмады (икенче урында – КПРФның Татарстан

Фото: tatarstan.ru

бүлеге лидеры Хафиз Миргалимов, 4,97 процент – бик тыйнак сан). Бу чын көндәшлек булмавын раслады гына. Оппозиция, гадәттә, килмәгәннәр, бәлки, аның өчен тавыш биргән булырлар иде, дип әйтергә ярата, әмма әлеге дежур аргумент та сайлаучылар тарафыннан кире кагылды: сайлауларда 75,85 процент кеше катнашты. Шуңа күрә бу очракта инде «бәлки» кебек шикле сүзләр бөтенләй урынсыз.

Сайлауларга килүчеләрнең санын бу юлы Рөстәм Миңнеханов хәтта үзе дә билгеләп үтте. Сайлау участоклары ябылганнан соң, «Казан» гаилә үзәге янында сәхнәгә чыгарга әзерләнгәндә һәм, мөгаен, инде экзитпол нәтиҗәләрен белеп, ул сайлаучыларның «бик югары» активлыгына басым ясады. Чыннан да татарстанлыларга сайлауларга килергә берни комачаулый алмады: алар, һава торышының уңай булуына да карамастан, бакча-дача мәшәкатьләрен, табигатьтә ял итүләрне артка чигереп, үз тавышларын бирергә дип, сайлау участокларына килде. Гражданнарның югары сәяси аңына тиешле бәяне биреп, без бу юлы төгәл кем һәм нәрсә өчен тавыш бирү хәлиткеч фактор булды, дип фаразларга җөрьәт итәбез. Төбәгебезнең киләчәге, аның алдагы елларга исәпләнгән курсы турында сүз барганда, әлбәттә, битараф калып булмый.

БЕРЕНЧЕ РӘИС

Биш ел элек сентябрьдә ТР Президенты сайланды. Быел республика беренче тапкыр Татарстан Рәисен сайлады. Исегезгә төшерәбез, югары вазыйфаи затның атамасы федераль законнар нигезендә үзгәртелде. Ул закон буенча РФндә бары тик бер генә Президент булырга мөмкин. Конституциягә тиешле төзәтмәләрне кабул итү вакытында ТР Дәүләт Советында нинди бәхәсләр баруын истә тотып, кайбер экспертлар, атаманы алыштыру интрига кертергә һәм реаль кандидат өчен тавышларны югалтуга китерергә мөмкин, дип фаразлап карады. Мондый хәл булмады, алай гына да түгел, биш ел элек булган сайлаулар белән чагыштырганда, Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов өчен бу юлы катнашучыларның күбрәк проценты тавыш бирде.

Көтелмәгән хәлме? Юктыр, дип уйлыйм. Инде өч ел чамасы республиканың иң югары вазыйфаи заты – Татарстан Рәисе. Бу сайлаучылар өчен гадәтигә әйләнде, ул хакта бәхәсләр үткәндә калды. Ә иң мөһиме, тормыш тәҗрибәсе шуны күрсәтә: теләсә нинди вазыйфа, хәтта иң югары дәрәҗәдәгесе дә, яңгыравыклы исем белән түгел, аны биләгән зат башкарган эшләр белән бәяләнә. Һәрвакыт. Бу Рөстәм Миңнехановның 14 сентябрьдә берсүзсез җиңүен аңларга да бик яхшы ярдәм итә.

Ул үзе сайлауларга болай дип нәтиҗә ясады: «Бу республика программалары эшенең нәтиҗәседер, дип уйлыйм. Сайлаучы республикада уңай якларның күбрәк булуын күрә». Төгәлрәк әйткәндә, сайлаучы нәтиҗәләрне генә түгел, ә аларга ирешү өчен Татарстан Рәисе куйган тырышлыкны да күрә белә.

Ә МӘСКӘҮ ҺӘРВАКЫТ ЯНӘШӘДӘ БУЛЫР

Асылда сайлау алды ае моны тагын бер мәртәбә раслады гына. Татарстан Республикасы Рәисенең гадәттән тыш киеренке графигы бу айда Россия Федерациясе Премьер-министры һәм федераль министрлар, Россиянең һәм чит илләрнең эре компанияләре топ-менеджерлары белән эшлекле очрашуларны, Татарстанда һәм чит илләрдә халыкара форумнарда катнашуны, республика шәһәрләре һәм районнары буенча дистәләгән сәфәрне үз эченә алды. Чистай районында бәрәңге эшкәртү заводы һәм Арчада, Баулыда, Кукмарада, Менделеевскида ябык футбол манежлары ачылу да каралган иде ул графикта. Тагын Апас районында булачак кошчылык фабрикасының төзелеш мәйданчыгын карау һәм «Безнең ишегалды» программасының үтәлешен бәяләү. Республика картасында пәйда булган яңа иҗтимагый киңлекләрне тикшерү һәм МХОда катнашучылар белән аларның гаиләләре өчен торак программасын эшләтеп җибәрү – ТР Рәисе катнашында бер ай эчендә узган чара һәм вакыйгаларның шактый зур исемлеге бер биткә генә сыеп бетми. Реаль эшләр һәм гамәлләрнең мондый исемлеге теләсә нинди PR-акцияләргә караганда нәтиҗәлерәк булуын әйтеп торырга кирәкме икән?

ТЕЛӘСӘ НИНДИ ВАЗЫЙФА, ХӘТТА ИҢ ЮГАРЫ ДӘРӘҖӘДӘГЕСЕ ДӘ, ЯҢГЫРАВЫКЛЫ ИСЕМ БЕЛӘН ТҮГЕЛ, АНЫ БИЛӘГӘН ЗАТ БАШКАРГАН ЭШЛӘР БЕЛӘН БӘЯЛӘНӘ. ҺӘРВАКЫТ. БУ РӨСТӘМ МИҢНЕХАНОВНЫҢ 14 СЕНТЯБРЬДӘ БЕРСҮЗСЕЗ ҖИҢҮЕН АҢЛАРГА БИК ЯХШЫ ЯРДӘМ ИТӘ.

2020 елда Рөстәм Миңнеханов өчен 1, 93 млн татарстанлы тавыш биргән, биш елдан соң – 1,96 млннан артык. Бүгенге кырыс чынбарлык шартларында югары вазыйфаи затка ышанычның артуы, килешәсездер, бик үтемле күрсәткеч. РФ субъектларының сайланган башлыклары белән очрашуда Россия Президентының, Татарстан Рәисенә мөрәҗәгать итеп, яхшы теләкләр теләвен шулай ук аңлатып тору кирәкмидер, дип уйлыйм.

«Сез республикада чын-чынлап ихтирам казанган, бай тәҗрибәгә ия кеше, – диде Владимир Путин Рөстәм Миңнехановка. – Мин сезгә ихлас күңелдән уңышлар телим. Куелган барлык бурычлар да хәл ителәчәк, дип ышанам. Ә Мәскәү, әлбәттә, һәрвакыт янәшәдә булачак, куркәм башлангычларга ярдәм итәчәк. Сез моны беләсез, без сезнең белән даими элемтәдә торабыз».

Фото: tatar-inform.ru, ТР Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы матбугат хезмәтеннән алынды

МАРАТ ҖӘББАРОВ:

БИШ ЕЛ ЭЧЕНДӘ АВЫЛ ХУҖАЛЫГЫНДА ХЕЗМӘТ ҖИТЕШТЕРҮЧӘНЛЕГЕ 2,5 ТАПКЫР АРТТЫ

Әхмәт Шакиров

Бу ел аграрийларга нинди сюрпризлар алып килде, һәм алар продукциянең сыйфатына ничек йогынты ясады? Нинди культураларны үстерү отышлы, ә кайсылары бик керемле түгел? Шикәргә бәя үзгәрерме? Ни өчен терлекчеләргә бернинди санкцияләр дә куркыныч түгел? Әлеге һәм башка сорауларга Премьер-министр урынбасары – Татарстан авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры җавап бирә.

УҢЫШКА БӘЙЛЕ ФАРАЗЛАР ТУРЫНДА

– Быел табигать аграрийларның ныклыгын тагын бер кат сынады. Коеп яуган яңгырлар бөртеклеләр уңышына тәэсир иттеме?

– Чыннан да, явым-төшемнәр урып-җыюны катлауландырды, аны оптималь срокларда төгәлләргә ирек бирмәде. Унҗиде метеостанциянең унбере туфракның артык дымлануын күрсәтте, шуның аркасында техника, батып калып, хәтта кырга да керә алмады. Без урып-җыюга керешкәндә, Татарстан буенча бөртеклеләрнең уртача уңышы 45 центнер чамасы иде, бүгенгә ул 37 центнерны тәшкил итте. Әлбәттә, урып-җыюның башында югарырак уңыш бирә торган культуралар – көзге бодай, арпа суктырыла, әмма шуңа да карамастан югалтулар шактый.

– Экстремаль һава шартлары ашлык сыйфатына нинди йогынты ясады?

– Дәүләт мониторингы нәтиҗәләре күрсәткәнчә, быелгы бодайның 14 проценты – өченче класслы. Былтыр бөртеклеләрнең 27 про-

центы өченче класска караган иде. Дымлы һава торышы үзен сиздерде – ул урып-җыю вакытында гына түгел, бөтен вегетация чоры дәвамында диярлек шундый булды.

– Ашлыкка бәяләр инде берничә ел түбән булып кала. Нишләргә?

– Ни кызганыч, быел да бәяләр игенчеләрне сөендерми. Авыл хуҗалыгы җитештерүчеләренең ала алмый калган керемнәре дәүләт ярдәме хисабына өлешчә компенсацияләнә. Авыл хуҗалыгы министрлыгы чәчүлек орлык, ашламалар сатып алуда, ашлык сатуда булыша, аграрийларга ягулык-майлау материалларын ташламалы бәяләрдән алу мөмкинлеге бирелә. Ашлыкны урып-җыюдан соң ук сатмаска киңәш итәбез, чөнки ул чакта бәяләр гадәттә түбән була. Соңрак, уңайрак вакытта сату өчен, ашлыкны саклауга салу яхшырак. Шулай ук ашлыкны терлекчелек продукциясе алыр өчен кулланырга тәкъдим итәбез, аларга уңышлырак сатып алу бәяләре урнашты.

– Әгәр чыгымнарны аклап булмый икән, бездә шул ук бодайны алай күп үстерүнең мәгънәсе бармы соң?

– Шул сәбәпле чәчүлек мәйданнары акрынлап югарырак керемле культуралар ягына үзгәрә дә. Мәсәлән, көнбагыш, соя, майлы җитен кебекләргә өстенлек бирелә. Быел көнбагыш мәйданнары 86 мең гектарга артты һәм 300 мең гектарга якынны тәшкил итте, сояныкы – 16 мең гектарга (62 мең гектар), майлы җитеннеке, 20 мең гектарга артып, 58 мең гектарга җитте. 2024 ел йомгаклары буенча иң табышлы культуралар – шикәр чөгендере һәм көнбагыш. Быел бу исемлеккә көзге рапс, соя һәм майлы җитен керәчәк.

– Авыл хуҗалыгы тармагында хезмәт җитештерүчәнлеге һаман да әллә ни югары түгел. Аның үсешен тәэмин итү өчен бездә нинди резервлар бар?

– Узган биш елда авыл хуҗалыгы оешмаларында хезмәт җитештерүчәнлеге 2,5 тапкыр артты һәм 2024 ел йомгаклары буенча бер хезмәткәргә 5,1 млн сумны тәшкил итте. Болар барысы да – предприятиеләрнең эчке резервларны табуы һәм куллануы, яңа технологияләр һәм цифрлы продуктлар кертүе, техник модернизация ясавы нәтиҗәләре. Авыл хуҗалыгы комплексының техник яктан җиһазландырылуы үсә, яңа терлекчелек объектлары сафка баса. Хезмәт җитештерүчәнлегенең алга таба үсешен югары нәтиҗә бирә торган алдынгы технологияләрне, пилотсыз техниканы, яңа селекция казанышларын актив куллану, тармакны цифрлаштыру тәэмин итәчәк. Шуны да билгеләп үтәсем килә: безнең предприятиеләр «Нәтиҗәле һәм көндәшлеккә сәләтле икътисад» милли проектының «Хезмәт җитештерүчәнлеге» федераль проектында актив катнаша.

Хәзерге көндә 119 потенциаль катнашучыдан 74 предприятие сакчыл җитештерү чараларын гамәлгә кертү проектларын тормышка ашырды яки ашырып килә. Алар федераль һәм төбәк компетенция үзәкләре ярдәме белән уңай икътисади нәтиҗәләргә ирешә.

ЭКСПОРТ, БӘЯЛӘР, ИХТЫЯҖ ҺӘМ ТӘКЪДИМ ТУРЫНДА

– Татарстан аграрийларының нинди продукциясенә бүген чит ил базарларында ихтыяҗ зур?

– Республика көнбагыш һәм рапс маен, сөт һәм үсемлек мае (соус) продукцияләрен экспортка актив озата. 14 сентябрьгә Татарстан агросәнәгать комплексы продукциясе экспорты күләме 295,5 млн АКШ долларын тәшкил итте. Бу, узган елның шул ук чоры белән чагыштырганда, 13,5 млн долларга күбрәк. Төп сатып алучылар исемлегендә – Кытай, Һиндстан, Иран, Белоруссия кебек дәүләтләр. Соңгы 5 ел эчендә әлеге күрсәткеч 2 млрд АКШ долларыннан артып китте.

– Соңгы елларда чит илләргә хәләл продукция сатуның шактый артуы күренә. Бу ел да искәрмә түгелдер?

– 2024 елда хәләл продукция экспорты 14 млн АКШ долларын тәшкил итте. Быел бу сан сизелерлек артты.

26 сентябрьгә Татарстаннан инде 24,5 млн долларлык хәләл продукция экспортка киткән. Киләчәктә чит илләргә сатуны үстерү перспективасы начар булмаган продукцияләр исемлегенә бөртеклеләр һәм аларны эшкәртү продуктлары кергәнен әйтеп үтим.

– Республика төп азык-төлек продуктлары белән ни дәрәҗәдә тәэмин ителгән?

– 2024 ел йомгаклары буенча республика бөртекле ашлык белән 118 процентка, мөгезле эре терлек ите белән – 121, сөт белән – 161, бәрәңге белән – 162, шикәр белән – 260, үсемлек мае белән 1216 процентка тәэмин ителгән. Шуны да истә тотарга кирәк: без илдәге бердәм базар мохитендә яшибез, шуңа күрә тулаем РФ буенча нинди дә продукциянең җитешмәве яки артыклыгы, әлбәттә, безнең бәяләрдә дә чагыла. Мәсәлән, быелтыр бәрәңге белән шулай булды. Республикада бәрәңге белән тәэмин ителеш дәрәҗәсе, Татарстан Республикасында яшәүче һәр кешегә исәпләгәндә, нормадан 150 процентка артып китте, әмма илдә икенче икмәк кытлыгы бәяләрнең кискен күтәрелүенә китерде. Ә инде хәзер, күргәнегезчә, бәяләр узган еллар дәрәҗәсенә кайтты.

Шуны да телгә алып китим: ваклап сату бәяләренең даими мониторин-

гы нигезендә ачыкланганча, «борщ җыелмасы» продуктларына бәяләр октябрьдән үсә башлый, һәм ул процесс киләсе елның июленә кадәр дәвам итә. Бу хәл базарда тәкъдимнең кимүе, шулай ук товарны саклау һәм сортларга аеру чыгымнары аркасында, продукциянең үзкыйммәте арту белән бәйле.

Быел Татарстанда бәрәңге һәм яшелчәләр уңышы бер миллион тонна дәрәҗәсендә булыр, дип көтелә.

– Сөт, атланмай, сөт продуктлары... Бу товарларга бәяләр бер ел эчендә бик нык артты. Быел да бәяләр үйнарга мөмкинме?

– Энергия ресурслары, логистика тарифларының һәм савып алынган чимал сөт хакының периодик рәвештә күтәрелүе бәяләр артуның төп факторы булып тора. Халыкның кереме арту һәм ваклап сату бәяләренең уртача динамикасы үсү фонында республикада, тулаем Россия күләмендә ихтыяҗның югары булуы да үз өлешен кертә. Тагын бер фактор – сөт продукциясенең аерым төрләрен экспортка озату күләмнәре арту; пальма маен һәм башка алмаштыргыч матдәләрне куллану тыелу сәбәпле, атланмайга ихтыяҗ үсү дә йогынты ясый.

Исегезгә төшереп китим, республикабыз Россия Федерациясендә сөт җитештерүдә иң алдынгы төбәкләрдән, без май һәм башка сөт продуктлары белән тулысынча тәэмин ителгән.

Халыкны авыл хуҗалыгы продукциясе һәм көндәлек азык-төлек товарлары белән тәэмин итү максатларында ел саен яз һәм көз айларында авыл хуҗалыгы ярминкәләре үткәрелә, анда бәяләр, кагыйдә буларак, уртача сату бәяләреннән 30 процентка кадәр түбәнрәк.

– Башка товарлардан аермалы буларак, шикәргә бәяләр ел буе тотрыклы калды. Бу елга фаразларыгыз ниндирәк?

– 2024 ел нәтиҗәләре буенча шикәр белән 260 процентка тәэмин ителдек. Быел Татарстанда 2,3 миллион тонна шикәр чөгендере җыеп алу планлаштырыла. Бу татарстанлыларны үзебездә җитештергән шикәр белән тулысынча тәэмин итү өчен җитәрлек, шуңа күрә бәяләрнең кинәт үсеп китешенә сәбәпләр юк. Сүз уңаеннан, традицион көзге авыл хуҗалыгы ярминкәләрендә аның хакы уртача базар бәясеннән түбәнрәк, хәзерге көндә килограммы 55 сумга сатыла.

ТЕРЛЕКЧЕЛЕК, САНКЦИЯЛӘР ҺӘМ ТИРӘНТЕН ЭШКӘРТҮ ПЕРСПЕКТИВАЛАРЫ ТУРЫНДА

– Татарстан – сөт җитештерүдә лидер. Бу тармакны алга таба үстерү өчен резервлар бармы?

– Терлекчелек – республика авыл хуҗалыгының иң алга киткән тармагы, безнең горурлыгыбыз. Ләкин иң яхшылардан булыр өчен даими камилләшергә кирәк. Быел Татарстанда 23 мең баш терлеккә исәпләнгән сөтчелек комплекслары төзү белән бәйле тугыз зур проект гамәлгә ашырыла. Инвестицияләрнең гомуми күләме 14 миллиард сумны тәшкил итә. Татарстан сөт җитештерүдә лидерлыкны саклап кала. Бер сыердан 8,7 мең килограмм сөт савып алыныр дип күзаллыйбыз. 2025 елда Татарстан Республикасында барлыгы 2 млн 313 мең тонна сөт җитештерелер дип көтелә.

– Шәхси хуҗалыкларда терлекләрнең баш саны, акрын булса да, кимүгә бара. Алмашка нәрсә булачак?

– Бу кимү сөтчелек тармагында нәсел-селекция эшен камилләштерү, югары продуктив терлекләр булдыру белән компенсацияләнә. Авыл хуҗалыгы җитештерүчеләре савым сыерларын яңарта, нәселле таналар сатып алалар, шуңа күрә сөт җитештерү күләмнәре дә арта.

Терлекләрнең баш саны кимү гомумдөнья тенденциясе икәнен дә искәртим. Бүген АКШ, Канада һәм Европада сөтчелек фермерлары, 70 ел элек булганга караганда, 60 поцентка күбрәк сөт җитештерә, ә аларның терлек көтүләре уртача өч тапкырга кимрәк.

– Санкцияләр терлекчелек тармагына ничек тәэсир итә? Бүгенге шартларда югары продуктив токымнар һәм технологияләр сатып алу мөмкин эшме?

– Баштагы мәлдә санкцияләр аркасында чит илдән нәселле терлекләр кайтарту кыенлашты. Әмма Россиядә, аерым алганда, Татарстанда, яхшы токымлы мөгезле эре терлекләр сатып алуга ихтыяҗны тәэмин итү өчен, нәселле терлек үрчетү белән шөгыльләнә торган хуҗалыклар җитәрлек. Моннан биш ел элек республикада нәселле терлек сатып алганда импорт өлеше 46 процент тәшкил итә иде, ә өченче ел һәм былтыр бу сан күзгә күренеп

кимеде – 25 процент (2023 ел) һәм 10 процент (2024 ел).

Хәзерге шартларда ил җитәкчелеге импортны алыштыру сәясәтенә йөз тота. Нәселле терлекчелектә эш терлекләрнең нәселлелек кыйммәтен анализлауга, аларның генетик потенциалын бәяләү һәм продуктивлыгын алга таба да яхшырту өчен төгәл белешмәләр базасын булдыруга һәм үстерүгә юнәлдерелгән. Хуҗалыклар нәсел-селекция эшен үз көтүләрендә алып бара, терлекләрнең баш санын арттыралар, шуның хисабына терлекләрне читтән кертү дә кими.

Токымлы терлек үрчетү өлкәсе турында сүз барганда, республикада «Элита» нәселле терлек предприятиесе эшләвен дә билгеләп үтәргә була. Ул – Россиядә голштин, гереформ, абердин-ангус, симменталь һәм башка токымнар, шул исәптән чит ил селекциясе нәсел үгезләренең орлыгын җитештерү, туңдыру һәм сату белән шөгыльләнә торган алдынгы заманча хуҗалык.

– Үзебездә нәселле терлекчелек тармагын үстерү өчен ниләр эшләнә?

– Хәзерге көндә Татарстанда терлекчелектә гамәли генетика белән шөгыльләнәчәк Агробиотехнопарк төзү проекты гамәлгә ашырыла. Әлеге проектилебез терлекчелеге өчен стратегик әһәмияткә ия, чөнки ул азык-төлек иминлеген ныгыту һәм агросәнәгать комплексының фәнни-техник потенциалын үстерү мәсьәләсе белән турыдан-туры бәйле.

Заманча генетик лаборатория, мәгариф кластеры һәм инновацион мәйданчыклар булдыру селекция эшен яңа дәрәҗәгә күтәреп кенә калмыйча, алдынгы технологияләрне үзләштергән белгечләр әзерләү өчен дә шартлар тудырырга мөмкинлек бирәчәк. Алдынгы биотехнологик ысулларны гамәлгә кертү терлекләрнең продуктивлыгын һәм чыдамлыгын көчәйтү, нәтиҗәдә, җитештерү чыгымнарын киметү һәм җитештерелә торган продукция күләмнәрен зурайту юнәлешендә эш алып барырга юл ачачак.

Дөньякүләм дәрәҗәдәге фәнни һәм селекция үзәкләренә ия алга киткән илләрдә (АКШ, Канада, Норвегия, Нидерландлар, Германия, Австралия, Франция һәм Кытай) геном селекциясе 2010 елдан терлекләрнең нәселлелек сыйфатларын бәяләүнең рәсми системасына әверелде. Бөекбританиядә белгечләр геном бәяләмәсе төрле дәрәҗәдә булган сыерларның генетик потенциалын һәм икътисадый нәтиҗәлелеген чагыштырганнар. Геном бәясе түбән булган (25 процент) көтүләр белән чагыштырганда, югары дәрәҗәле (75 проценттан башлап) көтүләрдә табыш 1 баш терлеккә 1,5 тапкырга күбрәк булып чыккан. Бу ысул генетик яктан бик көчле хайваннарны бик кечкенә чакта ук ачыкларга мөмкинлек бирә, селекция нәтиҗәсен 2 тапкырга тизләтә һәм савым сыерларының нәселдән килгән авыруларын ачыклау исәбенә керемне арттыра.

– Киләсе елга терлекчеләр алдында нинди бурычлар тора?

– Сөт җитештерүне 2 млн 358 мең тоннага җиткерү планлаштырыла. Терлекчеләр, быелгы белән чагыштырганда, өч процент дәрәҗәсендәге үсешкә ирешергә уйлый. Бу өстәмә 70 мең тоннадан артык сөт дигән сүз. Сугымга терлек һәм кош-корт җитештерү тереләй үлчәм хисабында 3,5 процентка артыр, дип фаразлана. Бу өстәмә 528 мең тонна бирәчәк. Йомырка 50,5 млн данәгә күбрәк җитештереләчәк, нәтиҗәдә барлыгы 1 млрд 658 млн данәгә җитәчәк.

– Гадәттәгечә, авыл хуҗалыгында игенчеләр һәм терлекчеләр түгел, ә продукция эшкәртүчеләр күбрәк акча эшли. Авыл хуҗалыгы продукциясен эшкәртү тармагы ничек үсә? Бу юнәлештә төп тенденцияләр нинди?

– Татарстан үзен төп азык-төлек продуктлары белән тулысынча тәэмин итә һәм авыл хуҗалыгы продукциясен уңышлы рәвештә Россия төбәкләренә экспортка озата. Продукциягә ихтыяҗ зур булу аграрийларга чималны республика территориясендә тирәнтен эшкәртү кирәклеген күрсәтеп тора. Бүген безнең эшкәртү сәнәгатендә 1000 нән артык предприятие исәпләнә. Якын киләчәктә ашлыкны һәм яшелчәләрне тирәнтен эшкәртү, шулай ук өстәлгән бәясе югары булган яңа продуктлар җитештерү планлаштырыла. Моңа ачык мисал – агымдагы елның августында эшләп киткән «Чисто Фри» заводы, ул бәрәңге эшкәртү һәм консервлау белән шөгыльләнәчәк.

АВЫЛ ЯШӘСЕН ДИП ЭШЛИБЕЗ

Руфия Фазылова

Ун-унбиш ел эчендә авыл хуҗалыгы тармагы шундый зур тизлек белән үсте ки, шаккатасың. Сыерларны бүген роботлар сава, ат арбасына төяп, азык та ташыйсы юк. Күпме сөт биргәненә карап, робот сыерга үзе азыкны әзерләп бирә. Ә техника нинди уңайлы! Бүген механизатор эшкә ак күлмәктән килә ала, чөнки салон эченә тузан керми. Монда да робот ярдәмгә килә: экранга ул бөтен мәгълүматны чыгара. Элек трактор, комбайн йөртүчеләр утыз градус эсседә пешеп йөрсә, бүген һәр техникада кондиционер тора. Әмма шулай булса да, авыл хуҗалыгы өлкәсендә эшләргә кеше табу авыр. Ни өчен? Әтнә районы Түбән Бәрәскә авылындагы «Ленин исемендәге нәселле терлек заводы» авыл хуҗалыгы җитештерү кооперативында бу сорауга җавапны беләләр.

«КӨН САЕН ИЛЛЕ ТОННА СӨТ САТАБЫЗ»

Түбән Бәрәскә авылына килгәч тә, ферма биналарына игътибар иттек: алар монда бик күп һәм берничә җирдә. Корылмаларның ник берсе ташландык яки иске булсын! «Хуҗа барлыгы сизелә монда», – дип сөйләшәбез. Май чүлмәге тышыннан билгеле була бит.

Ферма янында хуҗа кеше үзе дә күренде: утыз биш ел шушы хуҗалыкны җитәкләүче Илгиз Хәйруллинны республикада белмәгән кеше юк,

– Авыл хуҗалыгы тармагында көн дә, төн дә, бәйрәм дә юк ул. Ә көзге, язгы чор аеруча җаваплы, – дип елмайды Илгиз Вилданович.

Җитәкче белән фермага таба атлыйбыз. Элегрәк Европадагы фермалар турында укып шакката идек, кем уйлаган бездә дә шулай булыр дип! Гаҗәп бит, робот сыерның күпме ашаганын, күпме сөт биргәнен, кайчан бозаулыйсын, авыруларын, кыскасы, барысын да белеп тора.

– Сыерлар курортта кебек безнең, – диде Илгиз Вилданович. – Ашау мулдан, чисталык. Бездә малларга кычкырып та эндәшмиләр. Күпьеллык тәҗрибәдән чыгып әйтәм: сыерны сүгә-сүгә савасың икән, сөтне кимрәк бирә. Бездә сыерлар тәүлекнең теләсә кайсы вакытында савыла, кайчан телиләр, шунда робот янына киләләр.

Кооперативта дүрт меңгә якын мөгезле эре терлек бар. Бередә яшерминләр – игенчелек тармагына караганда терлек асрау отышлырак. Ләкин монда да белеп эшләргә кирәк:

– Терлекчелек тармагы игенчелектән башка яши алмый. Яхшы сыйфатлы терлек азыгы җитештерү – игенчелекнең ин беренче бурычы,– ди җитәкче. – Бер сыердан тәүлегенә уртача утыз литр сөт савабыз. Нәселле сыерлар тотабыз, баш санын ел саен арттырабыз.

Кооперативта 1 555 савым сыеры бар. Аларны роботлар сава. Көн саен 50 тонна сөт саталар. Бу акчалар хуҗалыкны алып барырга тулысынча җитә.

Фото: Лилиана Вәлитова. РЕКЛАМА

«АМБАРЛАР ТУЛЫ!»

Кооперативның 6822 гектар сөрүлек җире бар. Быел шуннан 14160 тонна иген җыеп алганнар. Уңыш узган елгы белән чагыштырганда югарырак: гектарыннан 53,1 центнер чыккан.

– Урып-җыю эшләренә 21 июльдә керештек, – диде хуҗалыкның баш агрономы Әнәс Хәйруллин. – Кызганыч, яңгырлар аркасында, эшләр берничә көнгә тоткарланды, югалтулар да узган елга караганда күбрәк булды. Әмма урып-җыю эшен бик яхшы күрсәткечләр белән тәмамладык. Хәзер инде бөтен көчне кукурузга юнәлттек.

Баш агроном безне басуга алып китте. 850 гектарда кукуруз чәчкәннәр. Узган ел орлыкка да алганнар, ягъни иген белән бергә кукурузны тарттырып он ясыйлар. Мөгезле эре терлек өчен бер дигән азык була икән.

Ашлык уңган елны игенчеләр сөенергә тиеш кебек. Әмма тәҗрибә күрсәткәнчә, андый елда игенчеләр минуста кала. Сәбәбе бик гади – игенгә бәя түбән: бер кило ашлыкка киткән чыгымнар керемгә караганда күбрәк килеп чыга. Менә шундый арифметика! Ленин исемендәге кооперативта моны яхшы аңлыйлар, шуның өчен алданмаска булганнар. Ашлыкны амбарларга тутырып куйганнар: игенгә бәя менгәнен көтәләр.

ЭШ ҖИТКЕРЕП БУЛМЫЙ...

Сүз башы бит Шүрәле. Авыл җирендә эшләргә кеше юк дибез. Бу проблема кооператив җитәкчесе Илгиз Хәйруллинны да бик борчый. Дөрес, бүген хуҗалыкта эшче кулларга кытлык юк, биредә ике йөздән артык кеше эшли. Һәм иң сөенечлесе – алар барысы да Бәрәскә, Бәрәзә, Өшкәтә авылы кешеләре. – Әлбәттә, безне шәһәр белән чагыштырып булмый, айлык хезмәт хакын да 150 мең куярга мөмкинлек юк, – диде Илгиз Вилданович. – Дөрес, сезон вакытында безнең дә механизаторлар 100–120 мең сумга кадәр алып эшли. Сыер савучыларның да уртача хезмәт хакы 70 мең сумнан артык чыга.

Кайчагында уйлап утырам: ел саен яңа ферма биналары корабыз, авыл халкының көнкүреше яхшырсын, дип телибез. Ләкин бит хәзер яшьләр җиңел, рәхәт яшәргә кызыга. Аларның күбесе шәһәргә китү ягын карый. Аннан соң... терлекче хезмәтенең абруе төште.

– Авылда калган яшьләр өчен дәүләт программалары бар бит?

– Әйе, барын бар ул. Мисал өчен, 35 яшькәчә булган гаиләләргә авыл җирендә йорт салу өчен акчаның 70 процентын дәүләт үзе бирә. Тик ни кызганыч, бүгенге көндә яшьләр бу программадан файдалана алмый, чөнки аның шартлары күп, үтәп бетермәслек... Минемчә, дәүләт тарафыннан конкрет чаралар күрелмәсә, әлеге проблема чишелмәячәк.

Тәҗрибәле җитәкче бүген әнә шулай дип борчыла. Әмма кукуруз кырына баргач, бу уңайдан башка төрле фикерләр туды. Әйе, Илгиз Вилданович дөрес әйтә: шәһәр авылны йота бара. Тик Ленин исемендәге кооперативта бу проблеманы күрмәдек. Ни өчен дигәндә, кукуруз басуында бер төркем яшь механизаторларга тап булдык. Кайсысы гаиләле, кайсысы әле армиядән яңа гына кайткан. Һәм алар шулай бергә җир җимертеп эшләп яталар.

– Бу әле көндезге смена гына, төнге сменага тагын шуның кадәр ир-ат чыга. Эш җиткереп булмый безгә, – дип елмайды егетләр.

... Түбән Бәрәскә халкы өчен шатланып кайттык, ихлас менә! Бер генә ташландык бина да, чүп баскан басу да күрмәдек. Йортлар төзек, берсеннән-берсе матур биредә. Күп авылларда соңгы фермаларга йозак элгәндә, Ленин исемендәге кооператив ел саен яңа корылмалар төзи. Нәтиҗәдә, авыл да яңара, үсә.


Закрыли рты,
открыли
тетради!
Выйди
и зайди
нормально!
Лес рук!

УКЫРГА, УКЫРГА ҺӘМ УКЫРГА!

Уку елы башланырга да өлгерми, без Укытучылар көнен бәйрәм итәбез. Без укытучылар һәм мәгариф хезмәткәрләре белән бу өлкәдәге проблемалар, көнүзәк мәсьәләләр, шау-шу уяткан вакыйгалар, киләчәк турында сөйләшергә һәрвакыт җай табабыз. Һәм тагын бер кат белемнең һәрвакыт кирәк булуы турындагы төп хакыйкатьне дәлилләп кенә калмыйча, бүген укучыга кайда, ничек һәм нәрсәгә өйрәнергә мөмкин булуын да аңлатырга тырышабыз. Чөнки Татарстанда белем бирү хезмәтләрен сайлау мөмкинлеге гаять зур: күппрофильле гимназияләрдән алып алдынгы физика-химия-математика мәктәпләренә кадәр; инженерлык лицейларыннан алып полилингваль белем бирү комплексларына кадәр. Бары тик укырга, укырга һәм укырга гына кирәк – республика тәҗрибәсе, шул исәптән мәгариф өлкәсендә дә, бөтен илгә үрнәк буларак таратыла. Чөнки Татарстанда укырлык, уртаклашырлык һәм өйрәнерлек нәрсәләр күп.

МӘГАРИФ СИСТЕМАСЫНДАГЫ СТРАТЕГИК АЛГАРЫШЛАР ҺӘМ МАТДИ СТИМУЛЛАР

Татарстанда һәр уку елы – якын киләчәктә республиканы тагын да куәтлерәк, абруйлырак, профессиональрәк итү юнәлешендәге алгарыш ул. Белем бирүдә бу, әлбәттә, үсеп килүче буын көче белән башкарыла. Бүген Татарстан мәгарифенең көн тәртибендә тормышыбызны алга этәрерлек нинди яңалыклар бар? Укучылар бу уңышларга ничек ирешә? Укытучылар, мөгаллимнәр нинди ярдәм чараларына исәп тота? Басмабызның әлеге һәм башка сорауларына Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министры Илсур Гәрәй улы Һадиуллин җавап бирде.

Фото: Александр Ефремов

Татьяна Вафина

УКЫТУЧЫЛАРГА – ТОРАК СЕРТИФИКАТЛАРЫ

– Илсур Гәрәевич, Татарстан Рәисе укытучыларга ярдәм итү буенча күп кенә проект һәм грантларны хуплады. Шулар турында әйтеп үтегез әле...

– ТР Рәисе карары буенча педагогларга яңа социаль ярдәм чаралары күрсәтеләчәк. Бу, беренче чиратта, торак сертификаты. 300 укытучы торак шартларын яхшырту өчен берәр миллион сумлык сертификат алачак. Ул ипотекага торак сатып алганда беренчел кертемне түләүдә яисә булган ипотека кредитының бер өлешен ябуда файдаланылырга, шулай ук фатир сатып алганда түләүнең бер өлеше булырга мөмкин. Гаризалар 2026 елның гыйнварыннан кабул ителә башлый, хәзер норматив документлар эшләнә. Ә ярты елдан, 2026 елның августыннан, түли башлаячакбыз.

– Мондый сертификатка кем исәп тота ала?

– Балалар бакчалары һәм мәктәп тәрбиячеләре, мәктәп укытучылары, урта һөнәри белем бирү оешмалары педагоглары, мәктәп яки урта һөнәри белем бирү оешмасы директорлары яки директор урынбасарлары. Әлбәттә, документларда төгәл шартлар язылачак, шуларның иң мөһиме: педагог эше башкару, мәшгульлек дәрәҗәсе, стаж һәм сертификат алганнан соң кимендә биш ел эшләү бурычы. Бу безнең педагоглар өчен бик яхшы ярдәм, дип уйлыйм. Моннан тыш, быелның өченче кварталыннан үз торaклары булмаган хезмәткәрләребездән торак өчен аренда түләвен компенсацияләүгә гаризалар кабул итә башладык. Гариза педагог эшләгән белем бирү оешмасы урнашкан муниципаль районда кабул ителә.

ХЕЗМӘТ ХАКЫНА ӨСТӘМӘ ТҮЛӘҮ

Хезмәт хакына өстәмә түләүгә килгәндә, бу уку елында яшь педагог һәм тәрбиячеләрнең хезмәт хакына ун мең сум өстәү күңелле сюрприз булды. Әлеге чараларның төп максаты – яшь укытучыларны җәлеп итү һәм аларга булышу, аларны һөнәргә беркетү. Татарстан бу мәсьәләне комплекслы хәл итә. Төрле премияләр, сыйныф җитәкчелеге өчен өстәмә акчалар, бүләкләр, мактаулы исемнәр һәм алар өчен матди түләүләр, һөнәри конкурсларда җиңүләр республикабыз педагогик җәмәгатьчелеге мохитенә уңай йогынты ясый.

ТӨГӘЛ ФӘННӘРГӘ КЫЗЫКСЫНУ АРТА

– Республикада цифрлаштыру белән кызыксыну көннән-көн арта, бу исә баштан ук төгәл фәннәрне яхшы белүне күздә тота. Татарстанда мәктәп укучыларын әлеге фәннәр белән кызыксындыру нинди чаралар ярдәмендә хуплана? Һәм узган елгы «Физика-математика буенча алга китеш»нең нәтиҗәләре нинди?

– Узган уку елында республикада «Физика-математика буенча алга китеш» пилот проекты старт алды. Физика-математика укытуның сыйфатын күтәрү, балаларның математикага сәләтен үстерү, бу юнә-

лешләргә ныклы белемле абитуриентлар агымын тәэмин итү өчен, без ел дәвамында биш юнәлеш буенча эшләдек. 5-7 сыйныф укучылары өчен – математика һәм физика түгәрәкләре, 7-9 сыйныфлар өчен профильле физика-математика сыйныфлары оештырылды. Бу фәннәрне популярлаштыруга һәм өйрәнүгә юнәлдерелгән күп кенә чаралар – фестивальләр, лекцияләр гамәлгә ашырылды. Балалар әлеге чараларда, бигрәк тә күчмә оештырылганнарында, актив катнашсын өчен, аларны премияләр

белән кызыксындырдык (200 укучы 50 шәр мең сум алды). Ә бу балаларны әзерләгән укытучылар өчен грантлар булдырдык. Физика-математика профилендәге 100 укытучы 300 әр мең сум грант; яшь укытучылар 240 шар мең сумлык 150 грант; физмат түгәрәкләре җитәкчеләре 90 шар мең сумлык 100 грант алды. Бу максатларга республика бюджетыннан 252 миллион сумнан артык акча бүлеп бирелде. Моннан тыш, Татарстанның 40 мәктәбенә «физика-математика сыйныфларында программаны гамәлгә ашырган өчен» 600 әр мең сум һәм «укучыларының физика, математика, информатика буенча югары нәтиҗәләргә ирешкәне өчен» берәр миллион сум грант тапшырылды.

Бу тәҗрибә киләсе елда да дәвам иттереләчәк.

– Матди стимуллаштыру лириклардан – физиклар, ә икеле капчыкларыннан отличник ясарга сәләтлеме?

– Балалар, аларны дөрес тәрбияләгәндә, бер үк вакытта лирик та, физик та була ала, тик аларга укуы кызык булсын. Ә бу эле матди яктан да ныгытылса, алар таулар күчерергә сәләтле. Икеле капчыклары каян килә соң алар? Нindидер сәбәпләр аркасында, балаларны предмет кызыксындырмаганлыктан. Безнең «Физмат буенча алга китеш» аларны кызыксындырды һәм шуңа күрә уңай динамика күрсәтте: икелеләр саны кимеде, дүртле һәм бишлеләр артты. Түгәрәкләр исә математика һәм аңа бәйле фәннәр белән бишенче сыйныфтан ук кызыксындыра башлау мөмкинлеген бирде. Бу проект нибары бер ел гына тормышка ашырыла әле, тик ул инде киләчәктә математик һәм техник белгечлекләр сайлап алачак укучылар санын шактый арттырды. Безнең бурыч – бу тәҗрибәне табигый фәннәр циклының башка предметларына, барыннан да элек химиягә, җәелдерү. Алга таба проектны бөтен ил территориясенә таратырга, дип уйлыйбыз.

«ФИЗХИМ – АЛГАРЫШ»

– Димәк, чираттагы алга китеш химия белән бәйле булачак?

– Физика һәм химия белән. Татарстан Республикасы Рәисе Рөстәм Нургали улы Миңнеханов күрсәтмәсе буенча Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, «Физик-химик алгарыш» проектын әзерләү өчен, химия һәм физика юнәлешендә укучылар һәм укытучылар белән эшләү буенча иң яхшы тәҗрибәләрне өйрәнә. Бу эш Казан федераль университеты һәм Иннополис университеты белән уртак башкарыла. Әгәр без илне югары дәрәҗәдәге кадрлар белән тәэмин итмәсәк, технологик бәйсезлеккә ирешә алмаячакбыз. Ә кадрлар әзерләү

мәктәптән башлана. Балаларның химия һәм физика белән кызыксынуы артуга уңай йогынты ясарга, бераз вакыттан соң инженер һөнәрләрен сайлаучы абитуриентлар санын арттырырга сәләтле 30 дан артык оешма проект өчен сайлап алынды инде. Проектка илнең әйдәп баручы химик һәм физикларын җәлеп иттек.

– Бу алга китешне тормышка ашыру күпме тора?

– Алдагысына караганда бераз кыйммәтрәк. Проектның концепциясе инде эшләнгән һәм өч елга (2026 елдан 2028 елга кадәр) сметасы 1 миллиард 432 миллион сумны тәшкил итә. Бу «физмат-смета»га караганда күбрәк, чөнки химия һәм физика математикага караганда ресурсларга таләпчәнрәк дисциплиналар санала.

– Бу суммага нәрсә керә?

– Иң беренче чираттагы бурыч – башта республика эчендә, аннары илнең башка төбәкләрендә кадрлар мәсьәләсен хәл итү. Моннан тыш, УКЫТУЧЫЛАРГА, МӘКТӘПЛӘРГӘ, УКУЧЫЛАРГА технологик, грант, методик, оештыру ярдәме күрсәтү һәм, әлбәттә инде, физика белән химияне ПОПУЛЯРЛАШТЫРУ. Химия һәм физика укытучылары өчен бу квалификация күтәрү, цифрлы методик әсбаплар, грантлар дигән сүз. Шулай ук югары уку йортлары мөгаллимнәренә мәктәпләрдә эшләгән өчен дә грантлар планлаштырыла. Мәктәп укучылары өчен түгәрәкләр генә түгел, профильле сменалар, предприятиеләргә экскурсияләр, онлайн дәресләр, әлеге юнәлештәге чараларда актив катнашкан өчен премияләр дә күзаллана. Мәктәпләр өчен – профильле сыйныфлар, түгәрәкләр ачу, югары казанышлар өчен һәм заманча җиһазлар яисә лабораторияләр сатып алуга грантлар. Химия һәм физиканы популярлаштыруга килгәндә, проектны гамәлгә ашыруда республика һәм Мәскәү югары уку йортлары да катнаша. Алга таба мин болар барысы да чынбарлыкка әйләнер, дип уйлыйм.

МИН ҮЗЕМ ХИМИЯНЕ ЯРАТА ИДЕМ

– Барыбызның да хәтерендә мәктәп еллары онытылмаслык булып саклана. Яраткан дәресләребез дә. Ә сез кайсы предметны яратып укыдыгыз?

– Минеке – химия. Төрле тәҗрибәләр ясарга ярата идем. Бу мине кызыксындыра, мавыктыра һәм әлеге фәнне ныграк өйрәнүгә илһамландыра иде. Нәтиҗәдә, химия укытучысы һөнәрен сайладым. Һәм хәзер, укучылар белән үткәргән дәресләремне искә төшереп, шуны әйтә алам: нәкъ менә тәҗрибәләр, балаларның уку процессы белән шәхси кызыксынуы аларга шул дәресне һәм шул фәнне гомерлеккә яратырга ярдәм итә.

«ЛИРИК» ЧИГЕНЕШ

– Лирикларга әйләнеп кайтыйк: әлегә «алгарышсыз» предметлар – башка фән укытучыларын да матди кызыксындыру бармы соң?

– Әлбәттә! Ел саен 200 белгечкә «Безнең яңа укытучы» гранты бирелә. Бу уку елында республикада грантлар саны 500 гә җитте!

БӘЙРӘМ БЕЛӘН, КОЛЛЕГАЛАР!

Кадерле укытучылар, коллегалар, тәрбиячеләр, кадерле педагогик хезмәт ветераннары, остазларыбыз!

Барыгызны да республикабыз Мәгариф һәм фән министрлыгы исеменнән, шәхсән үз исемемнән һөнәри бәйрәмегез белән котлыйм!

Укытучылар – миссионерлар алар! Көне буе мәктәптә, көне буе балалар белән искиткеч миссионерлык эшчәнлеге белән шөгыльләнәләр – өйрәтәләр, тәрбиялиләр, үстерәләр.

Без барыбыз да үзебезнең теге яки бу фән буенча белем биреп кенә калмыйча, ә чын шәхес тә итеп тәрбияләгән укытучыларыбызны гомер буе сагынып, хөрмәтләп яшибез!

Һәр өйдә, һәр гаиләдә, һәр бәйрәм табынында бу көнне үзләренең укытучыларын искә алалар!

Исән-сау, бәхетле булыгыз! Үзегезне саклагыз! Сезгә уңышлар һәм балалар тәрбияләүдә яңадан-яңа казанышлар телим! Тормышта һәм һөнәрендә үз урынын табарга булышкан һәркемнән олы ихтирам һәм рәхмәт сүзләрен кабул итеп алыгыз! Бәйрәм белән сезне!

Фото: Александр Ефремов

КАМИЛ АРСЛАНОВ: «ЯСАЛМА ФӘҺЕМ ЯХШЫ ЮРИСТНЫ АЛЫШТЫРА АЛМЫЙ»

Евгения Чеснокова

Россиядә югары мәктәп бүген чираттагы үзгәрешләр чорын кичерә. Казан федераль университетының юридик факультеты профессоры, гражданлык хокукы кафедрасы мөдире Камил Марат улы Арсланов белән без бу үзгәрешләрнең юридик белемгә ничек йогынты ясавы, хокук белемендә нинди яңа юнәлешләр барлыкка килүе, «бездә юристларны артык күп әзерлиләр» дип әйтүнең ни өчен дөрес булмавы һәм мөгаллимнәргә үзләрен формада тотарга нәрсә ярдәм итүе турында сөйләштек.

ЯҢА МӨМКИНЛЕКЛӘР ҺӘМ ЯҢА СЫНАУЛАР

– Камил Маратович, югары мәктәп бүген чираттагы трансформация чорын кичерә. Бакалавриат һәм магистратурадан белгечлеккә (специалитет) кире кайту юридик факультет укытучылары эшенә ни дәрәҗәдә йогынты ясый?

– Бездә ел саен мөгаллимнәргә яңа таләпләр, яңа тәкъдимнәр кертелә, яңа программалар пәйда була... Әмма юридик белем бирү һәрвакыт сыгылмалылыгы белән аерылып торды, шунлыктан безнең өчен әчтәлекнең асылы әллә ни үзгәрми. Мөгаллим яңа таләпләргә тиз арада җайлаша һәм программаларны үзгәртә белергә тиеш. Кирәк икән, курсны ике еллык яки ярты еллык итеп ясый алабыз. Тәкъдим ителгән программа кысаларында без студентларны кирәкле күнекмәләргә өйрәтә беләбез.

– Ә хәзерге студентлар, бөтенләй яңа буын – алар нинди? Сез алар белән уртак тел табасызмы?

– Әлбәттә. Гомумән, һәрдаим яшьләр арасында булу бик яхшы. Бездә бик яхшы студентлар укый, аларда яңа белем алуга омтылыш сизелә. Яшьләр белән кызык, әйләнә-тирәдәге яңалыклардан калышмас өчен, без нәкъ менә алар белән бер дулкында булырга тырышабыз. Үзебез дә алардан энергия алабыз.

Гомумән, алар безнең яшь чактан әллә ни нык аерыла дип әйтмәс идем, бары тик башкача киенә һәм сөйләшәләр генә, шулай ук аларның мөмкинлекләре зуррак, ымсындыргыч мавыгулары күбрәк. Һәм, сүз уңаеннан, бу мөмкинлекләр аркасында аларга бүген безгә караганда да авыррактыр әле, бәлки.

– Менә ничек?

– Менә карагыз: аларның технологияләре, интернет, GPT чатлары да бар кебек... Бездә боларның берсе дә булмады. Хәтта ксерокслар да юк иде, күп нәрсәне кулдан күчереп язарга туры килде. Әмма бу безгә өйрәнгәннәребезне тирәнрәк аңларга ярдәм итте бит! Ә бүген балар барысы да игътибарны тарката, яшьләр болайрак уйлый: кирәкле мәгълүматны һәрвакыт кайдан да булса карый, таба, җавапны белә алам... Ялкауландылар, нәтиҗәдә, мөмкинлекләр зуррак булса да, аларга белем алуы авыррак... Һәм хәзер яхшы белгеч булу өчен иң башта бу ялкаулыкны җиңәргә кирәк.

ТЕОРЕТИКЛАР ҺӘМ ПРАКТИКЛАР ТУРЫНДА

– Юридик белем һәрвакыт бик абруйлы булды, һәм күп кенә яшьләр, бәлки, һөнәрнең асылын бигүк аңлап бетермичә, юристлыкка омтыла. Ә сез юриспруденциягә ничек килдегез?

– Бу нәкъ шул туксанынчы елларда, зур үзгәрешләр вакытында булды. Миндә совет тәрбиясе, яхшылык һәм яманлык турында совет күзаллаулары бар иде, һәм, мөгаен, дөньяны яхшы якка үзгәртергә теләгәнмендер. Миңа бәхет елмайды: чикләр ачылган вакытта укыдым. Мин беренче тапкыр чит илгә 1992 елда – Германиядәге Дрезден шәһәренә бардым. Минем өчен бу дөньяны, үз-үземне танып белүдә зур ачыш булды. Дүртенче курста мин Германиягә киттем, студентлар алмашы кысаларында Гисен университетында укыдым. Анда үземнең искиткеч мөгаллимемне – профессор Ян Шаппны очраттым. Ул мине фәнни тикшеренүләрдә катнашырга

чакырды, һәм мин беркадәр вакытка Германиядә калдым, анда хокук магистры дәрәҗәсен алдым. Аннары Казан университетына кайттым, башта – ассистент, күпмедер вакыттан – доцент, соңрак бүген үзем җитәкләгән гражданлык хокукы кафедрасы профессоры булдым.

– Сез бит әле адвокат булып та эшлисез?

– Минемчә, теләсә кайсы юрист һичшиксез практик булырга тиеш. Табиб кебек. Операция ясый белмәгән табиб үз шәкертләренә хирургиядәге нindidер нечкәлекләрне аңлата алмаячак. Чөнки алар нәкъ менә практикада күренә. Теманың гамәли асылын аңламыйча, ничек мин, мәсәлән, килешүләр һәм салымнар турында лекцияләр укый алам? Студентлар кодекс маддәләрен өйрәнгәндә, гамәли тәҗрибәләре булмаганга, аларны күз алдына китерә алмауларын яхшы аңлыйм, ә юрист өчен бу бик мөһим. Практика безгә тормышка якыную, вакуумда калмау мөмкинлеген тудыра.

– Ә университетта эшләү практика өчен нәрсә дә булса бирәме соң?

– Әлбәттә. Практика белән генә шөгыльләнүче юристлар юриспруденция теориясендә, законнарда нинди үзгәрешләр барганын һәрвакытта да күзәтеп бара алмый. Мәсәлән, закон чыкты, ләкин аны ничек кулланырга икәне әле бигүк аңлашылмый... Ә мөгаллим кулын пульста тота, чөнки без мондый үзгәрешләр турында башкалардан иртәрәк беләбез. Шулай булгач, практикасы да булган укытучылар хәтта кайчакта башкаларга караганда да реаль эшкә күбрәк әзер.

ТАБИБКА ЮРФАК НИГӘ КИРӘК

– Юриспруденция, хокук – бик традицион тармак ул...

– Әйе, дөрес, традицияләребез Рим хокукыннан ук килә.

– Бу традициядә өр-яңа нәрсәләргә урын бармы?

– Бүген үзебезнең гражданлык хокукы кафедрасында гамәлгә керә торган яңа юнәлешләр турында сөйлим хәзер. Аларның берсе – медицина хокукы, аны бик мөһим дип саныйм. Бездә медицинаны белүче юристлар бик аз. Һәм минем максат – юрист-медиклар әзерләү. Чөнки медицина белеме булмаган юристка табиблар эшендә туган проблемаларны хәл итү бик кыенга туры килә. Үзләренә хокукый база кирәк булган табиблар, магистратурага яки икенче югары белем алырга дип, безгә килә. Психиатрлар да, терапевтлар да, стоматологлар да бар...

Шулай ук без табибларның хокукларын яклау юнәлешен үстерәбез. Бүген бездә пациент хокукларын яклау ягына авышу сизелә. Кулланучы һәрвакыт хаклы, ә табиблар еш кына яклаучысыз кала. Аларга теләсә нинди хата өчен бик каты җәза бирәләр, һәм һәрвакытта да гаделлек җитми.

Безнең тагын бер яңа юнәлешебез бар – сәнгать өлкәсе буенча юристлар. Сәнгать дөньясын регламентлый торган юридик нормалар белән эш итү. Монда да шул ук хәл – бездә бу өлкәдә белемле юристлар аз. Ә сәнгать белгечләре арасында, медиклар арасындагы кебек үк, юристлар юк диярлек. Шул ук вакытта анда да бүген яңалыклар күп – мәсәлән, токеннар, цифрлы кодлар рәвешендәге сәнгать. Белгеч булмаган кешегә бу яңалыкларның хокукый нигезләрен аңлау авыр.

Һәм, ниһаять, без юридик белем бирүдә мәгълүматлаштыру, цифрлаштыру, ясалма фәһем юнәлешендә эшлибез, башка өлкәләрнең белгечләре белән бергә хокукый регламентацияне тикшерәбез һәм аларны үзебез эшлибез. Бу юнәлешләр буенча без магистратурада белем алуны, квалификация күтәрү курсларын тәкъдим итәбез, лекцияләр укыйбыз. Күптән түгел, мәсәлән, Иннополиста хезмәттәшләребез белән чит ил студентлары

өчен цифрлы хокук өлкәсендә инглиз телендә лекцияләр укыдык.

– Хокук өлкәсендә мәгълүматлаштыру һәм ясалма фәһем турында сөйләшә башлагач, шундый сорау туа - ул тиздән тере юристларны алыштырыр дигән шик юкмы?

– Бер яктан, әйткәнемчә, цифрлы технологияләргә исәп тотып, без үзебез ялкауландык. Әмма икенче яктан, әгәр без бирешмәсәк, технологияләр беркайчан да безнең көндәшкә әйләнмәячәк. Кеше миенең мөмкинлекләре бик зур һәм әле ахыргача өйрәнелмәгән. Әгәр дә без кул кушырып утырмасак һәм баш миебезне үстерүне дәвам итсәк, ясалма фәһем кешене беркайчан да җиңмәячәк. Үз компетенцияләрен даими камилләштерүче яхшы юристны ул беркайчан да алыштыра алмаячак. Ләкин ул безнең бик яхшы ярдәмчебез булырга мөмкин. Иң мөһиме – аңардан дөрес файдаланырга өйрәнү.

БЕЛЕМ БЕРКАЙЧАН ДА АРТЫК БУЛМЫЙ

– Россия югары уку йортлары юристларны артык күп чыгара, дигән сүзләр инде утыз еллап тынмый. Бу хакта нәрсә уйлыйсыз?

– Әлбәттә, мин укыган вакытта түләүле уку бүлеге юк иде, бюджет кына, һәм университетта бөтен республикага бер юридик факультет бар иде. Хәзер исә юристлыкка кайда гына укытмыйлар, һәм юристлар чыннан да күп. Тик һәрвакыт әйтә килдәм: яхшы юристлар аз!

Икенче яктан, яшьләрне уйларга, укырга, яңа шартларга җайлашырга өйрәтүебез бик мөһим кебек тоела. Алар бу күнекмәләрне соңыннан башка өлкәләрдә кулланса да. Менә, мисал өчен, Лев Николаевич Толстой. Ул безнең университетның юридик факультеты студенты була, тик укуын тәмамламый. Аның әсәрләрендә юридик факультетта алган белеме чагылыш таба. Моңа ачык мисал – язучының «Воскресение» романы.

Мин кайвакыт үземнең шәкертләремне бөтенләй көтмәгән урыннарда очратам. Пешекчеләр, таксистлар, официантлар, менеджерлар... Иң мөһиме, без кешегә тормышта үз урынын табарга ярдәм итәбез. Гомумән, юридик белем, теләсә кайсы башка белем кебек үк, кешегә формалашу, тормышта үз урынын табу мөмкинлеген бирә. Студентларның егерме-утыз проценты гына үз белгечлеге буенча эшләсә дә, калганнары ахыр чиктә хокукый грамоталы кешеләр булачак, андыйлар исә бүген җитешми. Шуңа күрә мин хокукый дисциплиналарның безнең университеттагы башка факультетларда – педагог, психолог, икътисадчыларга да укытылуын дөрес дип саныйм...

– Гамәлдәге адвокат буларак, мөгаен, эш вакытында үзегез укыткан укучыларыгыз белән очрашасыздыр. Бу вакытта нинди хисләр кичерәсез?

– Бу бик кызыклы тойгылар. Мәсәлән, мин судка килдәм, ә судья – минем элеккеге студентым... Һәм бу, сүз уңаеннан, дөньяны һәм тормышны аңларга бик булыша. Тәкәбберләнүдән саклый. Чөнки университетта укыткан чакта үзеңнең өстенлегеңне, хаклы булуыңны тоясың. Ә монда син оттырырга да, хаталанырга да мөмкин... Шунлыктан һәрвакыт эзләнергә, яңа белемнәр үзләштерергә, үзеңне камилләштерергә кирәк. Бүген безнең кафедрада да күп кенә шәкертләрем эшли. Кандидатлык, докторлык диссертацияләрен яклаучылар бар. Димәк, без юриспруденциядә яңа фәнни мәктәп булдырабыз, дип әйтергә була.

СТРЕССНЫ СПОРТ ҖИҢӘ

– Заманча университет мөгаллиме – ул нинди булырга тиеш?

– Иң мөһиме – ул даими укырга, эзләнергә тиеш. Үз алдына яңа максатлар куярга, көн саен ниндидер ачышларга омтылырга. Бу җиңел түгел. Шуңа күрә һәркем дә мөгаллим була алмый.

– Сезгә бу юлда бирешмәскә, көч тупларга нәрсә ярдәм итә?

– Спорт. Ул минем тормышымның бик мөһим өлеше. Мин бассейнга йөрим, фридайвинг белән шөгыльләнәм, ләкин чын мәгънәсендә үземне классик япон көрәшләрендә таптым – буджитсу, джиу-джитсу, айкидо.

– Ни өчен нәкъ менә алар?

– Алар бит үзеңне яклый белү өчен генә түгел. Япон көрәшләре – ул әле эчке гармония, медитация, стресстан котылу мөмкинлеге дә. Мин Казанда уникаль тренерлар – Александр Леонидович Сивков һәм Алексей Георгиевич Мищенконы таптым. Алар белән шөгыльләнү үземне камилләштерергә ярдәм итә.

БОРЫНГЫ ДИВАРЛАР РУХЫ

– Бүген Казан университетында бер генә факультет – юридик факультет кына калды. Калганнары институт итеп үзгәртелде. Бу юрфак – КФУда иң традицион бүлекчә дигән сүзме?

– Бүлекчәләрнең исемнәрен үзгәртүгә карамастан, безнең, әйтик, тарихчылар, математиклар яки шәрыкны өйрәнүчеләр университет традицияләренә юристларга караганда азрак тугры, дип әйтмәс идем. Әмма шулай килеп чыкты ки, без бүген КФУда чыннан да бердәнбер факультет, һәм бүген дә XIX гасырдагы элгәрләребез укыткан аудиторияләрдә эшлибез. Шуңа ул заманның рухы бу аудиторияләргә сеңеп калган, дип саныйм. Ә хокук өчен бу дәвамчанлыкны, үзеңнең бик зур традициягә тугрылыгыңны тою бик мөһим.

«АДЫМНАР»: КАНАТ ЯРГАН ЧАК

Казанда өч телне тирәнтен өйрәнү белән «Адымнар – белемгә һәм килешүгә юл» беренче полилингваль белем бирү комплексы 2020 елның сентябрендә эшли башлады. Уку-укыту эшләре – Абдулла Бичурин урамындагы төп һәм башлангыч мәктәпләрдә, шулай ук Бондаренко урамындагы яңа корпуста алып барыла. Ике мәктәпнең гомуми мәйданы 48 мең квадрат метрдан артык! Белем үзәгенең ике бинасында күпфункцияле спорт заллары, өч бассейн, иҗади остаханәләр, фәнни лабораторияләр, видео- һәм тавыш яздыру студиясе, заманча китапханә урнаштырылган. Кыскасы, зур, заманча мәктәп бу.

Әлеге уку йортына республика җитәкчелегенең дә өмете зурдан иде. Шул өметләр акланганмы? Биш ел эчендә нинди нәтиҗәләргә ирешелгән? «Адымнар» полилингваль мәктәбенә баргач, әнә шулар хакында ачыктан ачык сөйләштек.

Руфия Фазылова

ПЫЯЛА ИШЕКЛӘР АРТЫНДА...

Мәктәп директоры Айдар Шәмсетдинов башта уку йорты белән таныштырып чыкты. Күзгә ташланган беренче нәрсә – стеналар пыяладан, ягъни коридордан узучы укучыларны карап китә. Шулай ук укучылар да узып баручыларга күз төшереп ала.

– Дәрес вакытында балаларның игътибары читкә юнәлмиме соң?

– Юк, алар аңа ияләнгән инде. Бер күз төшереп алалар да шуның белән шул.

Заманча мәктәпләр зурлыгы, укучылар өчен уңайлы ял итү урыннары булу белән бер-берсенә охшаш. Әмма «Адымнар» башкалардан аерылып тора: монда берьюлы, ким дигәндә, өч телдә сөйләшәләр. Әнә кемдер укытучысы белән инглиз теленнән олим-

Фото: Лилиана Вәлитова. РЕКЛАМА

пиадага әзерләнә, икенчеләр татар теленнән конкурска нәфис сүз ятлый, өченчеләр рус теленнән проект эшли.

Мәктәп директоры Айдар Илдарович коридорда очраган балаларга инглизчә дә, татарча да, русча да эндәшә. Укучылар да җавап бирә: тиз арада диалог башлана...

Директор белән үтә күренмәле ишекләр артына узабыз: сыйныфлар гына түгел, директор, укытучылар бүлмәсе дә пыяла монда. Биредә барысы да күз уңында.

– Биш еллык эш нәтиҗәләренә килсәк, иң беренче уңышлар турында әйтәсе килә, – дип сүзен башлады мәктәп директоры. – Әлбәттә, бу беренче чиратта укучыларыбызның җиңүләре. Бөтенроссия укучылар олимпиадалары нәтиҗәләре елдан-ел сөендерә, ягъни җиңүчеләр, призерлар саны арта бара. Монысы бер. Икенчедән. Тел укыту ысулларын камилләштерү мәсьәләсендә зур уңышларыбыз бар. Бездә барлык укучылар да татар телен өйрәнә, шул исәптән башка милләт балалары да. Ә бу бүгенге вазгыятьтә зур эш, дип саныйм. Әлеге юнәлештә ата-аналар белән дә элемтәдә торабыз, аңлату эшләре алып барабыз. Бондаренко урамындагы бинада чын татар мохите.

«ДӘРЕСЛЕК ЭШЛӘДЕК»

Чынлап та, «Адымнар»ның Бондаренко урамындагы бинасында барысы да татарча. Биредә ата-аналар да, балалар да милли җанлы. Башлангыч мәктәптә, математикадан кала, бөтен дәресләр татарча үткәрелә икән. Бу корпуста 1200 дән артык бала белем ала. Ә менә Бичурин урамындагы бинада уку күбрәк рус, инглиз телләрендә бара. (Сүз уңаеннан, ТАССР Куркынычсызлык комитеты рәисе булган генерал-майор Абдулла Бичурин истәлегенә мәктәптә экспозиция почмагы булдырылган.)

– Элекке 165 нче мәктәп иске бинада ике тулы смена белән эшли иде, – дип дәвам итте Айдар Шәмсетдинов. – Хәзер ул бинаны башлангыч мәктәп итеп реконструкцияләдек, анда хәзер бер меңнән артык бала укый. Башлангыч мәктәпкә килүгә, эти-әниләр төп траекторияне сайларга тиеш. Ул күп телле яки ике телле траектория – полилингваль һәм билингваль.

Казан федераль университеты галимнәре ярдәмендә, «Адымнар» өчен махсус татар теле дәреслеге язылган.

ХАТАЛАРСЫЗ ҮСЕШ ЮК...

Рузалия Фәйзрахманова, югары категорияле башлангыч сыйныф укытучысы:

– Җәмгыять өчен укытучының роле бик мөһим. Нәкъ менә укытучы балага этәргеч бирә, аның йөрәгендә: «Телим, булдыра алам, минем барысы да барып чыгачак», – дигән теләк уята. Егылуларсыз күтәрелүләр булмый, хаталарсыз үсеш юк. Һәр бала өчен терәк, илһамчы һәм остаз булырга тырышырга кирәк.

АҢЛАШУ КИРӘК

Рөстәм Гыйльметдинов, директор урынбасары:

– Гомер буе яшә, гомер буе өйрән, ди халык. Мин моның белән тулысынча килешәм. Без бүген балаларны аңлап бетермибез: гел аларга ниндидер үгет-нәсихәт, киңәш бирәбез. Әмма бер нәрсәне истән чыгармаска кирәк – дөнья үзгәрә, бер урында гына тормый. Үсмерләрнең үз телләре, заманча шөгыльләре бар, һәм бу гадәти хәл. Әлеге очракта укытучы да алардан хәбәрдар булырга тиеш. Шул очракта гына аңлаешлы диалог килеп чыгачак. Ягъни укытучы балага фән дөньясын, тормышның асылын күрсәтсә, укучылар исә безгә бүгенге заманны аңларга өйрәтә.

УКЫТУЧЫ ГАИЛӘДӘ БИРЕЛГӘН ТӘРБИЯНЕ ДӘВАМ ИТӘ

Раилә Закирова, беренче категорияле рус теле укытучысы:

– Бүгенге көн укытучысының төп максаты – тирән белем бирү белән беррәттән, әхлаклы, бар яктан камил, киңкырлы шәхес тәрбияләү, укучыларны туган илне яратырга, эти-әнине, олыларны хөрмәт итәргә өйрәтү. Укытучы, гаиләдә бирелгән тәрбияне дәвам итеп, бала өчен остазга әверелә, аңа тормышта үз юлын табарга булыша, акны карадан аерырга өйрәтә, авырлыклар алдында югалып калмаска өнди.



УКЫТУЧЫЛЫК СТАЖЫ – 500 ЕЛДАН АРТЫК

Динар Шәмсетдинов, югары категорияле тарих һәм җәмгыять белеме укытучысы, тарих фәннәре кандидаты:

– Безнең гаиләнең гомуми педагогик стажы 500 елдан артып китә. Әнә шундый нәселнең дәвамчысы булу горурлык та, җаваплылык та. Нинди генә чорда яшәсәләр дә, укытучыларның максаты бер булган – шәхес тәрбияләү, кешенең рухын үстерү... «Адымнар» мәктәбе укытучысы буларак минем максат – татар җанлы ватанпәрвәр әзерләү. Укытучы – юл күрсәтүче йолдыз, ул балаларга бу гаҗәеп дөньяның барлык якларын ачарга ачкыч тапшыра. Бүген укытучы булып эшләүчеләргә басып кул чабам, «Укытучы» сүзен баш хәрефтән язуны кертер идем.

УКЫТУЧЫ – БАЛАЛАР КҮҢЕЛЕ ДИРИЖЁРЫ

Илзирә Мукменёва, инглиз теле укытучысы, ТРның атказанган укытучысы:

– Укытучының төп бурычы – балада белемгә генә түгел, төп кешелеклелек сыйфатларына да нигез салу. Укытучы – балалар күңеле дирижёры, ә балалар – безнең хисләр, кәеф һәм гамәлләребезнең тулы бер оркестры. Укытучы никадәр оста, талантлы дирижёрлык итсә, балалар оркестры да шулкадәр көйлерәк, матуррак яңгырый.

АТТЕСТАТТА НИНДИ БИЛГЕ БУЛУЫ МӨҺИМ ТҮГЕЛ

Валентина Кузнецова,
рус теле һәм әдәбияты укытучысы:

– Укытучы булу – ул миссия, һәм аның роле күпкырлы, бигрәк тә хәзерге заманда. Әйе, укытучы белем, тәҗрибә белән уртаклашырга, төрле күнекмәләр тәрбияләргә, остаз, ярдәмче һәм дус булырга тиеш. Шулай да иң мөһиме – һәрберебез үз укучыларын теләсә нинди ситуациядә миһербанлы, чын кеше булырга өйрәтергә тиеш, дип уйлыйм. Имтиханда, аттестатта нинди билге булуы мөһим түгел, ә безнең балалар тормышында иң мөһиме кешелеклелеккә имтихан булачак, һәм нәкъ менә аны «бик яхшы»га тапшырырга кирәк! Монда исә күп нәрсә нәкъ менә укытучыдан тора.

Беренчедән алып унберенче сыйныфка кадәр эшләнгән әлеге зур хезмәт укучылар тарафыннан да, укытучылар арасында да уңай бәяләнгән. Әгәр дәреслек РТ Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан расланса, киләчәктә аны башка мәктәпләргә дә тәкъдим итү мөмкинлеге булачак.

– Ничек кенә булмасын, бүгенге балалар барыбер ике телле вазгыятьтә яши, – диде директор. – Алар тулаем татарча гына фикер йөртүче буын түгел. Яңа дәреслек нәкъ менә шуны күздә тота, укучылар өчен аңлаешлы. Ул чит телләр өйрәтү методикасына нигезләнгән, нәтиҗәдә, татарча сөйләшмәгән бала да рәхәтләнеп телне өйрәнә ала.

– Гадәттә, ике телне белгән бала өченчесен, дүртенчесен дә җиңел өйрәнә, диләр. Сез бу фикер белән килешәсезме?

– Йөз процент килешәм. Мисал өчен, белгечлегем буенча мин гарәп һәм инглиз телләре укытучысы. Рус һәм татар телен дә камил беләм. 38 яшемдә төрек телен өйрәнергә булдым, хәзер төрекчә йөгерек сөйләшәм, китаплар укыйм. Өстәвенә, мәктәптә француз телен укыган идем. Шуннан испан телен дә өйрәндем. Боларның барысы да – эш теле. Мин полиглот түгел. Хәзер кимендә дүрт тел белү – теләсә кайсы европалы өчен табигый ихтыяҗ булып тора. Шунысын һич икеләнмичә әйтә алам: тел белү, башка мәдәниятләр белән таныш булу – шәхесне үстерә.

Телләр дигәннән, «Адымнар»да математика, география, биология дәресләрен инглизчә укучы аерым сыйныфлар бар. ТР Хөкүмәте ярдәме белән, «Просвещение» нәшрияты махсус дәреслекләр нәшер иткән. Нәтиҗәдә, укучылар Россия стандартларыннан чыгып эшләнгән инглиз телендәге дәреслек белән укый.

УКЫТУЧЫ АБРУЙЛЫ БУЛЫРГА ТИЕШ

«Адымнар»да бар да яхшы гына икән дигән фикер туарга мөмкин. Юк, җәмәгать, алар да шул ук җәмгыятьтә яши. Монда да балалар үзара тарткалашә дә, ата-аналар белән дә аңлашырга туры килә. Барысы да гадәттәгечә. Һәм башка мәктәпләрдәге кебек үк биредә дә укытучылар җитми. Юк, бүген монда һәр предмет тиешенчә укытыла. Әмма укытучылар икешәр ставкага эшләргә

мәҗбүр. Беренчедән, укытучылар җитми, икенчедән, бер генә ставкага эшләсә, аның хезмәт хакы утыз меңгә дә тулмаячак. Ә бит әле белем сыйфатын күтәрү өчен укытучының да иңиңен җәлеп итәргә кирәк. Монысы буенча директор аерым эш алып бара: булачак укытучыларны студент эскәмиясеннән үк барлый.

– КФУның дәүләт йомгаклау комиссиясендә рәис булып торам, – дип дәвам итте Айдар Илдарович. – Ягъни иртәгә кулына диплом алачак студентларны бүгеннән үк күрәм. Һәм иң яхшыларын үзебезнең мәктәпкә чакырам. Дөрес, аны бит әле күндерергә дә кирәк. Ә без тәкъдим иткән хезмәт хакына бүген яшьләрнең мәктәпкә бик киләселәре килми. Яңалык әйтмәм: укытучыга дәүләт тарафыннан тиешле хезмәт хакы түләнергә тиеш! Мөгаллимлек эше – ул хезмәт күрсәтү түгел, ул милләткә, халыкка хезмәт итү.

Үз вакытында Сингапурда да, АКШта да, Финляндиядә дә стажировкада булдым. Без бит инде аларда дөньяның иң алдынгы мәгариф системасы, дип уйлыйбыз. Ләкин шуны да аңларга кирәк: Финляндиядә укытучы – иң югары хезмәт хакы алучы белгечләрнең берсе. Сингапурда педагог дәүләт хезмәткәренә тиңләштерелә һәм аларныкы кебек ташламаларга ия. Анда педагогик белгечлеккә укырга керү өчен бик зур конкурс узарга кирәк. Советлар Союзы фән тармагындагы ярышны совет мәктәбе партасы артында отты, дип сөйли торган булганнар заманында АКШта. Ләкин инде совет мәктәбе белән мактанып йөреп булмый, чөнки бу вакыт эчендә шактый нәрсә югалган, шактый нәрсә алга киткән. Ә минә укытучы җәмгыятьтә беренче номерлы шәхес булсын өчен, педагогка хөрмәт күрсәтеп, аңа йөз белән борылу бик мөһим.

...«Бүген «Адымнар» мәктәбендә дүрт меңгә якын бала белем ала. Бу инде үзе үк мәктәпнең дәрәҗәсе, уку сыйфаты турында сөйли. Начар мәктәп булса, ата-ана баласын әллә кайлардан китереп укытмас иде», - диде Айдар Шәмсетдинов. Чынлап та, директор белән килешми мөмкин түгел. Биш ел эчендә шундый абруй казанган уку йорты киләчәктә дә бу исемне аклар һәм тагын да яңа үрләргә ирешер, дигән теләктә калабыз.

КҮНЕГҮ КҮЧЕРТЕП УТЫРЫП КЫНА БУЛМЫЙ

Рамил Ханнанов, дәреслекләр авторы, татар теле һәм әдәбияты укытучысы:

– Укытучының максаты – бүгенге заман баласын аңлый белү һәм аны яңа белемгә мотивацияләү, кызыксындыру уяту. Бүген укытучы үзе кызыклы булмаса, бала күңеленә ачкыч таба алмаячак. Мөгаллим дәрескә яңалык алып килсен. Мисал өчен, шул ук үзем укыткан татар теле һәм әдәбият дәресләрен карыйк. Монда укучы өчен кызык булган тау-тау яңалык табарга мөмкин! Балага теге яки бу теманы ни өчен өйрәнгәнебезне аңлата алабыз икән, дәрес нәтиҗәле уза дигән сүз. Максат бит бөтен дәреслекне ятлап чыгу түгел, аның кирәге дә юк. Безнең башта ниндидер мәгълүмат алмашып кына тора, ә балаларда ул бигрәк тә тиз бара. Шуңа күрә укытучы әлеге тизлекне тойсын. Аның дәресе динамик рәвештә үтәргә тиеш, бик күп эш алымнары куллану мөһим. Бүген күнегү күчертеп, хикәя укытып кына утырасың икән, укучыга синең фәнең дә, телең дә, тарихың да кирәкми.

БАЛАЛАРНЫ ЯРАТЫРГА КИРӘК

Ләйсән Хәсәншина, беренче категорияле инглиз, гарәп телләре укытучысы.

– Укытучының төп максаты – балаларга гыйлем биреп, аларда уңай сыйфатлар тәрбияләү, укучыларны тигез күрү. Балаларны кеше буларак яратырга, шәхес буларак хөрмәт итәргә кирәк. Шулай ук укытучы булу – ул кешеләргә хезмәт күрсәтү аша дөнья үсешенә өлеш кертү дә.

КАМИЛЛЕККӘ ЧИКЛӘР ЮК

Ләйсән Ибәтуллина, кытай теле укытучысы:

– Укытучының төп максаты – укучыны үз фәне белән мавыктыру, кызыксындыру һәм күңелсез булмау! Педагогның үз өлкәсендә белгеч булуы гына җитми, ул гел үсештә булырга, заман белән бергә атларга тиеш. Камиллеккә чикләр юк, кешенең, гомумән, шәхеснең үз өстендә эшләве – хәзерге дөнья өчен гадәти хәл. Үз эшен ихластан яратса, укытучы укучыга дус та, юл күрсәтүче остаз да була, бу исә яңа талантлар ачарга ярдәм итә.

«ПЕДАГОГИКАМНЫҢ МАНТЫЙГЫ ГАП-ГАДИ...»

Бүгенге заман мәктәбенең төп имтиханы – балаларның предметлар белән кызыксынуына, белем алу процессына теләп кушылуына ирешү. Нәкъ менә шулар һөнәр сайлаганда да, тормышта да балага яхшы старт бирәчәк. Бу санда Казандагы Лицей – инженерлык үзәге мөгаллимнәре үзләренең принциплары, казанышлары, фикерләре белән уртаклаша. Әлбәттә, бу имтиханны «бик шәп» билгесенә бирә алыр өчен, нәрсә эшләргә кирәк икәнлеге белән дә!

Диана Аксанова, өстәмә белем бирү педагогы

Балалар минем үземә дә илһам бирә...

УҢЫШЛЫ ЗАМАНЧА МӘКТӘП УЛ...

бала белем алып кына калмый, ә үз мөмкинлекләрен ача, ирекле фикер йөртә һәм гамәлләре өчен җавап бирә ала торган шәхес буларак тәрбияләнү урыны.

МИНЕМ ӨЧЕН УКУЧЫ – ИҢ БЕРЕНЧЕ ЧИРАТТА...

кабатланмас эчке дөньясы, тормыш потенциалы һәм дөньяга үз карашы булган шәхес.

МИНЕМ ТӨП ҺӨНӘРИ ПРИНЦИБЫМ – УЛ...

балаларны мәгълүмат белән эш итәргә, анализларга өйрәтү, алган бу күнекмәләрне кулланырга юл күрсәтү. Нәкъ менә шушы күнекмәләрне куллана белү бүген безнең тормышка яраклаша алуыбызны билгели дә инде.

СОҢГЫ 2-3 ЕЛДАГЫ ТӨП КАЗАНЫШЫМ – УЛ...

проектлар белән эш итү юнәлешен кертү, аны камилләштерү. Болай эшләгәндә, балаларның дөньяны күзаллавы киңәя, мөстәкыйль рәвештә карарлар кабул итәргә кызыксынуы арта, эчке ихтыяры ныгый. Бу минем үземә дә илһам бирә.

БЕЛЕМ ҮЗЛӘШТЕРҮНЕ ДӘВАМ ИТӘМ...

чөнки мәгариф һәм идарә итү өлкәсендәге заманча технологияләр уку-укыту процессын мөмкин кадәр югары дәрәҗәдә оештырырга мөмкинлек бирә.

Фото: Лицей – инженерлык үзәге архивыннан. РЕКЛАМА

Руфина Дәүләтбаева, мәгариф һәм мәдәният отличнигы, өстәмә белем бирү буенча директор урынбасары

Төп принцип – ихлас булу

УҢЫШЛЫ ЗАМАНЧА МӘКТӘП УЛ...

белем алырга өйрәтә, балалар да, укытучылар да заманнан артка калмаска тырыша торган урын. Лицей – инженерлык үзәге – нәкъ менә шундый уку йорты. Бу – ата-аналар да, укучылар да, мөгаллимнәр дә бергәләп нәтиҗәләргә ирешә ала торган зур бер йорт. Һәм бу – бик мөһим.

МИНЕМ ӨЧЕН УКУЧЫ – ИҢ БЕРЕНЧЕ ЧИРАТТА...

үземнең тәҗрибәмне уртаклаша алыр кеше, һәм бу тәҗрибә аның өчен файдалы, кирәкле булырдай итеп тапшырылырга тиеш. Без балаларны һәрвакыт үз мөмкинлекләрен иң югары дәрәҗәдә файдаланырга, мөстәкыйль карарлар кабул итәргә өйрәтергә омтылабыз.

МИНЕМ ТӨП ҺӨНӘРИ ПРИНЦИБЫМ – УЛ...

ихлас булу. Үзем белән дә, укучыларым белән дә, коллегаларым белән дә. Үз умырткама һәм үз карашыма таяну.

СОҢГЫ 2-3 ЕЛДАГЫ ТӨП КАЗАНЫШЫМ – УЛ...

балаларыбызның уңышлары. Быел профильле «Сириус» федераль проектына гариза биргән 22 лицей укучысының 9ы призёр һәм җиңүчеләр булды. Мин моны шәхси җиңүем дип тә кабул итәм, чөнки балалар белән без бу юлны проектны презентацияләүдән башлап, җиңүнең үзенә чаклы узабыз. Бәйге булсынмы ул, хыялдагы уку йортына керүме.

БЕЛЕМ ҮЗЛӘШТЕРҮНЕ ДӘВАМ ИТӘМ...

үз-үземне даими үстерергә тырышам: күп укыйм, коллегаларның сайтларын күзәтеп барам, яңа юнәлешләрне өйрәнәм. Яхшы белем – ул коллегалар белән аралашу, яңа эмоцияләр алу, инде ияләшкән нәрсәләргә бөтенләй икенче караш белән карый башлау. Һәр яңа белем укучыларым белән бер телдә сөйләшергә өйрәтә.

Миләүшә Закирова, математика укытучысы

Мөгаллимнең кыйммәте – укучысының үсешендә

УҢЫШЛЫ ЗАМАНЧА МӘКТӘП УЛ...

мөгаллимнәр дә, укучылар да үзләренең иң яхшы идеяләрен тормышка ашыра ала торган мөмкинлекләр мәйданы.

МИНЕМ ӨЧЕН УКУЧЫ – ИҢ БЕРЕНЧЕ ЧИРАТТА...

илһам чыганагы. Аның уңышларын һәм үсешен күзәтеп торып, үземнең педагогика юнәлешендәге хезмәтемнең дә кыйммәтен тоям.

МИНЕМ ТӨП ҺӨНӘРИ ПРИНЦИБЫМ – УЛ...

һәр укучыны чын-чынлап аңлый белү. Баланы китап белән чагыштырып була – аның ак, саф битләренә сезнең күз алдыгызда тарих языла, аны сез бергә язасыз. Минем бурычым – бу китап тиешенчә язылып, бәхетле язмышка ия булсын.

СОҢГЫ 2-3 ЕЛДАГЫ ТӨП КАЗАНЫШЫМ – УЛ...

физика, математика һәм информатика укытучыларына ярдәм итү максаты белән Татарстан Республикасында «Физика-математика буенча алгарыш 2025» проекты кысаларында грантка ия булу, шулай ук югары квалификация категориясен алу. Һәм укучыларымның БДИда, олимпиадаларда ирешкән уңышлары. Моннан тыш, алар дәресләрдә ничек катнаша – монысы да гаять әһәмиятле.

БЕЛЕМ ҮЗЛӘШТЕРҮНЕ ДӘВАМ ИТӘМ...

«Укытасың икән, үзең дә гел укуда бул» – әнә шул принципны бик дөрес дип саныйм. Хәзерге вакытта Новосибирск шәһәрендә Россия фәннәр академиясе оештырган программаны узам. Ул лекцияләр, гамәли дәресләр, семинарлар һәм экскурсияләрне үз эченә ала. Россия төбәкләреннән җыелган педагог-математикларның тәҗрибә уртаклашуында катнашу – бик зур белем.

Ранил Гобәйдуллин, физика укытучысы, өстәмә белем бирү буенча педагог

Укучыларыбызның казанышлары белән горурланам

УҢЫШЛЫ ЗАМАНЧА МӘКТӘП УЛ...

бүгенге көннең яңа таләпләренә һәм технологияләренә туры килер өчен, даими үсештә булган мәгариф учреждениесе.

МИНЕМ ӨЧЕН УКУЧЫ – ИҢ БЕРЕНЧЕ ЧИРАТТА...

без, мөгаллимнәр, мөстәкыйль рәвештә зур иҗади һәм интеллектуаль казанышларга ирешә ала торган итеп тәрбия бирә алган шәхес.

МИНЕМ ТӨП ҺӨНӘРИ ПРИНЦИБЫМ – УЛ...

укучыны үз белемнәренә таянырга һәм үз-үзенә, бу дөньяга кирәклегенә ышанырга өйрәтү.

СОҢГЫ 2-3 ЕЛДАГЫ ТӨП КАЗАНЫШЫМ – УЛ...

2019–2020 елларда алган «Безнең яңа мөгаллим» гранты. 2025 елда Лаеш авиация техникумы базасында «Пилотсыз авиация системаларын эшләү, җитештерү һәм куллану өлкәсендә педагогика хезмәткәрләрен гамәли әзерләү» программасы буенча һөнәри белем алдым. Укучыларымның мәртәбәле бәйгеләрдә катнашуы, җиңү яулавы да бик әһәмиятле: мәсәлән, Королёв исемендәге төбәкара конференция, йә булмаса Симонов исемендәге халыкара конференция, КАИ уздыра торган конференцияләр.

БЕЛЕМ ҮЗЛӘШТЕРҮНЕ ДӘВАМ ИТӘМ...

һөнәри һәм шәхси яктан үсәр өчен бу бик кирәк. Даими рәвештә үз юнәлешемдә, ягъни физика буенча квалификацияне күтәрә торган курслар узарга тырышам. Алай гына да түгел, яңа технологияләр буенча да, шул исәптән – мәгариф өлкәсендәге мәгълүмати технологияләргә караган өлкәдә.

Раушания Юнысова, башлангыч сыйныф укытучысы

Мәктәп – сиңа ышаныч күрсәтелә торган урын

УҢЫШЛЫ ЗАМАНЧА МӘКТӘП УЛ...

укытучылар, балалар һәм әти-әниләр бер максатка ирешер өчен тырыша торган иптәшләрчә бердәмлек урыны. Биредә һәркем үзен коллективның әһәмиятле бер өлеше дип исәпли, ә балалар ярдәм, кайгыртучанлык һәм аңлау атмосферасына килеп эләгә.

МИНЕМ ӨЧЕН УКУЧЫ – ИҢ БЕРЕНЧЕ ЧИРАТТА...

таланты һәм мөмкинлекләр киңлеге булган уникаль шәхес. Минем бурычым – балаларга булган сәләтләрен үстерергә ярдәм итү, үз-үзләренә һәм көчләренә ышаныч тәрбияләү.

МИНЕМ ТӨП ҺӨНӘРИ ПРИНЦИБЫМ – УЛ...

«Зыян китермә». Ә бу баланы чын күңелдән яратуны күздә тота, аны нинди бар, шундый итеп кабул итүне. Шалва Амонашвили сүзләрен китерергә телим бу урында: «Син – кечкенә, ә мин зур бала. Менә шул минем гади генә педагогикам. Сиңа – минем белән, миңа синең белән рәхәт. Педагогиканың гади генә логикасы бар».

СОҢГЫ 2-3 ЕЛДАГЫ ТӨП КАЗАНЫШЫМ – УЛ...

сыйныфта бер-береңә ышана һәм таяна алырдай мохит тудыру. Аңардан башка педагог белән укучы арасында аралашу туа алмый.

БЕЛЕМ ҮЗЛӘШТЕРҮНЕ ДӘВАМ ИТӘМ...

soft skills, «сыгылмалы» күнекмәләр буенча. Бүгенге заманда адаптациягә әзер булу, даими рәвештә үзеңне үстерү, вакытка һәм үз ролеңә тәңгәл калу – бик мөһим сыйфатлар. Бары тик үз эше белән кызыксынган, мавыккан, балаларны да җәлеп иткән укытучы гына аларны үз артыннан ияртеп бара ала, дип уйлыйм.

Эльмира Митрофанова, башлангыч мәктәп буенча директор урынбасары

Уңышка һәркем ирешә ала

УҢЫШЛЫ ЗАМАНЧА МӘКТӘП УЛ...

бала үзен иркен, хәвеф-хәтәрсез мохиттә дип исәпли алган һәм яңалыкка омтылып, ялгышлар ясарга курыкмый торган урын. Без белем бирү процессын балалар үз каршыларында нинди офыклар ачылуын күрә торган итеп оештырырга тырышабыз: уңыш якында гына, аңа һәркем ирешә ала!

МИНЕМ ӨЧЕН УКУЧЫ – ИҢ БЕРЕНЧЕ ЧИРАТТА...

аңа ышанып була һәм үзе дә безгә ышана ала торган кеше. Укучы үзен уку-укыту процессының тулыканлы вәкиле итеп тоярга тиеш – үз ачышлары, сораулары, мавыгулары белән.

МИНЕМ ТӨП ҺӨНӘРИ ПРИНЦИБЫМ – УЛ...

бала үзен төрле рольләрдә сынап карый ала торган ышанычлы һәм ярдәмләшү мохите тудыра алу. Без «лингво» белән «техно»ны бербөтенгә кушарга омтылабыз, академик катгыйлык белән иҗади омтылышларны берләштерәбез. Шул рәвешле, балалар үзләрен математика өлкәсендә дә, сәхнәдә дә иркен итеп тоя.

СОҢГЫ 2-3 ЕЛДАГЫ ТӨП КАЗАНЫШЫМ – УЛ...

«Кечкенә мәктәп»нең гаиләләр әйләнеп кайта торган мохиткә әверелүе. Бездә хәзерге вакытта инде башлангычны тәмамлап чыккан укучыларыбызның кечкенә энекәшләре белән сеңелкәшләре белем ала. Бу – ата-аналарның чын мәгънәсендә ышанычы һәм безнең эшләгән эшләребезгә югары бәясе.

БЕЛЕМ ҮЗЛӘШТЕРҮНЕ ДӘВАМ ИТӘМ...

балаларны да, ата-аналарны да, мөгаллимнәрне дә тыңларга һәм ишетергә өйрәнәм. Уку йортыбыз киләчәк мәктәбе булып калсын өчен, иң беренче чиратта, үзебезне үстерергә кирәк – педагогикадан башлап, цифрлы ысулларга кадәр. Шулчакта гына коллегаларга да, балаларга да үрнәк була аласың.

Татьяна Майорова, югары категорияле башлангыч сыйныф укытучысы, башлангыч сыйныфлар укытучыларының методик берләшмәсе җитәкчесе, «Сәләтле бала» программасының кураторы

Без бергә үсәбез

УҢЫШЛЫ ЗАМАНЧА МӘКТӘП УЛ...

һөнәри яктан югары квалификациягә ия мөгаллимнәр командасы эшчәнлегенә бәйле рәвештә укучыларның потенциалы ачыла торган урын. Коллективта бердәм кыйммәтләр һәм уртак эш юнәлеше булганда, балалар барлык өлкәләрдә дә ярдәм ала. Математика булсынмы ул, телләр үзләштерүме, иҗади омтылышлармы, тикшеренү эшчәнлегеме...

МИНЕМ ӨЧЕН УКУЧЫ – ИҢ БЕРЕНЧЕ ЧИРАТТА...

үз кызыксынулары, мөмкинлекләре һәм холык-фигыле булган шәхес. Һәр баланың үз темпы, юлы бар, педагогның бурычы – балага ул юлны үз ритмында үтәргә, моннан кала, уку белән мавыгуын, шуннан ләззәт алуын да саклап калырга булышу.

МИНЕМ ТӨП ҺӨНӘРИ ПРИНЦИБЫМ – УЛ...

Укыткан преметыңны ярату, укыткан укучыларыңны ярату. Педагогның күзләре янган очракта гына укучылар да кабынып, кызыксынып китә.

СОҢГЫ 2-3 ЕЛДАГЫ ТӨП КАЗАНЫШЫМ – УЛ...

югары квалификация категориясен алу, «Сәләтле бала» проектын уңышлы тормышка ашыру. Олимпиада белән бәйгеләрдә укучыларымның җиңүләре, аларның саны артып торуы. Балалар үз көчләренә ышанырга өйрәнә, югары максатларга ирешергә курыкмый. Димәк, методика чыннан да дөрес сайланган, дигән сүз.

БЕЛЕМ ҮЗЛӘШТЕРҮНЕ ДӘВАМ ИТӘМ...

бигрәк тә, яңа методикалар һәм юнәлешләрне. Нәкъ менә яңаны куллану укучыларның мөмкинлекләрен ачарга, авырлыкларны җиңеп чыгарга булыша. Моннан тыш, мин үзем дә балалардан күп нәрсәгә өйрәнәм – аларның сораулары дәресләрне оештыру юнәлешләрен бирә, димәк, барыбыз бергә бу процесстан ләззәт алачакбыз...

УҢЫШКА ЮЛ БИРЕДӘ БАШЛАНА

Евгения Чеснокова

Тулпар урамында урнашкан күппрофильле 181 нче мәктәп – Казандагы иң яңа уку йортларының берсе, аны 2017 елда гына ачтылар. Дүрт блоктан торган иркен бинада заманча җиһазландырылган якты сыйныф бүлмәләреннән тыш, берничә спорт залы, ике бассейн, бию студиясе бар...

«Биредә без, коридорның рекреация өлешен бүлеп, музыка класслары ясадык, ә монда ашханә – пешекчеләр үзебезнеке, өстәлгә яңа пешкән ризыклар гына куела...» Директор Динә Абдуллина зур горурлык белән миңа мәктәпне күрсәтеп йөри. Аның һәр сүзеннән барысы да аңлашылып тора: ул мәктәпнең нигезенә нинди кирпеч салынганлыгына кадәр белә. Һәм бу бер дә арттыру түгел: Динә Альберт кызы белеме буенча педагог кына түгел, ә инженер да. Аны мәктәп бинасы Азинодагы яңа төзелгән биек йортлар уртасына салына башлаганда ук директор итеп куялар. Динә Абдуллина сызымнарны, конструкцияләрне җентекләп үзе өйрәнеп чыга, кайдадыр үзгәрешләр кертүне дә сорый.

«Әлбәттә, өр-яңадан төзү җиңел түгел. Аның каравы яңа бинада эшләү канатлар куя», – ди Динә Абдуллина.

Директорны яңа урында педагогларның менә дигән командасын туплый алуы да илһамландыра. Сер түгел, бүген безнең мәктәпләргә укытучылар җитми. Монда директорның фикердәшләрен туплый алуы – үзе бер талант. Һәрбер укытучының үз педагогик кредосы бар, һәркайсы тәгаен бер өлкә өчен җавап бирә, һәм боларның барысы да уртак нәтиҗәгә китерә.

БАЛАЧАК – ҖИТДИ ЧОР УЛ

Театр кием элгеченнән башланса, мәктәп – башлангыч сыйныфлардан. Проект буенча, 181 нче мәктәп 1224 кешегә исәпләнгән. Чынлыкта (микрорайон бик зур бит!) биредә 900 балага артыграк укый. Һәм укучыларның яртысы диярлек – башлангыч сыйныфлар. Быел һәм узган елларда беренчеләрне җидешәр сыйныф җыйганнар, өченче сыйныфта – ун параллель. Зур мәктәп

Фото: 181 нче мәктәп администрациясеннән алынды. РЕКЛАМА

эчендә үзенә бер аерым уку йорты дияргә дә була. Болар янына әзерлек курсларына йөри торган булачак беренчеләрне дә кушсаң...

Шушы шактый саллы бүлеккә завучлар Наталья Чумарова белән Юлия Сорокина җитәкчелек итә. Алар шуңа ышана: балачак – ул «кеше тормышының башлангыч чоры» гына түгел, ә үзе бер мөстәкыйль тормыш – үзенчәлекле, кабатланмас. Баланы алга таба да укуын дәвам итәргә өйрәтергә, аңарда Белемгә мәхәббәт уятырга, яшьтәшләре һәм өлкәннәр белән аралашуда тотрыклы күнекмәләргә нигез салырга кирәк.

Наталья Петровна һәм Юлия Владимировна һәрбер баланы, аның әти-әнисен, гаилә хәлен белә. Беренчеләр, барлык шушы мәгълүматка психологик анализ ясау нигезендә җыйналып, һәрбер сыйныфта бала үзен уңайлы хис итәрлек итеп туплана.

Биредә, башлангыч мәктәптә үк, бала үз талантын үстерү мөмкинлеген ала. Башлангычтагы өстәмә белем – музыка да, бию дә, спорт секцияләре дә, инженерлыкка әзерлек тә (әйе, нәниләрдә дә), информатика, телләр... Быел, мәсәлән, кытай теле дәресләре керә башлаган.

Ата-аналар белән тыгыз элемтә – мәктәпнең уңыш нигезе. 181 нче мәктәптә моны яхшы аңлыйлар. Педагоглар укучыларының гаиләләренә һәр мәсьәләне хәл итәргә әзер булулары һәм ярдәмнәре өчен рәхмәтле. Үз чиратында, эшли торган әти-әниләргә уңайлы булсын дип, мәктәптә нәниләргә тулы көн сыйныфлары да ачылган. Алар биредә укый да, ял да итә, өч тапкыр ашый да, өстәмә рәвештә үзләре теләгән дәресләргә дә йөри.

ИНЖЕНЕРЛАРГА ӨСТЕНЛЕК

Башлангыч мәктәптә үк өстәмә дәресләр аша салынган профильле әзерлек нигезләре балаларга урта мәктәптә булачак һөнәрләренә таба ныклы адымнар ясарга ярдәм итә. 181 нче мәктәптә киң колачлы инженерлык белеменә зур игътибар бирелә. Бу турыда безгә директорның уку-укыту буенча урынбасары Резеда Закирова сөйли. Резеда Илдус кызы табигый-фәнни цикл предметлары өчен җаваплы. Ул үзенең педагогик бурычын мәгълүмати технологияләр дөньясы белән табигать фәннәре аша балаларны тиз үзгәрүчән тормышка иҗади карарга, яңа туган сорауларга җавапларны тиз арада табарга өйрәтүдә күрә.

«Инженерлар Казаны» проекты кысаларында, инженерлык лицее һәм Казан милли тикшеренү техник университеты – Казан авиация институты белән хезмәттәшлектә без инженер сыйныфлары ачтык, – дип сөйли Резеда Закирова. – Бишенче сыйныфтан башлап, балалар физика нигезләрен, программалауны, радиоэлектрониканы, 3D-конструкторлауны өйрәнә. Алар инглиз телен тирәнтен үзләштерә, чөнки ул – заманча фән теле. Тагын бер мөһим юнәлеш – сигезенче сыйныфтан «Промхимтех» проекты башлана. Биредә табигать фәннәренә – химия, биологиягә басым ясала. КМТТУ – КХТИ белән дә хезмәттәшлектә эшлибез, укытучылар арасында химия фәннәре кандидатлары да бар».

Шуңа күрә 181 нче мәктәпне тәмамлаучылар арасында химия һәм бик тә катлаулы профильле математика буенча йөз балл җыйган укучыларның булуы бер дә гаҗәп түгел.

Теоретик әзерлектән тыш, укучыларның югары уку йортларына һәм шул профильдәге предприятиеләргә экскурсияләргә йөрүен дә әйтергә кирәк. Күптән түгел «Сибур»ның бүлекчәсе булган «Казан Оргсинтез» заводына экскурсиядән үсмерләр генә түгел, мәктәп директоры да бик канәгать калган. Биредә профильле әзерлеккә шулкадәр җитди игътибар булу мәктәп укучыларының алга таба һөнәр сайлавына зур йогынты ясавын әйтеп тору да кирәкмидер.

ҮСЕШ ГАРМОНИЯЛЕ БУЛЫРГА ТИЕШ

181 нче мәктәптә профориентация буенча эш инженерлык белгечлекләре белән генә чикләнми. «Безнең югары сыйныф укучыларының эшче һөнәре буенча сертификат алу мөмкинлеге дә бар», – дип сөйли уку-укыту буенча директор урынбасары Динә Хөснетдинова.

Чыннан да, ТИСБИ һәм Россия кооперация университеты белән хезмәттәшлектә мәктәптә шимбә көннәрендә флористика, визаж, кунакханәләр эше, IT-белгечлек, ясалма фәһем һәм БПЛА белән идарә итү буенча һөнәри сыйныфлар эшли. Шул рәвешле мондый сыйныфларда укыган укучылар кулларына аттестат алу белән эшли башларга да мөмкин.

Динә Хөснетдинова спорт тәрбиясе буенча да җаваплы. Монда да мәктәпнең горурланырлык нәтиҗәләре бар. Бадминтончылар командасы быел Казан мэры кубогын яулаган. Шәһәр буенча ярышларда футбол, волейбол, баскетбол командалары даими рәвештә призлы урыннар яулый. Мәктәпнең ике бассейнында барлык укучылар да шөгыльләнә ала, тагын әле синхрон йөзү төркемнәре бар, анда шөгыльләнүче 12 кыз – Татарстанның җыелма командасы составында. Менталь дәрәҗәдә генә түгел, ә физик яктан да гармонияле шәхес тәрбияләү – 181 нче мәктәпнең тагын бер принцибы.

МӘКТӘП БӘЛӘКӘЙ ИЛ КЕБЕК УЛ

Уку елы башлануга 181 нче мәктәптә гадәттә көзге ярминкә уза. Быел аның темасы «Татар бистәсе» булган. Һәрбер сыйныф эти-әниләре белән берлектә, милли традицияләргә йөз тотып, үз мәйданчыгын оештырган. Милли блок өчен мәктәптә завуч Фәния Шәйхетдинова җавап бирә. Ул зур илгә мәхәббәт туган телеңә һәм туган мәдәниятеңә мәхәббәттән башлана, дигән ныклы фикердә.

Фәния Фоат кызы хаклы рәвештә, милли традицияләргә мәхәббәтне гаиләдән башка тәрбияләп булмый, дип ышана. Шуңа да төрле бәйрәмнәр һәм чаралар әзерләгәндә, ул һәрвакытта да эти-әниләргә мөрәҗәгать итә. Алар бик теләп ярминкәләрдә, фестивальләрдә, концертларда катнаша. Мәсәлән, февральдә, Халыкара туган тел көне билгеләнгәндә, мәктәптә «Халыклар дуслыгы» фестивале уздырыла. Анда балалар эти-әниләре белән милли костюмнар киеп килә, милли ризыклар әзерли, концертлар куя. Әйе-әйе, эти-әниләр дә милли костюмнар кия, хәтта мәктәп сәхнәсендә бии дә! Руслар, татарлар, тувалар, азәрбайҗаннар – үзе дә бәләкәй генә ил кебек мәктәп бу көнне бигрәк тә җете төсләр белән балкый.

Сүз уңаеннан, Фәния Шәйхетдинова үзе дә мондый халык бәйрәмнәренә аерым бер төс бирә: мондый чаралар узган көнне ул мәктәпкә татар күлмәгеннән һәм калфактан килә. Ә чаралар күп: Тукай атналыгы, Пушкин атналыгы, Майчабу бәйрәме, Печән базары... Укучылар милли мәдәнияткә үз иҗатлары аша гына якынаймый. Алар өчен театрларга сәфәрләр дә оештырыла, Татарстан Республикасы Дәүләт җыр һәм бию ансамбле, мәсәлән, даими рәвештә балалар, укытучылар һәм ата-аналар каршында чыгыш ясар өчен Тулпар урамына килә. Ул чагында актлар залында алма төшәр урын да калмый.

Үзләре куйган спектакльләр дә тулы заллар җыя – мәктәптә рус, татар һәм инглиз телләрендә театр студияләре эшли. Студия артистларының берсе быел Казанның театр училищесына укырга кергән, һәм укытучылары аның зур сәхнәдә йолдыз булып балкыячагына тамчы да шикләнми. Шул рәвешле милли традицияләр һәм мәдәният – өстәмә белем бирү генә түгел, киләчәктә һөнәри баскычка илтүче юл да.

ВАТАНПӘРВӘРЛЕК СҮЗДӘ ГЕНӘ ТҮГЕЛ

«Уку ничек кенә мөһим булмасын, безнең бурыч – Россиянең чын ватанпәрвәрләрен тәрбияләү дә», – дип сөйли тәрбия эшләре буенча директор урынбасары Татьяна Гаврилова.

Патриотик тәрбия – мәктәп тормышы мозаикасындагы тагын бер бизәк, аннан башка балалар белән тулы канлы эшләү турында сөйләп булмас иде. Әлбәттә, 181 нче мәктәптә «Мөһим нәрсәләр турында сөйләшү»гә зур игътибар бирәләр. Билгеле, һәр дүшәмбе биредә Россия һәм Татарстанның дәүләт флагларын күтәрүдән башлана – монда Юнармия отрядында укучыларның Махсус хәрби операциядә һәлак булган Россия Герое Владислав Мариненко исемендәге байраклы төркеме катнаша.

Сүз уңаеннан, 181 нче мәктәп Юнармия йорты булып тора. Монда балалар һәм үсмерләр башлангыч хәрби әзерлек күнекмәләренә ныклап өйрәнә. Мәктәп башка уку йортлары белән тәҗрибә уртаклашу

мәйданчыгы санала. Быел мәктәп «Ватанны саклау һәм куркынычсызлык нигезләре» кабинетын җиһазландыру буенча республикада иң яхшысы дип табылган. Иң яхшы техника, шул исәптән виртуаль тир белән җиһазландырылган әлеге кабинет һәм янәшәдә урын алган Чик сакчылары даны музее республиканың жюри әгъзаларында яхшы тәэсир калдырган.

181 нче мәктәптә оештырылган юнармия хәрәкәтендә югары сыйныф укучылары гына түгел, түбәнрәк сыйныфлар да катнаша. Юнармия отрядлары даими рәвештә Казанда уздырыла торган 9 Май парадында катнаша, тагын алар... бии дә әле! Юнармиячеләр – шәһәрдә үткәрелә торган төрле балларда даими катнашучылар да. Мәктәпнең аерым бер горурлыгы – барабанчы кызлар отряды, алар да шулай ук төрле митинг һәм парадларда, махсус хәрби операция каһарманнарына багышланган мемориаль такталар ачылышында чыгыш ясый.

Әмма ватанпәрвәрлек – конкурслар һәм парадлар гына түгел әле ул. Укучылар эти-әниләре белән берлектә махсус хәрби операциядәге сугышчыларга хатлар яза, даими рәвештә армия өчен хәйрия акцияләрендә катнаша, традицион көзге ярминкәдән кергән керемне дә алар тагын бер мәртәбә фронтка посылкалар җыюга ярдәм буларак туплаган. Алар МХО зонасында калган хайваннарга азык сатып алып җибәрүне дә оештыра. Кече туганнарга мәхәббәт – шулай ук ватанпәрвәрлек, әхлакый тәрбия.

ҺӘРНӘРСӘГӘ ӨЙРӘНЕРГӘ ҺӘМ ҺӘРВАКЫТТА УКЫРГА

Әлбәттә, педагоглар командасы – завучлар гына түгел, ә укытучылар да. Завучлар үзләре биредә – укытучы да, сыйныф җитәкчеләре дә. Ике меңнән артыграк укучыга 116 укытучы белем бирә. Һәркайсының эш күләме бик зур, әмма мәктәпнең җайга салынган механизмы менә дигән итеп эшли. Үзенең һәр укытучысы турында Динә Абдуллина туктаусыз сөйли ала. Биредә һәрбер укытучы үз уен коралында шәп итеп уйный, бөтенесе бергә кушылгач, оркестр килеп чыга. Кызганыч, барысын да бер язмада санап чыгу гына мөмкин түгел...

«Читтән караганда, барысы да үзеннән-үзе оештырыла кебек күренә ул, – ди Динә Альберт кызы. – Әмма алай гына түгел. Бездә һәркем үзенең нәрсә өчен җаваплы икәнен төгәл белә. Иң мөһиме – менә шушылай, уртак нәтиҗәгә йөз тотып эшләү һәркемгә ошый. Без көн саен мәктәпкә шатланып киләбез. Чөнки балалар белән эшләү – безнең изге бурыч».

Динә Альберт кызы үзе мәктәпкә иртәнге җидедә килә. Эшен төгәлләп, – кайчан ничек килеп чыга инде – кичке сигездән дә иртәрәк кайтырга чыкмый. Укытучылар көне алдыннан, педагоглар бию әзерләгәндә – тагын да соңрак. Әйе-әйе, укучыларның һәм аларның эти-әниләренең үрнәге белән илһамланып, директор үзе дә укытучылар бәйрәмендә мәктәп сәхнәсенә биергә чыкты. Моның өчен хореографка берничә атна дәвамында репетициягә йөргән.

«Иҗат – бик мөһим ул. Без балаларны да шуңа өйрәтергә телибез, – ди Динә Альберт кызы. – Аларга бит яңа, һәрдаим үзгәреп тора торган дөньяда яшисе. Алар иҗади фикер йөртергә, үзгәрешләрдән курыкмаска тиеш. Гомер буена уку – бүгенге мәктәп укучыларында тәрбияләнергә тиешле принцип ул».

УҢЫШ РИТМЫНДАГЫ ЮБИЛЕЙ

Ксения Сёмина

Казанның 187 нче күппрофильле лицееның биш ел эчендә Кытайда кызыксыну уятырлык тәҗрибә туплауга ирешүе турында сөйлибез бу санда.

САЙЛАУ РИТМЫНДА

Үз куллары белән эшләнгән вертолёт макеты, винт канатлы машинаның тышчасын ремонтлау күнекмәләре – 9И инженерлык классы укучылары Казан вертолёт заводының белем бирү программасын әнә шундый күзгә күренеп торган уңышлар белән тәгәлләгән. Бүген лицейның 1-9 сыйныфларында 12 инженерлык сыйныфы бар. Һәр сыйныф өчен программалар укучыларның яшенә һәм белем дәрәҗәсенә туры килерлек итеп эшләнгән. Әлеге программаларның сыйфаты һәм педагогларның тәҗрибәлелеге, лицейда төгәл фәннәрне укытуның гомуми югары дәрәҗәсенең нәтиҗәләре буларак, чыгарылыш укучыларының күбесе технологияләр өлкәсендә һөнәр сайлый.

– Инженерлык сыйныфында мин техник дисциплиналарда, аерым алганда, 3D-проектлау юнәлешендә тирәнтен белем алам. Киләчәгемне шул өлкә белән бәйләргә җыенам. Күнекмәләремне камилләштереп, төрле олимпиадаларда җиңәргә ниятлим, Мәскәү яки Санкт-Петербургның техник вузына укырга керергә планлаштырам, – ди 9И сыйныфы укучысы Эмиль Буреев.

Инженерлык сыйныфлары лицейның күппрофильле системасының бер өлешен тәшкил итә. Инженерлыктан тыш, монда медиа, кадетлык, психология-педагогика, экология, метрология юнәлешләре дә эшли.

РИТМ Казан мэры Илсур Метшинның тәкъдиме белән күппрофильле уку йортына әйләнеп куя. Булачак лицей концепциясе белән танышканда, Илсур Рәис улы төрле юнәлештәге сыйныфлар булдыру РИТМга үзендәге белем бирү потенциалын максималь рәвештә тормышка ашырырга мөмкинлек тудырачагын билгеләп үтә.

Фото: 187 нче лицей җитәкчелегеннән алынды. РЕКЛАМА

«Без сезнең белән горурланабыз!» – диде Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов «Профессионаллар», «Абилимпикс-2024» чемпионатларында җиңүчеләр һәм призёрлар белән очрашуда һәм шулай ук бу елның февралендә РИТМ лицеенда мөгаллимнәр белән остазларны Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре белән бүләкләү тантанасында.

КОМПАС РИТМЫНДА

– Без балаларның тормышта кирәкле булуын һәм төрле ситуацияләргә җайлаша алуларын телибез. Моның өчен техник күнекмәләрне, социаль компетенцияләрне һәм фундаменталь белемнәрне үстерү бертигез дәрәҗәдә мөһим. Күппрофильле булу безгә белгечлекнең тиешле дәрәҗәдә өйрәтелүен тәэмин итәргә һәм һәр лицей укучысына сайлау мөмкинлеге тудырырга юл ача, – ди лицей директоры Гөлнара Галиева.

Мондый сайлау иреге еш кына балалар өчен юл күрсәтеп торган маякка әйләнә. Профильле сыйныфларны тәмамлаучылар, югары уку йортына кергәндә, киләчәк белгечлеге белән инде чын мәгънәсендә мавыккан була.

– Лицейда психология-педагогика сыйныфында укып, вожатый һөнәрен үзләштерүемә һәм бу хакта рәсми таныклык алуыма бик шат. Без мәгариф департаменты проектларын эшләдек, грант конкурсларында катнаштык – бу җитди әзерлек таләп итә торган яңа күнекмә иде, – ди Казан федераль университетының Психология һәм мәгариф институты студенты, РИТМны 2024 елда тәмамлаган Анна Зуевская. – Лицей дөрес юнәлеш алырга ярдәм итте. 11 нче сыйныфта мин ике юл – спорт һәм психологияне сайладым һәм аларны берләштерә алачагымны аңладым. Хәзер гомуми психология кафедрасында укыйм һәм спорт психологиясе юнәлешендә үсәргә телим.

ОСТАЛЫК РИТМЫНДА

– Спорт белән актив шөгыльләнүче яки бу юнәлештә беренче адымнарын гына ясаучы һәркемгә теләгем шул: үзүзегез белән көн саен көрәшегез, ялкаулыкка каршы торыгыз, буш вакытыгызны гаджетларда уздыру теләген җиңәргә өйрәнегез. Әгәр чыннан да уңышка ирешергә телисез икән, һәрвакыт каршылыкларны җиңүгә, максималь нәтиҗәгә ирешүгә омтылыш булдырырга һәм төп игътибарыгызны куелган максатка юнәлтергә кирәк. Тырыш хезмәт нәтиҗә бирә. Спортта гына түгел, тормышның теләсә кайсы өлкәсендә дә шулай, – дип мөрәҗәгать итә лицей укучыларына Россия Олимпия комитеты президенты Станислав Поздняков. Ул РИТМ укучыларына бу сүзләрне узган елның февралендә Олимпия чемпионнары Евгений Тищенко һәм Анастасия Назаренко, Татарстан Олимпия комитеты рәисе Марат Бариев һәм ТР спорт министрының беренче урынбасары Хәлил Шәйхетдинов белән бергә лицейга килгәч әйтте.

Мондый бик күп кызыклы чаралар уздыруда лицейда эшләп килгән Өстәмә белем бирү үзәгенең дә өлеше зур. Аның составына социаль-гуманитар, техник юнәлешләрдәге, спорт, сәнгать, техника, табигать фәннәренә йөз тоткан 27 берләшмә керә. Лицейдан чыкмыйча гына, балалар яраткан шөгыльләре белән әвәрә килә алалар. Андый шө-

РӘИС ШӘЙХЕЛИСЛАМОВ, Казан федераль университетының Педагогик осталык югары мәктәбе директоры:

– Бүген функциональ грамоталылыкны формалаштыру белем бирүнең сыйфат күрсәткече булып тора, һәм бу яктан РИТМ югары дәрәҗәгә иреште. Коллектив яңа методикаларны кабул итү генә түгел, ә укучыларның функциональ грамоталылыгын үстерү өчен мохит булдырды. Ул шартларда белемнәр дәрестә дә, дәрестән тыш эшчәнлектә дә гамәли күнекмәгә әверелә. Бу тәҗрибә инде Татарстаннан читтәге мәктәпләрдә дә кызыксыну уятты һәм Россия мәгариф академиясе конференциясендә тәкъдим ителде. РИТМ – киләчәк мәктәбе ул. Анда балалар тормыш өчен кирәкле тиңсез ресурсны үзләштерә.

гыйльләр арасында кытай телен өйрәнү, веб-проектлар ясау һәм мини-футбол һ.б. бар.

Лицейда өстәмә белем алу бик популяр. Статистика буенча, бу дәресләргә РИТМ укучыларының 114% ы йөри. Бу популярлыкның сәбәбе шунда: барлык 27 юнәлешнең дә педагоглары – үз эшләре белән ихлас мавыккан белгечләр.

– Балалар бакчасы, мәктәп булсынмы, югары уку йорты булсынмы, ата-ана үз баласының иң яхшы, иң тәҗрибәле мөгаллимнәрдә белем алуын тели. Өстәмә белем бирү өчен бу бигрәк тә мөһим: кече яшьтән һөнәр сайлау мәсьәләсе нәкъ менә шушында тормышка ашырыла. Безнең педагоглар, анализлап, ирешерлек максатлар куя белә, укытуның заманча технологияләрен куллана ала. Чөнки, Константин Ушинский әйткәнчә: «Оста янында гына яңа оста үсеп чыга ала», – ди Үзәк җитәкчесе Чулпан Насыйбуллина.

ЯРДӘМ РИТМЫНДА

Белем бирү программаларын җентекләп, энә күзеннән үткәреп җыю, профильле педагогларны җәлеп итү, Татарстан һәм Россиянең алдынгы югары уку йортлары һәм предприятиеләре белән хезмәттәшлек итү – РИТМ коллективының мондый бинаһая зур хезмәте нәтиҗә бирми калмый: 2024 елда чыгарылыш сыйныф укучыларының барысы да бердәм дәүләт имтиханын уңышлы тапшырган, 70% тан артыгы республикадагы уртача дәрәҗәдән югарырак балл җыйган, ә лицейнең берничә укучысы 100 балл алуга ирешкән. Сүз уңаеннан, лицейда хәтта имтиханнар тапшыруга да команда проекты, уртак эш итеп карыйлар.

– Без балалар өчен, аларның әзерлек дәрәҗәсен исәпкә алып, төркемләп консультацияләр һәм практикумнар үткәрәбез, БДИ форматында даими сынау күнегүләре оештырабыз. Лицей югары уку йортлары һәм дәүләт йомгаклау аттестациясен тикшерүче белгечләр белән хезмәттәшлек итә. Бу исә лицей укучыларына сынаулардагы таләпләргә җайлашуда булыша. Психологик ярдәм дә оештырабыз: педагог-психологлар имтихан бирәчәк укучыларга каушаудулкынлануны җиңәргә һәм уңышка ышаныч булдырырга булыша, – ди укуукыту эшләре буенча директор урынбасары Гөлназ Хөббетдинова.

ҖИҢҮ РИТМЫНДА

Уңыш – РИТМның синонимы ул. Уңыш энергиясе, лицей мохитен биләп алып, балаларга, ата-аналарга, педагогларга куйган максатларына ирешергә ярдәм итә, хәтта әлеге максатларга илтә торган юлда киртәләр тулып ятса да. Бервакыт лицей укучысы «Профессионаллар» чемпионатына баргач, инде ярыш мәйданчыгында чакта үзенә салкын тигәнлеген сизеп ала. Беренче көн биремнәрен үтәгәннән соң, яшүсмер, гаиләсе һәм остазлары белән киңәшләшеп, бәйгедә чыгышын туктатырга һәм өйгә кайтып китәргә дигән катлаулы карар кабул итә. Берникадәр вакыттан соң оештыручылар аны медаль алырга чакыра. Беренче көнне ул шулкадәр яхшы чыгыш ясаган ки, кирәкле санда балл җыюга ирешкән.

«Кырыс» күнекмәләр белән бергә лицей укучылары инициативалылык, сыгылмалылык, җаваплылык, карарлар кабул итә белү һәм үзеңне кыю рәвештә күрсәтә алу кебек «йомшак» күнекмәләрне дә үстерәләр. Бу сыйфатлар хәзерге дөньяда күп ишекләрне ача. Ә андый сыйфатлар балаларда күп кенә эчке һәм тышкы проектларда катнашу нәтиҗәсендә формалаша. «Орлята России», «Беренчеләр хәрәкәте», «Профессионаллар» һәм «Абилимпикс», «Зур тәнәфес», «Белемнәр бозваткычы», өч театр коллективы һәм өч музей – болар үсү-камилләшү өчен бик зур мөмкинлекләр мәйданы булып тора. Үзара ярдәм һәм иминлек хөкем сөргән мохиттә үзеңне сәясәтче, инженер, айтишник, туган якны өйрәнүче, актёр, лингвист, урбанист, эшмәкәр рольләрендә һәм башка теләсә нинди яссылыкта сынап карарга мөмкин.

ГАИЛӘ РИТМЫНДА

– Конкурс миңа белем-фәннәрнең төрле өлкәләренә чумып, тирә-ягымдагы дөньяны өйрәнүнең никадәр кызыклы һәм файдалы

ЭМИЛЬ ГОБӘЙДУЛЛИН, һөнәри компетенцияләрне үстерү төбәк үзәге җитәкчесе, «Профессионаллар» чемпионатының төбәк операторы:

– Чемпионатка һәм киләчәктәге һөнәренә әзерләнүдә хезмәттәшлекнең иң нәтиҗәле моделе «мәктәп – предприятие – компетенцияләр үзәге» өчлегенең тыгыз бәйләнешенә корыла. 187 нче лицей инде берничә ел бу модель нигезендә актив эшли: биредә һөнәри сынаулар культурасы формалаша, остазлар һәм эш бирүчеләр белән системалы эш алып барыла, ә иң мөһиме – балалар реаль нәтиҗәләргә ирешә. Лицей укучыларының «Профессионаллар» бәйгесендә финал ярышларында җиңүе һәм призлы урыннар алуы – моңа ачык дәлил.

Лицейның белем бирү тәҗрибәсе илнең башка төбәкләренә дә кызыклы, ә былтыр ноябрьдә РИТМ Цинхуа университеты (Гуанчжоу, КХР) каршындагы мәктәп белән хезмәттәшлек турында меморандум имзалады.

булуын күрергә ярдәм итте. Минем алдагы планнарым – бу искиткеч проектта катнашуны дәвам итү һәм, тормыш китабына якты сәхифәләр өстәр өчен, башка проектларда киң офыклар ачу! – ди унынчы сыйныф укучысы, «Зур тәнәфес» конкурсының 2 нче дәрәҗә лауреаты Диләрә Әсәдуллина.

Мондый проектларда егетләр һәм кызлар елдан-ел күбрәк катнаша. Җиңүчеләр һәм призёрлар саны арта бара. Бер яктан, бу – РИТМ коллективының шәхси һәм һөнәри дәрәҗәсен үстерү, лицейда гамәлгә куелган гомуми тәртип нәтиҗәсе. Икенче яктан, мондый уңыш бирердә гаиләне баланың иң мөһим теләкләренә җәлеп итә алулары белән бәйле.

– «Профессионаллар» бәйгесендә җиңү китергән юлны улым белән бергә узгач, мин бер серне ачтым: әгәр ата-аналарны кызыксындырып, балаларга дөрес ярдәм итәргә өйрәтсәң, нәтиҗәләр күпкә югарырак булачак. Ата-аналар булыша белсә, гаиләдә үзара мөнәсәбәтләр яхшыра, ышанычны тоеп, яшүсмер теге яки бу эшне күбрәк, сыйфатлырак башкара һәм моннан чын ләззәт тоя ала, – ди педагог-психолог, «РИТМ family» ата-аналар клубын оештыручы Лилия Насыйбуллина.

Казанның 187 нче күппрофильле лицее биш ел эчендә республикада иң яхшылар рәтенә керде һәм XXI гасырда белем-тәрбия эшенең партнёрлыкка корылуын исбатлады. РИТМның формуласы гади һәм анык: балалар да, өлкәннәр дә бергә үскән урында теләсә нинди максатка ирешеп була.

ЧЭН ХУЭЙЮНЬ, Цинхуа университеты каршындагы урта мәктәп директоры:

– Безнең мәктәпләр, хезмәттәшлек һәм симбиозның яңа юлына аяк басып, рәсми рәвештә кардәшлек мөнәсәбәтләре урнаштырды, шул рәвешле фән һәм инженерия – уртак ДНК, ә инновацияләр үзара бәйләп торган буынга әверелде. Ике якның да укытучылары һәм студентлары чыннан да халыкара офыкларны киңәйтә, киләчәк бурычларны хәл итү өчен кирәкле мәдәниятара аңлашуны һәм уртак инновацияләрне үстерә.

2020 ачылыш елы

2000 нән артык укучы

150 дән артык педагог

27 өстәмә белем бирү берләшмәсе

йөзләгән җиңү район, муниципаль, төбәк, федераль һәм халыкара дәрәҗәдәге профильле олимпиадаларда, конкурсларда, конференцияләрдә

РИТМ МНОГОПРОФИЛЬНЫЙ ЛИЦЕЙ 187

ГИМНАЗИЯ ГЕНӘ ТҮГЕЛ, Ә ЗУР БЕЛЕМ МӘЙДАНЫ

2025 елда Казанның 179 нчы гимназиясе унъеллыгын билгеләп узды. Шушы вакыт эчендә ул урта гомуми белем бирү мәктәбеннән алып, гади гимназиягә кадәр генә түгел, ә җитди белем бирә торган мәгариф үзәгенә кадәр юл үтте.

ИҢ ЯХШЫ МӘКТӘПЛӘР ИСЕМЛЕГЕНДӘ

Бүген 179 нчы гимназия ике меңнән артыграк укучыны, шулай ук аларның әти-әниләрен һәм укытучыларны берләштерә. Уку йорты шәһәр вузлары һәм предприятиеләре белән тыгыз хезмәттәшлек итә. Бу исә уку-укыту процессында өстәмә белем бирүнең төрле формаларын уңышлы куллану мөмкинлеген бирә.

Биш ел дәвамында гимназия медицина өлкәсендә көндәшлеккә сәләтле укучылар тәрбияләү буенча Россиянең иң яхшы мәктәпләре рейтингында тора. 2024 елда ул шулай ук Россиянең иң яхшы 500 мәктәбе һәм Татарстанның иң яхшы 20 мәктәбе исемлекләренә керә (Raex-Analitika рейтинглар агентлыгы мәгълүматларына караганда).

Соңгы алты елда мәктәпнең 19 укучысы БДИ буенча 100 балл җыя. Укучылар Бөтенроссия олимпиадаларында елдан-ел югары нәтиҗәләргә ирешә: 2024–2025 уку елында биредә муниципаль этапта 82 укучы җиңсә һәм призлы урынга лаек булса, төбәк һәм республика этапларында 47 се призлы урын ала, бишесе җиңү яулый, олимпиадаларның йомгаклау этабында инде ике укучы призлы урынга чыга.

«Россиянең Мәгариф министрлыгы мәктәпләре» проекты кысаларында гимназия «Остазлык лига»сына керә. 2025 елда ул Россиянең «Белем» җәмгыяте белән Россия Мәгариф министрлыгының ата-аналар җәмәгатьчелеге башлангычлары конкурсында җиңеп чыга, шулай ук «Патриотлар шәһәре» конкурсының да җиңүчесе дип таныла. Мәктәпнең «Уңыш координатасы» укучылар үзидарәсе, «Зәңгәр кош» театры һәм гимназиянең структур бүлекчәсе булган «Алсу җилкәннәр» оркестры бөтенроссия һәм төбәкара конкурсларда күп тапкырлар җиңүле урыннар яулый.

ТЕХНОЛОГИК АЛГАРЫШ ЭЗЕННӘН

Ил технологик мөстәкыйльлеккә омтылыш белән яшәгән дәвердә мәктәпне тәмамлаучыларга табигать фәннәре һәм математика буенча төпле белемгә ия булу үтә дә мөһим. Бу белемнәр заманча технологияләрне һәм инновацияләрне аңларга ярдәм итә. Шуңа да мәктәп укучылары физика, химия, биология, математика һәм информатиканы яхшы белергә тиеш. Яшь казанлыларга нәкъ менә шушы юнәлешләрдә үсәргә кирәк, чөнки Татарстан башкаласы – республикада һәм Россиядә иң эре сәнәгать лидерларының берсе. Нәкъ менә профиль сайлау, профильле һәм һөнәри әзерлек буенча ныклы система булу нәтиҗәсендә, гимназиядә инженерлык һәм технологик белемнәр популярлаша. Профиль сайлау һәм профильле уку системасын үстерү концепциясе кысаларында гимназия «Авиатөзелеш профильле инженерлык сыйныфлары», «Пилотсыз авиация системалары өчен кадрлар» һәм «Илдә җитештерелә торган пилотсыз авиация системаларына ихтыяҗны стимуллау» проектларын гамәлгә ашыра.

Фото 179 нчы гимназия администрациясеннән алынды. РЕКЛАМА

Гимназия үз укучыларын инженерлык белгечлекләре, аерым алганда, энергетика, вертолёт төзелеше, авиация, электроника һәм микросистемалы техника буенча уку йортларына керү өчен әзерләү юнәлешендә эшли. Командада эшли белүгә һәм практикада кулланырга яраклы яңа проектлар уйлап табуга юнәлтелгән күнекмәләрне үстерүгә аерым игътибар бирелә. Гимназиянең «Цифрлы сәнәгать өчен кадрлар» бөтенроссия конкурсы финалында җиңүе Казан милли тикшеренү техник университеты – Казан авиация университеты һәм Казан вертолёт заводы белән хезмәттәшлегенең уңай нәтиҗәсе булып тора. Тәмамланган проект-конструкторлык карарлары һәм «Кибердром» ярышлары режимында пилотсыз очу аппаратлары белән идарә итү буенча Казан вертолёт заводының яшь хезмәткәрләре, П.В. Дементьев исемендәге Казан авиация техник көллияте студентлары һәм 179 нчы гимназиянең 10-11 сыйныф укучылары эшли.

МӘКТӘП СЫЙНЫФЛАРЫНДА ПРОФЕССОРЛАР

IT-класслар ачылу гимназиядә укучыларга шактый күп өстенлекләр бирә. Мәктәп укучылары программалау, аналитика, компьютерлар архитектурасы буенча белемнәр ала, стандарт программада болар өзек-өзек кенә бирелә. Алар Python, C++, Java, JavaScript, SQL телләрен өйрәнә, эшләү күнекмәләрен ала. КФУның Мәгълүмат технологияләре һәм интеллектуаль системалар институты мәктәп укучыларына үз лабораторияләренең ишекләрен ача. Укучылар анда IT-юнәлештә укуның структурасы белән таныша ала, әйдәп баручы белгечләр исә гимназиядә лекцияләр укый. ICL компаниясе, Казанның Бәшир Рәмиев исемендәге IT-паркы мәктәп укучылары өчен экускурсияләр, анда эшләүчеләр белән очрашулар оештыра.

Гимназиядә гамәлгә ашырыла торган «Физика-математика буенча алга китеш» проектында төп урынны гамәли дәресләр, остаханәләр һәм күренекле галимнәр укый торган лекцияләр алып тора. Математика класслары өчен мондый чаралар циклын Иннополис Университеты ректоры, физика-математика фәннәре докторы, МФТИ профессоры, Математик модельләштерү һәм мәгълүматларга анализ ясау үзәге җитәкчесе Александр Гасников ачкан. Укучылар белән стандарт булмаган мәсьәләләрне физика-математика фәннәре докторы, МФТИның математика профессоры Андрей Райгородский чишкән. Физика-математика фәннәре кандидаты, Россия ФА Мәгълүмат тапшыру проблемалары институты секторы һәм МФТИ һәм AIRIда кафедра мөдире Егор Ершов шулай ук укучыларга иң заманча тикшеренүләр турында сөйләгән. Бу лекцияләрнең һәркайсы яшь математикларда кызыксыну уяткан.

Профильле сыйныфларны тәмамлаган укучыларның 80 проценттан артыгы БДИны профильле математика, физика, информатика, химия, биология буенча сайлый һәм шәһәрдәге университетларга укырга кирәргә документлар тапшыра.

Сүз дә юк, гимназиянең барлык эшчәнлеге нигезендә тәрбияви максат ята – укучыларда Ватанга мәхәббәт формалаштыру, энергетика, IT-индустрия, нефть химиясе, фармацевтика, төзелеш һәм республика икътисадының башка перспективалы өлкәләре турында киң мәгълүмат бирү. Мондый максат гимназияне белем алу урыны гына итеп калмый, ә булачак инженерлар, технологик белемгә ия белгечләр үстерә һәм тотрыклы киләчәк тудыра торган мәйданчык та ясый.

ҖИР ШАРЫН КОЛАЧЛАП БУЛАМЫ?

Луиза Шарова

Каюм Насыйри исемендәге 80 нче мәктәп турында берничә мәртәбә язганыбыз бар. Чөнки анда вакыйгалар һәрчак кайнап тора: әле мәктәпкә бөек мәгърифәтче исемен бирәләр, әле Каюм Насыйри юбилеена багышлап Россия күләмендә конференция, укулар оештыралар, әле интерактив музейга җан өрәләр...

2025 НЕҢ МАЙ АЕНДА...

Ә быел май аенда, Бөек Җиңүнең 80 еллыгы уңае белән, мәктәпнең 4 нче катында сыннар композициясе әзерләнеп, 80 нче мәктәптән Бөек Ватан сугышында катнашкан егет-кызларның исемнәре, кайсы яуларда нинди батырлык күрсәткәне, язмышлары турында мәгълүмат тупланган мемориал ачылган. Ул еллардагы табиблар белән тыл батырларының каһарманлыгын да онытмыйлар бирәдә. 80 нче мәктәп территориясе ул әле бөек мәгърифәтче, галим, әдип Каюм ага Насыйри эзләрен, аның нигезен саклаган кадерле урын гына түгел, ә Казандагы иң әһәмиятле эвакогоспитальләрнең берсе урнашкан нокта да.

1941 елның 1 сентябрендә ул 0213 нче номер белән формалаша. 1941 елның 4 ноябреннән 3992 нче номер бирелә. Шушы сан белән ул ТАССР һәм Советлар Союзы тарихына кереп урнаша. 1946 елның 3 гыйнварында гына эшчәнлеген туктата. Документларда госпиталь турында рәсми мәгълүмат менә ничек теркәлгән: «Госпиталь начальниклары – II ранглы хәрби табиб А.А. Кокурин, III ранглы хәрби табиб Стребков, III ранглы хәрби табиб А.И. Анахова, медицина хезмәте майоры Деражне, медицина хезмәте майоры Виноградов. Койкалар саны: 475».

– Анда гаҗәеп язмышлар бар, без ул документларны, аларның алган орден-медальләре тарихын, хатларын җентекләп тупладык, хәзер өйрәнәбез. Бу материаллар буенча укучыларыбыз алга таба фәнни конференцияләрдә дә чыгыш ясар, без аларны тарихыбыз-

Фото: Анна Арахамия. РЕКЛАМА

ны, үткән юлыбызны белеп үсәргә өндибез, – ди мәктәпнең директоры.

Роберт Мияссәр улы Мансуров – фидакарьлеге, милләтпәрвәрлеге белән бөтен республикага мәгълүм зат. Патриотик тәрбияне дә актив алга сөрә. Әле ул тагын һәр идеянең пространствода да калкып чынга ашуын, кул белән тотып, күз белән күреп булырдай формага керүен ярата. Шуңа мәктәпнең һәр почмагында бу урын-җирлек белән бәйле шәхесләрнең мирасы сыннар булып та, истәлек такталары булып та, фотоларга һәм стендларга әверелеп тә гәүдәләнә... Белгечлеге буенча географ, Роберт Мияссәр улы, мәктәп капкасыннан керүгә, чәчәккә күмелеп утырган түтәлләр уртасына хәтта планетабыз – җир шарын да бар координаталары белән җентекләп ясатып куйган. Бу гаҗәеп вак детальләр белән җиренә җиткереп эшләнгән җир шары шактый зур һәм саллы. Ул безне, чыннан да, алдыбызга зур максатлар куярга чакырып тора...

– Тәвәккәлләргә генә кирәк, җир шарын да колачлап була, диюегез инде, әйе, Роберт Мияссәрович? – дим.

Ул хәйләкәр елмая:

– Үзе сәнгать объекты гына сыман, әмма мәгънәсе һәм тәэсир итү көче нинди киң, әйеме?!

«БУ – БЕЗНЕҢ НИГЕЗЕБЕЗ»

80 нче мәктәптә эшли торган мөгаллимнәр – чын профессионаллар. Күбесе биредә дистә еллар эшли.

– Бер-беребезгә ияләшеп, инде бер йодрык булып әверелдек хәзер, – дип елмаешалар. Роберт Мансуровның мәктәпне җитәкләвенә дә 5 ел тулып килә. Элеккеге җитәкчеләр белән ветераннарны да онытмыйлар, истәлекләрне кадерләп саклыйлар. Мәктәптә әле тагын тарихи музей-объектлар булачак, дип ышандыра директор. Әмма моңа иганәчеләр, энтузиастлар кирәк, бу идея белән кешеләрне мавыктырырга...

Бөек Җиңүнең 80 еллыгына багышланган сыннар композициясен эшләгәндә, «үз тиене» белән һәр укучы, укытучы, ата-ана да өлеш керткән икән.

– Махсус дәфтәргә фәлән укучы һәм аның этисе белән әнисе, фәлән мөгаллим күпме өлеш керткәне теркәп куелды. Бу киләчәк буыннар өчен – бер истәлек, алар нәрсәнең каян килгәнен белергә тиеш. Шулчакта гына мәктәпкә дә, аның язмышына да ихтирам формалаша. Бу – безнең кадерле нигезебез, дигән ышану барлыкка килә. Бәлки, шуңа да мәктәпне тәмамлап чыккан укучылар, инде ныклы педагогик белем, профиль алып, үзебезгә укытырга әйләнеп кайта... Каюм бабай да дәшеп тора аларны... – ди Роберт Мияссәрович, кабинетына килеп кергән яшь мөгаллим кызларны аталарча кочып алып.

– Роберт Мияссәрович бер чарада күреп алды да, шунда ук эшкә чакырды, аннан соң ычкындырмады инде, – дип елмая кызларның берсе.

– Яшь укытучылар безгә бик кирәк! Мәктәптә, шөкер, кадрлар барлык предметлар буенча да бар, бездә – тулы комплектация, – ди директор, куанычын яшермичә. – Гәрчә бүгенге көндә андый проблема күп урыннарда булса да... Ата-аналар да безгә балаларын китерергә атлыгып тора, хәтта башка районнардан. Төрле милләт вәкиленнән булган 813 бала белем ала. Без бит – гап-гади мәктәп, беркемне дә артык та, ким дә күрмибез, тигез итеп укыта-тәрбиялибез.

ПУШКИН ӘКИЯТЕНДӘГЕ КЫЗЛАРМЫНИ...

Иң беренче эш итеп, мәктәпнең горурлыгы булган Евгения Всеволодовна Матвеева белән таныштык. Ул – рус теле һәм әдәбияты укытучысы, аның әдәбият дәресенә туры килдек. Укучылар белән аралашуы да, дәресне алып баруы да үзенчәлекле – юмор, ирония, шул ук вакытта һәркемгә фикерен әйтергә, үз анализын ясарга өндәү, фәлсәфи сөземтәләр белән.

– Рус теле һәм әдәбияты буенча без – алдынгы позицияләрдә, иң югары күрсәткечләр белән барабыз, – ди мөгаллим. – Укучыларымны Казанның гына түгел, Россиянең иң яхшы вузларын да исәптә тотарга, үз белемнәренә ышанырга өндим. Һәм алар укырга кергәндә бу белемнәрен Россия күләмендә аклый да.

«Три девицы под окном...» – дигән юллар хәтергә килде мәтәпнең иң яшь кадрлары булган мөгаллим кызлар кабинетка кереп тезелешеп утыргач. Икесе – өченче уку елын,

берсе бишенче уку елын эшли икән. Кызлар – педагогик династиядән, шуңа мөгаллимлекне сайлаулары өчен үкенми. Бу өлкәдән перспективалырак башкалары да бар, дигәнгә, тыйнак һәм әдәпле генә итеп елмаялар. Күренеп тора – бу аларның стихиясе.

– Яшь укытучылар өчен өстәмә мөмкинлекләр каралган. Мәсәлән, мин быел Татарстан Республикасы грантын оттым – «Физика-математика профилендәге яшь укытучы» номинациясендә, – ди Гүзәл Илдар кызы Галиева. Ул шулай ук «Ел укытучысы – 2023» бәйгесендә шәһәр дәрәҗәсендә «Педагогикадагы өмет» номинациясендә җиңгән.

– Күпчелек балалар әти-әниләренә охшарга тырыша, минем әнием гомере буе укытучы булып эшләде, шуңа мин дә аның эзләреннән киттем, – ди әңгәмәдәшебез. – Аның ничек эшләгәнен карап торып, бала шәхесен формалаштыруда мөгаллимнең роле ни дәрәҗәдә мөһим булуына төшендем. Һәр дәрес – ул яңа сценарий, уен, ачыш. Мәктәптә эшләү яшь балалар белән бергә яңа дөньялар ачарга мөмкинлек бирә, шуның белән бик ошый. Алар барысы да – кабатланмас үз язмышын язучылар, без балаларга шул ышанычны сеңдерергә тиеш.

Бүген барыбыз да диярлек техник юнәлешләр, ясалма фәһем һәм нейрочелтәрләр белән «чирләгән» бер заманда, барлык буын укытучыларына да бер үк сорауны бирдем: «Киләчәк мәктәбен ничек күрәсез, гомумән, күрәсезме аны?» Җаваплар төрле һәм кызыклы булып чыкты. Әйтик, Гүзәл Галиева болай диде:

– Киләчәк мәктәбе һәр баланың иҗади потенциалын ачу һәм формалаштыру, аңарда тәнкыйди фикер тәрбияләү, стандарт булмаган карарлар кабул итәргә өйрәтү урыны булачак, дип ышанам. Укытучы фигурасы белем бирү процессында, ни генә булмасын, үзәктә калачак.

Математика һәм информатика укыта торган икенче яшь кадр – Рузилә Зөфәр кызы Ханова.

– Педагогик эшчәнлегемдә иң кадерле мизгелләрнең берсе – укуда авырлык кичергән, мотивациясе булмаган бер укучымның чын мәгънәсендә яхшы күрсәткечләргә ирешүе. Без аның белән бик күп көч куйдык, тырыштык, һәм менә ул үз-үзенә ышана башлады, дәресләрдә актив катнашырга кереште, имтиханнарны яхшы итеп тапшырды... Бу очрак һәр балага үз «ачкычларын» табарга кирәклекне раслады, һәр укучының язмышын үзгәртеп булуына инандырды. Мине иң куандырганы – аларның уңышлары, күрсәткечләреннән тыш, үзләренә ышана башлаулары, максатларына ирешергә көч табулары.

Рузилә Зөфәр кызы да киләчәк мәктәбен һичшиксез укытучы белән генә күзаллый:

– Әлбәттә, ул бик заманча, алдынгы технологияләрне исәптә тотып җиһазландырылган булырга тиеш, әмма процессны оештыручы һәм әйдәп баручы – барыбер дә тере укытучы.

– Ә минемчә, укытучы ул – һөнәр генә түгел, ә язмыш та. Мин бу юлны әбием белән әнием мөгаллимнәр булганга сайладым, дөресрәге, ул үзе мине сайлады, – дип, әңгәмәгә кушыла Рәзилә Марат кызы Заһидуллина. Ул – рус теле һәм әдәбияты укытучысы, күпсанлы лингвистик һәм филологик фәнни конференцияләр, бәйгеләр катнашучысы. Шундый мөһим вакыйгаларның берсе, мәсәлән – «Ломоносов – 2025» Халыкара форумы.

Рәзилә Заһидуллина сыйныфы белән шактый кырыс та, ягымлы-мөлаем дә. Әдәбият дәресендәге бер кызык очракны да искә төшерде:

– Бер классик әсәрне тикшерәбез: укучым өзекне шәп иттереп укый башлады, әмма азагында, сөрлегеп, каламбур ясады: «Сквозь леса и пустыни кот неожиданно заблудился...» Үзара көлештек тә, аны уенга борып төзәттек. Балалар әдәби әсәрләрне үзләштергәндә, рәхәтлек һәм җиңеллек хисе кичерергә тиеш.

Ә киләчәк мәктәбендә, тел-әдәбият укытучысы фикеренчә, проектлар якларга һәм аралашуга, үзеңнең фикереңне киң җәмәгатьчелеккә җиткерә белүгә дә өйрәнергә тиешләр.

КИЛӘЧӘК МӘКТӘБЕ: АЧЫК ЭКОСИСТЕМА, РАЙОНДАГЫ МӘДӘНИ-СОЦИАЛЬ ХАБ

Ленара Шәүкәт кызы Хәйруллина – предметы буенча физика укытучысы, уку-укыту эшләре буенча директор урынбасары. 25 еллык педагогик стажы һәм күпсанлы бүләкләре булган, укучылары ел саен олимпиадалар белән профильле бәйгеләрдә җиңеп килгән

бу мөлаем ханым белән мәктәпнең киләчәккә стратегик планнары турында да сөйләштек.

– Кечкенәдән катлаулы нәрсәләрне гади итеп аңлатырга ярата идем. Миңа калса, бу укытучы өчен иң кирәкле күнекмәләрнең берсе. Дөньяны ничек яхшырак якка үзгәртеп була, дип тә гел уйлап йөри идем. Үземнән нинди өлеш кертә алам, дип...

– Мәктәп системасына килеп кергәч, ул идеалистик планнарны, чынлап та, тормышка ашырып буламы соң? – дип кызыксынам.

– Минем эштә, отчётлардан кала, барысы да бик кызыклы. Чөнки мәктәп ул – тере организм, уку-укыту процессы да – җанлы, тынгысыз... Болай сөйләп утыруымны, бәлки, Мәгариф министрлыгы «сатып алган фикер» дип уйларлар, ләкин чын күңелемнән ышанып әйтәм: мәгариф өлкәсе даими рәвештә үсә, үзгәрә, камилләшә. Бер кимчелеге дә булмаган идеаль система – утопия, совет чоры укыту ысулларын кайтарырга кирәк дию дә чынбарлык белән яраша алмый, чөнки заман икенче. Завуч буларак, мин күп нәрсәне тормышка ашырырга көчемне куя алам, идеаль итеп эшләп булмаса да, нәрсәнедер эшләп була бит.

Бүгенге укучыларга куелган бердәй стандартлар турында да сөйләштек. Һәр баланың мөмкинлекләре төрле бит. Ленара Хәйруллина да килешә:

– Кайбер балалар өчен БДИ ны 40–50 баллга тапшыру – зур казаныш, без моны аңлап эш итәргә тиеш. Гомумән, баланың БДИны тапшыра алуы – инде уңыш.

Ә киләчәк мәктәбенә килгәндә, аның карашы мондыйрак:

– Ачык экосистема булырга тиеш. Балаларга мөнәсәбәт тә индивидуаль, чөнки бертөрле балалар табигатьтә була алмый. Алар безгә түгел, без аларның үзенчәлекләренә ярашырга, шул үзенчәлекләрне үстерергә тиеш. Киләчәктә мәктәп ул 8:00 дән 15:00 гә кадәр эшли торган ниндидер ябык мохит түгел, ә тәүлек дәвамында белем алмашуга, мәдәни-социаль аралашуга корылган бер үзәк булыр, дип уйлыйм. Балалар, ата-аналар һәм районда яшәүчеләр өчен үзенә күрә бер хаб, ә анда – секцияләр, коворкинг, лекторийлар, остаханәләр... Укытучы да такта янында сөйләп торучы баш кына булудан туктар, мотиватор, оештыручы, тренер булып әверелер...

БАЛАЧАК ФӘРЕШТӘЛӘРЕ

Гадәттә, башлангыч сыйныф укытучыларына игътибар гел җитеп бетми, шуңа 80 нче мәктәпкә килеп керү белән, алар хакында сораштык. Икесе белән танышып, аралашып та өлгердек.

Әлфия Мәхмүт кызы Сәлимуллина балачакта актриса булырга хыялланган, әмма язмышын мәктәп белән бәйләгән.

– Укытучы ул – белем бирүче дә, җырчы да, биюче дә, сүз остасы да, оештыручы да, ул беркайчан картаймый, – дип елмая Әлфия Сәлимуллина. Сүз уңаеннан, ул әле үзе тагын – шагыйрә дә. Мәктәпнең шигырь түгәрәген актив әйдәп баручыларның берсе. Ике китап авторы. Шигырьләре һәм мәсьәлләре халыкара, республика бәйгеләрендә дәрәҗәле урыннар алган. Педагогик тормышындагы иң зур вакыйга дип татар теле һәм әдәбияты буенча «Ел укытучысы» бәйгесендә Вахитов районында 1 урынга лаек булуын исәпли.

– Балалар иҗатыма да илһам бирә, – ди мөгаллим. – Минекеләр бит – кечкенәләр, бервакыт шулай сөт тешләре төшә башлады. Шул балалар – укучыларым исеменнән шалт итеп шигырь язып куйдым:

Берсе әйтә: «Кичә минем
Бер тешем төшкән иде.
Шул тешне алырга диеп
Теш фәрештәсе килде.

Менә шулай, ә үзләре алар укучылары өчен балачак фәрештәләренә тиң инде. Юлия Анатольевна Хәбибуллина, узган елгы «Ел укытучысы – 2024» бәйгесендә катнашып, район дәрәҗәсендә 2 нче урын алган. Моннан тыш та бик күп бүләкләре бар. Өч ел буена «Юл патруле» түгәрәген җитәкли.

– Миңа элеккеге башлангыч сыйныф укучыларымның, шалтыратып, уңышлары белән бүлешүе кадерле, – ди Юлия Хәбибуллина. – Димәк, хезмәтем бушка китмәгән. Ул балалар сиңа инде соңыннан беркайчан да чит булмый, аларның язмышларын мәктәп дәверендә дә, аннан ары да гел күзәтеп торасың...

Юлия Анатольевна 2012 елда Казанга Башкортстаннан күчеп килгән. Мәхәббәтен – Илсурны очраткан, гаилә корып җибәргәннәр. Ике балалары бар – Артур белән Алисә. Артур – шушы мәктәптә 5 сыйныфта белем ала, Алисәгә – 5 яшь. Ә кадерле кешеләре – махсус хәрби операциядә.

– Ирем һәм балаларымның әтисе белән бик горурланам, тизрәк исәнимин илгә, өебезгә әйләнеп кайтуын көтәм. Балалар да бик көтә... – диде Юлия Анатольевна, күзләрендәге яшьне күрсәтмәскә тырышып.

Саубуллашканда, фронт һәм тыл каһарманнары стенды янында озак басып тордык. Язга таба 80 нче мәктәп ишегалдында әле мемориалның дәвамы да пәйда булачак икән. Димәк, көрәшер өчен дә сәбәп һәм җай табылачак. Т

«КВАНТОРИУМ» – КИЛӘЧӘККӘ СТАРТ

Казанның 174 нче гимназиясендә мәктәп технопаркы һәм югары технологияле лабораторияләр уникаль мәдәни мохит белән баетылган.

«Кванториум» балалар технопаркларын мәктәптә укыган чорда ук яшь буынга заманча компетенцияләрне һәм күнекмәләрне үзләштерергә мөмкинлек тудырган уникаль белем бирү эшчәнлеген оештыру үрнәге дип атыйлар. Алар бөтен ил буенча «Заманча мәктәп» федераль проекты кысаларында оештырыла, ә 174 нче гимназия – Татарстанда перспективалы проектны гамәлгә ашыру пионерларының берсе.

Казан гимназиясенең «Кванториум»ы биш йөз квадрат метрга якын мәйданда урнашкан лабораторияләрдән гыйбарәт. Анда балалар җиде яшьтән йөриләр, алар биредә алган белемнәрен гамәлдә кулланырга өйрәнә. Югары технологияле җайланмалар укучыларга табигать фәннәре һәм техник юнәлешләр буенча дөнья дәрәҗәсендәге компетенцияләрне үзләштерергә мөмкинлек ача. Технопаркта, әлбәттә, бушлай шөгыльләнергә, дәрес кысаларында һәм дәрестән тыш вакытта физика, химия, биология, 3D-модельләштерү, прототиплау, робот техникасы буенча белем алып була. Моннан тыш, профиль алды сыйныфлары оештырылган. Аларда дәрестән тыш өстәмә фәннәр – 5-6 нчы сыйныфларда олимпиада физикасы, программалар төзү укытыла.

Болар барысы да гимназия укучыларына табигать фәннәре, математика, мәгълүмат технологияләре өлкәсендә грамоталылыкны күтәрүгә ярдәм итә, аларда тәнкыйди һәм креатив фикерләү формалаштыра, технологик юнәлештәге күнекмәләрне камилләштерергә мөмкинлек бирә. Алай гына да түгел, 174 нче гимназия инде дүртенче ел рәттән 4.0 мәктәптә уку-укыту концепциясен формалаштыруга юнәлдерелгән «Инженерлык республикасы» инновацион белем бирү проектына кушылган. Проект укучыларны үзгәрүчән, яңаны тиз үзләштерү-өйрәнүне таләп иткән заманча дөнья сынауларына әзерләргә булыша. Димәк, Азинода яшәүче гимназистлар шул рәвешле киләчәкләре өчен бик яхшы старт ала.

Гимназия җитәкчелеге, рухи якны игътибарсыз калдырганда, гармонияле шәхес тәрбияләү мөмкин түгеллеген бик яхшы аңлый. Нәкъ менә шуны күздә тотып, 2014 елда биредә зур иҗади проект тормышка ашырыла – күренекле опера җырчысы, Татарстанның халык артисты Хәйдәр Бигичевка багышланган «Зур җыр театры» мәктәп музее ачыла.

Үзенә күрә тиңсез бу музей Бигичев иҗаты белән таныштыра. Биредә мәшһүр җырчының фото- һәм видеоматериаллары, шәхси киемнәре, театр костюмнары тәкъдим ителгән. Аларны маэстроның хатыны Зөһрә Сәхәбиева биргән. Музей экспозицияләре, Минтимер Шәймиев сүзләре белән әйткәндә, «халкыбызның җанын яктыртучы» булган Бигичев коллегалары, республикада опера сәнгате үсеше тарихы турында да сөйли.

Шунысын да билгеләп үтик: бу – музей гына түгел, ә үзенчәлекле белем бирү киңлеге. Нигез салынган көненнән башлап, ул бөтен мәктәпнең уртак эшенә, укыту-тәрбия бирү юнәлешенең үзәгенә әверелә. Экспонатлар татар әдәбияты дәресләре өчен кыйммәтле күрсәтмә материал буларак актив кулланыла, музейда туган тел дәресләрен үткәрү дә бер традициягә әйләнгән. Т

Фото: национальныепроекты.рф, tatar-inform.ru сайтларыннан. РЕКЛАМА

ТАТАРСТАН

журналын кайдан сатып алырга:

«Мегастрой»
Гаврилов ур., 5
тәүлек буе

Казан-2 тимер юл вокзалы
көтү залы.
Воровский ур., 33
тәүлек буе

«Тукай мәйданы» метро станциясе
6:00 дән 00:00 гә кадәр

Аэропорт терминал 1
тәүлек буе

«Дубравная» метро станциясе
(Зорге урамына чыгу)
6:00 дән 00:00 гә кадәр

РЕКЛАМА. 16+

редакция кухнясы

Фото: Ната Смирнова. РЕКЛАМА

ИМЕЮТСЯ ПРОТИВОПОКАЗАНИЯ. НЕОБХОДИМА КОНСУЛЬТАЦИЯ СПЕЦИАЛИСТА

ИМЕЮТСЯ ПРОТИВОПОКАЗАНИЯ. НЕОБХОДИМА КОНСУЛЬТАЦИЯ СПЕЦИАЛИСТА

СОЦИАЛЬ ӘҺӘМИЯТТӘГЕ БИЗНЕС КОРОЛЕВАСЫННАН – БАЛЫК КҮПТЕРМӘСЕ

Татьяна Вафина

Бүген «Татарстан»ның «Редакция кухнясында» аеруча җылы һәм рәхәт. Чөнки әнисе – «Социаль әһәмияттәге бизнес королевасы» Дарья Логинова балык күптермәсе әзерләгән арада коляскада аның ике айлык улы Всеволод мышнап йоклап ята. Гаилә җылысы һәм бәхете турында сөйләгән бу күренеш шунда ук күңелне нечкәртеп җибәрә…

СЕВА ЙОКЛАГАН АРАДА…

Сева йоклаган арада әнисе – аерым үсеш үзенчәлекләре булган балалар белән эшли торган «Я говорю» нейрологопедия үзәге хуҗабикәсе Дарья – үзенең социаль әһәмияткә ия бизнесының ничек барлыкка килүе турында сөйли.

– Рәсми статистика буенча, безнең көннәрдә ун баланың тугызында үсеш тоткарлана. Бу зур сан, һәм никадәр иртәрәк шөгыльләнә башласак, сөйләм һәм когнитив планда сәламәт балалар шулкадәр күбрәк булачак. Әмма, минем күзәтүләрем буенча, белгеч белән консультациядән соң да әле гаиләдә әти-әниләр нидер эшли башлаганчы, бер айдан да ким вакыт узмый. Вакыт үтә, һәм аннары савыгу процессы катлаулана, озаккарак сузыла.

– Ни өчен бүген үсешләрендә тоткарлык булган балалар шулкадәр күп?

– Иң соңгы һәм популяр фаразларның берсе – генофонд үзгәрү. Мәгълүмат эшкәртү тизлеге үзгәрә. Әгәр безнең балачагыбыз белән балаларыбызның балачагын чагыштырсак, бүген аларның сенсор системасы – бигрәк тә күрү, ишетү системасы – күп мәртәбә артыграк йөкләнеш кичерә... Тавышлар артык күп, күзләргә йөкләнеш тә, чөнки телевизор да режим буенча түгел, телефонны да кулдан төшермибез... Балалар мизгел эчендә ләззәт алуга күнегә, кулларына гаджет килеп эләккәч, аралашу күнекмәләрен һәм мөстәкыйльлекләрен бөтенләй югалта. Барыгызга да киңәш итәбез – мәктәпкәчә яшьтәге бәләкәй балаларга гаджетлар бирмәскә, аларны үзара аралашуга, урамда уйнауга һәм көнкүреш күнекмәләренә өйрәтергә кирәк. Иң мөһим чор – өч яшькә кадәрге

БЕЗГӘ КИРӘК БУЛАЧАК:

Күптермә (запеканка) өчен:

- Балык (бөкрәч яки керкә) – 200 г;
- Дөге – 300 г;
- Брокколи кәбестәсе – 200 г;
- Сөт өсте-150 г;
- Майонез – тәменчә;
- Сыр – 100 г.

Брускета өчен:

- Күмәч телемнәре;
- Авокадо – 1 данә;
- Инҗир – 3 данә;
- Тозлы балык – 6 кисәк;
- Яшел тәмләткеч үләннәр.

– Минем дүрт балам бар. Әйе-әйе. Сева дүртенчесе, – дип елмая Дарья, йоклап яткан сабыена бәхетле караш ташлап.

– Әгәр сез омега препаратларын эчмисез икән, – дидем балаларга, – димәк, сез ул омеганы күптермәдә ашарга тиеш!

чор. Бу баланың чын предметлар, уенчыклар, яшьтәшләре һәм әти-әнисе белән максималь контакт вакыты булсын.

Үсешендә тайпылышлар булган балалар чыннан да арта бара, әмма белгечләр моны вакытлы күренеш дип саный. Кем әйтмешли, бар нәрсә үз җаен алсын өчен, шактый вакыт кирәк булачак әле. Без яңару процессын кичерергә тиеш, тора-бара болар барысы да җайга салыначак, үз урынына урнашачак. Иң мөһиме – баланың үсешен күз уңыннан ычкындырмау һәм, тормышы тулы канлы булсын өчен, аңа яңа шартларга җайлашырга ярдәм итү.

БАРЫСЫ ДА ҮЗЕМНӘН БАШЛАНДЫ

– Дарья, ни өчен сез бу катлаулы эш белән шөгыльләнергә булдыгыз?

– Минем дүрт балам бар. Әйе-әйе. Сева дүртенчесе, – дип елмая Дарья, йоклап яткан сабыена бәхетле караш ташлап. – Олы кызымның үсеше тоткарланды, өч яшендә ул бөтенләй сөйләшми иде диярлек, ә кечесенең бәләкәй чагында яктылыкка һәм тавышларга реакциясе начар иде. Ул вакытта мин мөрәҗәгать иткән табиблар канәгатьләндерерлек җавап бирмәде, мәгълүмат аз иде. Һәм, үз балаларыма ярдәм итү өчен, мин дефектолог булырга укырга кердем, аннары – нейропсихологка, параллель рәвештә клиник психологка укыдым. Соңыннан шуны аңладым: белем һәм күнекмәләрем башка балалар һәм ата-аналарга да файдалы булачак бит. Беренче эш урыным тернәкләндерү үзәге иде. Анда берничә ел хезмәт куйганнан соң, үз эшемне ачарга ниятләдем, чөнки бала белән тернәкләндерү чорында гына түгел, даими шөгыльләнергә кирәк. Күпчелек ата-ана тернәкләндерү сеансларына гына (бу 14–21 көн) өмет баглый. Аннары көнкүреш мәшәкатьләренә бата, бала белән даими шөгыльләнмичә, чираттагы тернәкләнү вакытын көтә. Мондый мөнәсәбәт дөрес түгел, нәтиҗәсе дә аяныч: өч яшьлек бала мөстәкыйль рәвештә ашый, киенә, юына, уенчыкларын җыя белми. Ә бит бу күнекмәләрдән мөстәкыйль шәхес формалаша, һәм, әгәр без үз вакытында өйрәтмәсәк, бала гомере буена ата-анасына бәйле булып калырга мөмкин.

Минем үзәк «Я говорю» дип атала. Һәм бу тернәкләндерү генә түгел, бу – диагностикадан алып баланың тулы канлы үсешенә кадәр нейрологопедик ярдәм күрсәтү дә. Бездә педагоглар, нейропсихологлар, логопед-дефектологлар, клиник медицина психологлары, терапевтлар, сенсор интеграциясе һәм баш мие стимуляциясе инструкторлары, сенсомоторлы коррекция белгечләре эшли. Шулай ук балалар һәм өлкәннәр өчен гаилә психологлары командасы да бар, чөнки гаиләдәге имин вазгыять, үсеш үзенчәлекләре булган баланы гаиләнең ничек кабул итүе һәм аңа ничек булышуы бөтен педагогик маршрутта хәлиткеч роль уйный.

БАРЫСЫ ДА ҮЗ ВАКЫТЫНДА БУЛЫРГА ТИЕШ, ЮГЫЙСӘ КУЫП ТОТАРГА ТУРЫ КИЛӘЧӘК

– Кешеләр сезне ничек эзләп таба?

– Үсешнең дөрес бармаганын сизгәч, консультациягә киләләр. Билгеле бер коррекцияүстерү маршруты төзибез – тикшерү үткәрәбез. Еш кына педагоглар гына түгел, табибларның да катнашуы таләп ителә – аларның маршрутлары һичшиксез нәтиҗәле булачак.

Сроклар һәм нәтиҗәләр турында иң еш сораулар – «Күпме шөгыльләнергә кирәк?», «Ә бала башкалар кебек булырмы?», «Ә кайчан шундый булыр?». Әмма бер генә төрле интервал юк шул. Әгәр дә без балага грамоталы матур сөйләм, әйтелеш кую турында сөйлибез икән – ул дөрес әйтә алмаган авазлар санына карап, моңа ярты елдан ел ярымга кадәр вакыт китәргә мөмкин. Ә инде бөтенләй сөйләшмәүче биш яшьлек бала белән бу берничә елга сузыла ала. Чөнки үсешнең үз сизгер чорлары бар. Барысы да үз вакытында булырга тиеш. Ул чак узып киткән икән, без бу чорны куып тотарга тиеш булабыз. Менә шулай килеп чыга. Һәм без бала белән генә түгел, аның әнисе белән дә эшлибез.

ТЕЛЕФОНДА УТЫРЫРГА ТҮГЕЛ, БАЛА БЕЛӘН АРАЛАШЫРГА КИРӘК

– Әнисе белән?

– Әйе. Үсештә булачак тайпылышлар ана аша, бала туганчы ук тапшырыла. Әниләр еш кына стресс хәлендә була. Игътибар итсәгез, безнең заманда шундый хәлләр күпме! Барлык әниләр дә диярлек эшли, ә махсус хәрби операция белән бәйле рәвештә безнең тормышка стресс

ИМЕЮТСЯ ПРОТИВОПОКАЗАНИЯ. НЕОБХОДИМА КОНСУЛЬТАЦИЯ СПЕЦИАЛИСТА

ИМЕЮТСЯ ПРОТИВОПОКАЗАНИЯ. НЕОБХОДИМА КОНСУЛЬТАЦИЯ СПЕЦИАЛИСТА

тагын да күбрәк өстәлде. Моңа кадәр коронавирус чоры булды. Яңалыклар тасмасын даими актару, статуслар кую да тынычлык өстәми... Бала туа да шунда ук бу ыгы-зыгылы стресс мохитенә кереп чума. Шуңа күрә, әгәр элек баланы дәвалау логопедтан башланган булса, хәзер без бала һәм әни өчен психологтан башлыйбыз. Аннары инде логопедлар кушыла.

– Тәүлек буе телефонда утырырга ярамый, дигән гади хакыйкатьне әни кешегә ничек җиткерергә соң?

– Беренче адым ясалгач, баланың иң кечкенә генә уңышы да әниләрне сөендерә. Психолог белән консультациядән соң ул инде могҗиза көтеп утырмый, ә телефон белән уйнарга аның хәзер вакыты юк. Ул баласы белән даими аралашу өчен һәрвакыт нидер эшләргә тиеш. Сабые кичә генә нәрсәнедер эшли алмаган иде, ә бүген инде булдыра. Үзенә мөрәҗәгать итүне аңламаган бала кинәт аңлый башлый. Беренче тапкыр: «Телим!» яки «Әйдә, киттек!» дип әйтүе, кечкенә генә уңышы әнисен дә, баласын да канатландыра. Бигрәк тә – әнисен, чөнки балалар үзләрендәге бу җитешсезлекләрне сизми дә. Аларга бу табигый тоела.

АНА ТӘҖРИБӘСЕ: БАРЫСЫН ДА ТӨЗӘТЕП БУЛА!

– Ә сез баласының күңелсез диагнозын беренче тапкыр ишеткән әниләрне ничек тынычландырасыз?

– Әниләр нәрсә эшләргә кирәк булуын белгәндә үзләрен тыныч тота. Төгәл план күргәндә тынычлана. Моның катастрофа һәм ахырзаман булмавын аңлаганда. Бу үлемгә китерми һәм авырттырмый. Бу дөрес юл. Беренче нәтиҗәләрне күргәннән соң, аларга инде гомумән берни дә куркыныч булмый башлый. Мондый әниләр өчен төп универсаль киңәш – алар вакытында ярдәм сорап мөрәҗәгать итсен. Белүгә, хәлне аңлауга ук килегез! Никадәр иртәрәк килсәгез, проблемалар шулкадәр тизрәк хәл ителәчәк. Тагын бер нәрсә бар: тумыштан ук бала белән бергә булырга гына түгел, аның белән мөмкин кадәр күбрәк аралашырга да кирәк. Сөйләшергә, елмаерга, җыр җырларга, әкият сөйләргә, кочакларга, үбәргә...

Үземнең ана булу тәҗрибәмне мисал итеп китерәм. Өч бала бер-бер артлы туды. Һәм мин аларның балачак мизгелләре белән чын мәгънәсендә ләззәтләнә алмадым. Бала чүпрәкләре юу-ашату-йоклату... Хәзер белгеч буларак та, әни буларак та мин бала белән теләсә нинди бәйләнешнең никадәр мөһим булуын аңлыйм. Һәм минем бер кагыйдәм бар: бала янында булганда, мин телефонда түгел. Шалтыратуларны кабул итмим, хәбәрләргә җавап бирмим. Статуслар куймыйм һәм аларны карамыйм. Мин бала белән генә. Һава сулап йөрибез, ашыйбыз, уйныйбыз – мин телефонда түгел! Хәзер инде беркем дә телефонсыз өч секунд та тора алмый, дип санала. Мин тора алам. Улым миңа карап елмайганда, ничек мин телефонга карыйм ди инде? Аның елмаюы мине әсир итә.

– Тумыштан ук бала белән бергә булырга гына түгел, ә мөмкин кадәр күбрәк аралашырга да кирәк.

– Сезгә бу бу һөнәрне үзләштерергә этәргеч биргән олы кызыгызның хәле хәзер ничек?

– Хәзер аңа 17 яшь, һәм ул «Тодес»та бии. «Новая волна» фестивалендә аларның коллективы Леонтьев, Буланова, Ревва чыгыш ясаганда биеде. Бар да яхшы, мәктәпне тәмамларга җыена, әмма безнең юлыбыз бик озын булды. Һәм хәзер мин төгәл беләм: әгәр, барысы да үзеннән-үзе җайланыр әле, дип уйлап, өч ел көтмәгән булсам, хәлләр башкачарак булыр, тизрәк савыгыр идек. Уртанчы кызыма тиздән 14 тула. Аның белән мин нәрсә эшләргә кирәклеген инде тизрәк аңладым. Ике-өч ай эчендә үсешендәге тайпылышлардан котылдык.

Әлеге һөнәремдә миңа тагын үземнең әни булу тәҗрибәсен, үз башымнан кичергәннәрне башка әниләргә тапшыру да бик мөһим. Чөнки безгә ярдәм сорап әлегә мондый тәҗрибәсе булмаган хатын-кызлар килә. Алар әле нәрсә белән очрашканнарын, моның белән ничек яшәргә икәнен аңламый. Сөйләшә башлагач, минем тәҗрибәм үземә дә ярдәм итә.

1 Чистартабыз

2 Турыйбыз

3 Пешерәбез

4 Җәябез

5 Салабыз

6 Агызабыз

7 Тезәбез

8 Таратабыз

9 Өстибез

10 Сибәбез

11 Пешерәбез

12 Алабыз

Моны ата-аналар сизә һәм барысы да җайланачагын аңлый. Мин безнең һөнәргә үзләре ата-ана булгач килгән кешеләрне бик күп күрәм, мәсәлән, алар дефектология факультетын тәмамлаганга гына түгел, ә нәкъ менә үзләренә үзенчәлекле бала тәрбияләргә туры килгәнгә күрә бу юлны сайлаган булып чыга.

КҮПТЕРМӘ-КОНСТРУКТОР

Сөйләшкән арада Дарья булачак ризыкның барлык өлешләрен әзерләп тә куйды: балык сөякләреннән чистартылды һәм туралды, дөге һәм брокколи пешерелде, сыр угычтан уылды, – һәм менә инде барлык ингредиентларны табага катламлап саласы гына калды. Һәр катламга сөт өсте агызылды...

– Газ мичендә пешкән бөтен нәрсә конструктор кебек җыела, – дип шәрехли Дарья. – Минем гаиләдә дүрт биюче-спортчы бар, аларга дөрес туклану кирәк. Һәм менә без алар белән шундый килешүгә килдек: «Әгәр сез омега препаратларын эчмисез икән, димәк, сез ул омеганы күптермәдә ашарга тиеш!» – дидем. Ашыйлар!

Дөрес, бу файдалы ризыкта, шеф Ивлев әйтмешли, «мазик» (майонез) бар, шуңа күрә дөрес туклану эффекты кими. Әмма болай тәмлерәк шул.

– Бу сезнең яраткан ризыкмы?

– Безнең гаиләдә иң яраткан ризык – ул традицион итле бәрәңге күптермәсе. Тагын барысына да туралган иттән күркә, тавык кәтлитләре ошый. Бу оттырышсыз вариантлар – тиз әзерләнәләр һәм бар кеше дә тук-канәгать була.

ҺӘР КӨНГӘ КУАНЫП ЯШИМ

– Гаиләдә ашарга сез генә пешерәсезме?

– Хәзер олы кызым ашарга пешерергә булыша. Аңа ошый, тәмле дә килеп чыга. Бигрәк тә ул десертлар пешерергә ярата. Мондый ярдәм миңа да бик кирәк! Хәтерлим, мин үзем бала чакта беренче тапкыр дөгеле аш пешердем. Нәтиҗәдә ит, бәрәңге һәм башка ингредиентлар кушылган ботка килеп чыкты. Ул чагында миңа әтинең сүзләре ошады. Мөгаен, әгәр башка реакция булса, мин бүтән пешермәс тә идем. Мин аңа бу ризыкның бигүк ошамавын күрдем, әмма әтием бик мактады: «Мин арып-талып, ачыгып кайттым, ә өйдә ашарга пешкән!» – дип сөенде.

Әни белән бала арасында да, өлкән һәм кече балалар арасында да иң идеаль яшь аермасы – менә шундый, ярдәм итәр кеше була торган аерма. Бер-бер артлы туган сабыйларым үскәндә, артык уйланып, сокланып торырга вакыт юк иде. Ә хәзер минем уникаль мөмкинлегем бар: баламның ничек үсүен күрәм. Мин аның белән дә шөгыльләнәм, бизнесны да алып барам, гаиләмне дә кайгыртам. Өлгерешмәгән чакларым да була, ләкин бу миңа барыбер рәхәтлек китерә. Мин вакытны ашыктырмыйм. Элек мин кайчан үсәрсез, йөрергә өйрәнерсез, сөйләшә башларсыз, мәктәпкә барырсыз инде, дип уйлый идем. Ә хәзер һәр туган көнгә куанып яшим, тәм табам. Бу - зур бәхет!

ИМЕЮТСЯ ПРОТИВОПОКАЗАНИЯ. НЕОБХОДИМА КОНСУЛЬТАЦИЯ СПЕЦИАЛИСТА

ИМЕЮТСЯ ПРОТИВОПОКАЗАНИЯ. НЕОБХОДИМА КОНСУЛЬТАЦИЯ СПЕЦИАЛИСТА

БЕРГӘЛӘП КЕНӘ ХӘЛ ИТЕП БУЛА ТОРГАН ПРОБЛЕМА

– Шундый зур эш башкарган һәм күп балалы булган килеш сез ничек «Мисс һәм Миссис Бизнес Татарстан» конкурсына килеп эләктегез һәм анда «Социаль әһәмияттәге бизнес королевасы» титулын яуладыгыз?

– Конкурста катнашканда, авырлы идем. Финал йөклелекнең сигезенче аена туры килде. Ләкин барысы да шактый ансат үтте: берәү дә мине биек үкчәле туфли кияргә мәҗбүр итмәде, арыганда ял итәргә мөмкинлек булды. Минем уйлавымча, эшеңне яратып эшлисең икән, ул бер дә ялыктырмый, барысы да үзеннән-үзе килеп чыга.

Конкурска исә тормышымны кызыклы итәргә дип түгел, үз бизнесым идеясе турында сөйләү минем өчен мөһим булганга бардым. Без шундый кызыклы, матур һәм булдыклы ханымнар гына түгел, үсеш үзенчәлекләре булган балалы гаиләләргә ярдәм итәргә сәләтле аз санлы үзәкләрнең берсендә дә эшлибез, диясем килде. Үсешендә тайпылышлар булган балаларны диагностикалау планында Казан һәм Россиянең күп кенә алдынгы лабораторияләре һәм клиникалары белән хезмәттәшлек итәбез, дип җиткерәсем килде. Конкурс минем өчен яңа элемтәләр, мөмкинлекләр барлыкка килсен, безнең хакта мөмкин кадәр күбрәк кеше ишетсен өчен яхшы этәргеч булды. Бу проблема хакында да ишетсеннәр, чөнки андый балалар бар, андый гаиләләр бар, бу бер ике кеше генә түгел, алар күп. Һәм бу хәл ителергә тиешле проблема. Арабызда андый балалар шактый күп. Алар да дуслашырга, сөенеп яшәргә, файдалы булырга тели.

ДӨРЕС МИССИЯ

– Балаларга ярдәм итү - бу сезнең өчен эшме, әллә миссиягме?

– Җирдәге бик кирәкле миссиям, дип саныйм. Чөнки барлык балалар да үзләрен яратуларын, нәрсәгәдер ирешә алуларын тоярга тиеш. Балаларга ярдәм итү – искиткеч! Балачакта мин Гадәттән тыш хәлләр министрлыгында эшләргә – коткаручы булырга хыяллана идем. Балачак хыялымнан ерак китмәвемә сөенәм хәзер.

...ҺӘМ ТАГЫН БРУСКЕТА

Күптермә пешкән арада Дарья тиз генә брускеталар ясый: яртысын тозлы балык һәм авокадо белән, яртысын эремчекле сыр һәм инҗир белән.

– Мондый брускеталарны мин өйдә иртәнге ашка әзерлим. Балалар бутербродларны, кыздырылган күмәчләрне бик ярата. Углеводларны инде. Шуңа күрә бутерброд яраталар икән, файдалысын ашасыннар, дип тырышам.

ВАКЫТ – ИҢ КАДЕРЛЕ РЕСУРС

– Сезнең практикада өметсез очрак булдымы?

– Мин һәрвакытта да әти-әниләрдән белгечләрнең киңәшләрен тыңлауларын, барысы да үзеннән-үзе үтәр, дип көтмәүләрен үтенәм. Булышмыйча гына үтми. Шунда ук нәрсәдер

эшләргә кирәк. Менә шундый бер очрак. Күптән түгел бер кызның әтисе шалтырата, минем телефонда ул: «Вика. 3,5 яшь», – дип язылган. Трубканы алам, исәнләшәбез: «Мин сезне хәтерлим, хәлләрегез ничек?» – дим. Ә ул: «Викага хәзер унынчы яшь», – ди. Мин инде аларның мәктәптә ничек укулары, төрле олимпиадаларда җиңүләре турында ишетергә өметләнәм. Мондый яңалыкларны ишетүемә һәрвакыт бик куанам: балалар өчен дә, безнең команда өчен дә, үзем өчен дә шатланам, вакытында ярдәм итүебезгә сөенәм... Ә Виканың әтисе безгә кабат ярдәм, консультация кирәк, ди... Тагын сорыйм: «Алты ел үтте бит инде, шул вакыт эчендә сез нишләдегез соң? Тәкъдим ителгәнне эшләдегезме?» – дим. «Юк, – ди. – Безгә барысы да яхшы булачак, бала белән өйдә шөгыльләнергә кирәк, диделәр...»

Менә бу очракта нишләргә? Вакытның узуы бик кызганыч, чөнки ул – бәһасез ресурс. Үткән вакытны берничек тә кире кайтарып булмый. Шуңа күрә мондый әйберләр гафу ителмәслек, дип саныйм. Уңай хәбәрләрне мин күбрәк ишетәм, шалтыратып, менә мәктәпкә кердек, яки, әйтик, инвалидлыктан котылдык, бала дуслар тапты, дисәләр... Бәхеткә, мондый хәбәрләр беренчеләренә караганда күбрәк.

– Ә савыккан балалар сезнең янга киләме?

– Гадәттә ата-аналар аларның фотоларын телефонга җибәрә. Менә карагыз, – Дарья безгә сөйкемле балалар галереясын күрсәтә. – Менә бу баланың әзерлек классына керүен күрү миңа бик күңелле булды. Ә менә безнең беренче сыйныфта укучы кызыбыз. Ул әле безгә шөгыльләнергә йөри, әмма нәтиҗәсе инде күз алдында. Ә менә безнең Егорка, ул безгә килгәндә гомумән сөйләшми иде. Хәзер инде ул мәктәпнең нуленче сыйныфында укый. Мондый фотолар минем күңелемә май булып ята. Димәк, без барысын да дөрес эшлибез, димәк, тырышуыбыз юкка түгел.

– Мондый брускеталарны мин өйдә иртәнге ашка әзерлим. Балалар бутербродларны, кыздырылган күмәчләрне бик ярата. Углеводларны инде. Шуңа күрә бутерброд яраталар икән, файдалысын ашасыннар, дип тырышам.

ТАТАРСТАНДА УКЫЙСЫҢ –

«ТАТАРСТАН»НЫ УКЫ

ИЖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ БАСМА

ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАНДА ҖИҢӘСЕҢ –

«ТАТАРСТАН»НЫ УКЫ

ТАТАРСТАНДА ЭШЛИСЕҢ –

«ТАТАРСТАН»НЫ УКЫ

ТАТАРСТАНДА ЯШИСЕҢ –

«ТАТАРСТАН»НЫ УКЫ

Реклама 16+

WWW.PROTATARSTAN.RU

акыллы гамәлләр

игелекле эшләр

мәңгелек кыйммәтләр

Бу санда тәкъдим итәбез:

Бер ел эчендә Лисичанск һәм Рубежноедагы тормыш **ничек** үзгәргән

XIII гасырда **кайсы** шәһәр Париждан зуррак булган

Биләрдәге экофермада **нәрсәләр** яши

БЕР ЕЛГА СУЗЫЛГАН КОМАНДИРОВКА

Максим Переходько, Николай Крушинин

Фронт сызыгына якын регионнан Казанга Фәнил Әһлиуллин* әйләнеп кайтты. Журналыбыз хәбәрчеләренә ул үзе анда командировкада булган вакытта Татарстан шефлык иткән шәһәрләр – Лисичанск белән Рубежноеның ничек үзгәрүе хакында сөйләде. Бу бер ел эчендә тормышка карашның ничек үзгәрүен дә.

ЛИСИЧАНСК СҮЗГӘ САРАНРАК, Ә РУБЕЖНОЕ АЛГА КАРАП КЕБЕК

– Одессада шулай дияләр гадәттә: Лисичанск белән Рубежное – икесе гел ике төрле. Фәнил Әнвәрович, бу шәһәрләргә килгәч тә, беренче тәэсирләрегез нинди булды?

– Әйе, иң беренче шәһәрләр төрле, дип уйладым, әмма аларда уртак сыйфатлар да җитәрлек. Икесе дә фронт сызыгына якын, икесендә дә узган соңгы елларның коточкыч җөйләре ярылып ята. Лисичанск элек-электән шахтёрлар шәһәре булган. Рельефы ягыннан катлаулы, әле биеклек, әле түбәнлек, планировкасы ягыннан да буйга сузылып урнашкан. Тарихи үзәге – 50 нче еллар совет төзелеше үрнәге, сугыштан соң торгызылган йортлар. Алар, әйтерсең, әле дә шул чорның сулышын саклый. Шәһәр шахталар тирәли төзелгән, соңыннан заводлар хисабына үсеп-ирәеп, җәелеп киткән. Нәкъ менә биредә – үзәктә, административ биналар тирәсендә зыян күргән нокталар бик күп. Карап тору да әллә нишләтә: ярасы ачык, кан саркып торган урыннар бу...

Рубежное икенче: җыйнак, яшь шәһәр. Проспектлары да киң, иркен аның. Җимерелүләр нигездә промзона тирәсендә, ә торак өлешләр чагыштырмача яхшы сакланган. Шуңа атмосфера да башкарак. Лисичанск сүзгә саран, эндәшмәүчән булып тоелса, Рубежноеда көч ташып тора, ул алга карап яши.

ТӨП МИССИЯ – ТЫНЫЧ ТОРМЫШТА ЯШӘҮЧЕ КЕШЕЛӘРГӘ ЯРДӘМ КҮРСӘТҮ

– Бу шәһәрләргә татарстанлылар ни дәрәҗәдә еш килә? Нинди миссия белән?

Фото: Максим Переходько

* Фәнил Әһлиуллин, ТР җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министры, ТРның элеккеге вице-премьеры, 2025 елның сентябренә кадәр ЛХРда республика шефлык иткән шәһәрләрне җитәкли.

– Һәр атна. Гуманитар колонналар агылып тора, Татарстан районнарыннан делегацияләр килә. Кемдер продуктлар белән дарулар китерә, икенчеләре – төрле җиһазлар, төзелеш материаллары. Белгечләр дә килеп эшли: инженерлар, төзүчеләр, авария бригадалары. Төп миссия – тыныч тормышта яшәүчеләрне ташламау, аларга ярдәм күрсәтү. Фронт сызыгындагы шәһәрдә калган кеше үзен ташланган итеп хис итмәскә тиеш: аны хәтерлиләр, аның турында кайгырталар, ул берьялгызы түгел.

СУ ҺӘМ ЖЫЛЫЛЫК

– Хәзерге көндә төп бурыч нинди?

– Лисичанскидагы иң төп һәм җитди проблема – су белән тәэмин итү. Су ул – тормыш чыганагы, су булган җирдә яшәү бар. Шәһәр дә яши ала, дигән сүз. Безнең белгечләр шәһәрнең үзәк өлешендәге су системасының авария вакытында сафтан чыккан өлешләрен төзекләндерә. КАМАЗлар, су ташу өчен махсус көйләнеп, шәһәр читендәге бистәләргә су ташый. Бу – көндәлек, җайга салынган хезмәт. Шуның белән беррәттән, йортларны кышка әзерләү бара, җылылык белән тәэмин итү. Әлбәттә, социаль объектлар да күз уңында: хастаханәләр, мәктәпләр, балалар бакчалары, спорт объектлары. Алар тыныч тормыш бара икәнен раслап, күрсәтеп тора.

МӘКТӘПЛӘР, БАЛАЛАР БАКЧАЛАРЫ, ТУКЛАНУ БЛОГЫ

– Кайсы объектларны торгыза алдыгыз?

– Рубежноеда күңелне җылыткан төп вакыйга гомуми белем бирү мәктәбен кулланылышка тапшыру булды. Аны өр-яңадан төзеп чыктылар дисәк тә була: башта түбәсен алыштырып яптылар, аннары пыяла белән тышладылар, җылылык бирү системасын эшләтеп җибәрделәр, җылылык үзәге белән инженерлык челтәрләрен җайга салдылар, шуннан соң инде капиталь ремонт башкарылды, фасадны бизәү эшләре тәгәлләнде. Бүген мәктәп балаларны укырга кабул итте. Ул эчке яктан да заманча итеп җиһазландырылган, спорт инвентарьлары да бар. Мондагы тагын бер мөһим объект – хастаханә урнашкан шәһәрчектәге туклану блогы. Ул кайнар аш белән персоналны да, пациентларны да тәэмин итә. Үз чиратында мондый система дәвалау учреждениесендәге эчке тормышны көйли.

Лисичанскида эш берничә юнәлештә алып барылды. Хәзер менә «Светлячок» балалар бакчасында төзекләндерү эшләре тәгәлләнеп

Лисичанскида Татарстаннан өч авария бригадасы эшли. Алар җирле коммуналь хезмәт вәкилләре ярдәмендә су белән тәэмин итү челтәрләрен торгыза, торак фондны җылылык бирүгә әзерли.

Лисичанск. Техника йорты.



Лисичанск белән Рубежноеда **җимерелгән биналар.**

Яңарыш нәтиҗәләре:

Рубежноедагы мәктәп бинасы;

Лисичанскидагы балалар-яшүсмерләр спорт мәктәбе. Фәнил Әһлиуллин һәм ТР Иҗтимагый палатасы әгъзасы, ТР атказанган тренеры Ольга Павлова укучылар белән ГТО комплексы нормативларын тапшыру вакытында;

Лисичанскидагы төзекләндерелгән мәктәп;

Лисичанскидагы Балалар сәнгать мәктәбе.

ТР Рәисе күрсәтмәсе буенча ТР Премьер-министры Алексей Песошин һәм ТР Рәисе администрациясе башлыгы Әсгать Сәфәров җитәкчелегендәге делегация Луганск Халык Республикасындагы Лисичанск шәһәренә сәфәр кылды.

килә. Узган елда балалар сәнгать мәктәбен тормышка кайтардык, ике урта мәктәпне тулаем комплектлап чыктык – эчке җиһазлардан башлап, медицина кабинетларына кадәр. Балалар һәм яшүсмерләр спорт мәктәбендә төзекләндерү эшен берничә этапка бүлдек: башта объектның үзен сафка бастырдык, соңыннан подвал өлешләрен рәтләп, территориясен тәртипкә китердек. Хәзер менә ЛХР спорт министрлыгы линиясе буенча спорт җиһазлары килергә тиеш – шуларны көтәбез.

ЭЛЕМТӘ ЮКЛЫК ҺӘМ ЗЫЯН КУРКЫНЫЧЫ

– Нинди кыенлыклар белән очрашырга туры килә?

– Күзгә ташланмый торган, ләкин гаять җитди кыенлык – элемтәнең юклыгы. Мобиль интернет булмау, кәрәзле телефон аша хәбәргә чыга алмау. Элемтә өчен башка юллар табарга туры килә. Ә бу бик кирәк: төзүчеләрнең эшләрен оештыру өчен дә, администрация белән авария хезмәтләрен бер йодрыкка җыеп тотар өчен дә. Шулай да җаен табарга тырышабыз. Әлбәттә, дошман яңадан утка тотса, торгызылган объектларның зыян күрүе дә бик мөмкин, андый хәвеф бар, тик әле яңадан җимерелгән урыннар булмады диярлек. Шулай да объектлар шартлау йә дулкыны аркасында, йә ярчыклардан зыян күргәли, әмма аларын гына төзәтергә иялэштек инде.

КОЛАКНЫ ГЕЛ ШОМРАЙТЫП ТОРЫРГА ӨЙРӘНДЕМ

– Дошманның янәшәдә генә икәнлеге сизеләме? Ярымхәрби тормыш шартларына ничек яраклаштыгыз?

– Билгеле, сизелә. Китереп бәрүләр, шартлатулар, нигездә, эзлекле түгел, системага салып булмый аларны. Бу көндәлек имин тормышка охшамаган шартлар, шулай да иялэшенә – мин хәзер колакны гел шомрайтып тотам, ул-бу була калмасын дип, саграк булырга тырышам. Универсаль саклану рецепты юк: тәҗрибә, аек акыл, ныклы ихтыяр көче булыша.

БАШЫҢ – САЛКЫН, ГАМӘЛЛӘРЕҢ ЭЗЛЕКЛЕ БУЛСЫН

– Иң куркыныч көн дип кайсын әйтә аласыз?

– Без мондагы көннәрне курку тойгысы белән исәпләмәскә тырышабыз. Ә кешеләр алдындагы, республика каршындагы җаваплылык белән. Менә шул безгә көч тә, егәр дә бирә. Курку – эмоция, аны без читкә этәреп торабыз. Иң мөһиме: акылың – салкын, гамәлләрең эзлекле булсын, шулай гына эш бара.

Җирле халык өчен Татарстан – плюс билгесе булган бренд ул. Чөнки кешеләр чынлап та ярдәм барлыгын күрә.

ЫШАНЫЧ, ИХТИРАМ ҺӘМ РӘХМӘТ ХИСЛӘРЕ

– Татарстанга җирле халык нинди мөнәсәбәттә?

– Татарстан биредә – плюс билгесе булган бренд. Кешеләр чын ярдәмне күрә, бәяли: кемдер азык-төлек ала, кемдер – китапханә өчен китаплар, кемдер баласын яңартылган балалар бакчасына, мәктәпкә бирү мөмкинлегенә ия була. Бу, үз чиратында, ышаныч һәм ихтирам уята, рәхмәт хисләре тудыра.

– Безнең шефлыкка куелган шәһәрләрдә яшәүчеләрнең Татарстанга килергә мөмкинлеге бармы?

– Әйе, без моңа басым ясыйбыз да. Лисичанскидагы һәм Рубежноедагы 11 сыйныфны тәмамлаучылар, мәсәлән, Алабугага килеп, имтихан тапшыралар, безнең вузларга укырга керәләр. Балалар өчен җәйге лагерьлар оештырыла, әйтик, Кырымдагы «Ак Барс Сәләт» сменасы. Баскетбол, бадминтон буенча да сменалар булды. Балалар ял итеп, канатланып кайттылар.

КОМАНДА БЕЛӘН НӘТИҖӘЛЕ ЭШ ҮРНӘГЕ

– Экспромт хәл итәргә туры килгән бурычлар да булдымы?

– Даими рәвештә диярлек. Иң күзгә ташланып торган мисал – Лисичанскида су системасын эшләтеп, сафка кертеп җибәрү. Суның агып китүе генә булды, туңып каткан челтәрләрдәге дистәләгән авария очраклары ачыклана башлады. Казаннан, Яр Чаллыдан, Яшел Үзәннән тиз арада авария бригадаларын китерттек. Кризисны кичекмәстән туктатырга кирәк иде, хәзергә кадәр безгә коллегалар кул сузып, ярдәм итеп тора. Бу – чын мәгънәсендә команда белән нәтиҗәле эшнең үрнәге.

БУ ШӘҺӘРЛӘР ӘЛЕ КҮТӘРЕЛЕП КИТӘЧӘК

– Сез Лисичанск белән Рубежное шәһәрләрен бер биш елдан соң ничек итеп күрәсез?

– Су, җылылык, юллар, мәктәпләр, балалар бакчалары – боларның барысы да торгызылган һәм сафта итеп күрәм. Яңа гаиләләр төзелә, сабый балалар дөньяга аваз сала... Җитештерү кайта. Ә иң мөһиме – якындагы фронт сызыгы инде юк. Дошманны без тар-мар итәчәкбез. Бу шәһәрләр әле күтәрелеп китәчәк. Мин үзем белән эшләгән командага зур рәхмәт әйтергә телим. Янәшә, иңгә-иң торып хезмәт күрсәткән һәркемгә: төзүчеләрме ул, инженерлармы, педагогларммы, Татарстан районнары вәкилләреме... Бу – тулы бер республиканың тырышлыгы, куәте, без бары тик бергә булып кына мондый җитди бурычларны җиренә җиткереп башкарып чыга алабыз.

Су, җылылык, юллар, мәктәпләр, балалар бакчалары – боларның барысы да торгызылган һәм сафта итеп күрәм. Яңа гаиләләр төзелә, сабый балалар дөньяга аваз сала... Җитештерү кайта. Ә иң мөһиме – якындагы фронт сызыгы инде юк.

ЮЛЛАРНЫҢ БАРЫСЫ

ҺИЧШИКСЕЗ БАРЫРГА

Казан Кремле

Кремльдәге истәлекле урыннар арасында Татарстанның төп җәмигъ мәчете – Кол Шәриф, Благовещение соборы, Сөембикә манарасы, Казан ханнары төрбәсе, «Эрмитаж-Казан» үзәге, «Хәзинә» милли картиналар галереясы бар. «Казан Кремле» музей-тыюлыгы территориясе – моннан 1000 еллар элек шәһәргә нигез салынган урын.

Барлык диннәр гыйбадәтханәсе

Дөньяда гыйбадәтханә рәвешендә төзелгән бердәнбер архитектура ансамбле, ул җир йөзендәге барлык төп конфессияләрне үз эченә ала кебек. «Католиклар чиркәве» янәшәсендә – «мәчет», «синагога» янында – «буддистлар храмы», «япон пагодасы» белән рәттән «православие чиркәве» тора. Шунысына да төгәллек кертик: Барлык диннәр гыйбадәтханәсе дини учреждение түгел, анда беркайчан да гыйбадәт кылулар үткәрелмәгән.

Сәүдәгәрләр Алабугасы

Биредә XIX гасыр ахырындагы бай сәүдәгәр шәһәренең бөтен матурлыгы диярлек сакланып калган. Төп истәлекле урыннар арасында Иван Шишкинның музей-йорты бар. Анда барысы да бөек рәссам исән чактагы кебек сакланган. Алабуга символы – Шайтан шәһәрлегендәге борынгы болгар манарасы, ул XI гасырда төзелгән.

«Татар авылы» этнография авылы

Казаннан 50 чакрым ераклыктагы Исәк авылында урнашкан ачык һава астында музей. Монда борынгы татар авылы көнкүреше торгызылган.

«Долгая Поляна» утар комплексы

Молоствовларның борынгы дворян нәселенә караган утар Тәтештән 13 чакрым ераклыкта урнашкан. Дворян йорты, XIX гасырның зиннәтле карагай аллеясе, биек Идел ярыннан ачыла торган гүзәл манзара – истәлекле урыннарның кайберләре генә бу. Урын паранормаль күренешләрне тикшерүчеләрне дә җәлеп итә. Болгар ханнары да энергия алырга дип бирегә килгән, дип сөйлиләр. Һәм бүген дә кешеләр, монда килгәч, үзләрендә көч-энергия артуын тоялар.

Фото: kazan-kremlin.ru, tatarica.org, elabuga-rt.ru, tatar-inform.ru, tetyushy.ru, Игорь Глушков, monasterium.ru

ДА ТАТАРСТАНГА ИЛТӘ

КИРӘК УРЫННАР

10 ТОП

Иннополис

Россиянең иң яңа шәһәрләренең берсе, аның халкы тулысынча диярлек IT-белгечләрдән тора. Асылда бу – киләчәк шәһәре, анда инде иртәгәге көннең күп кенә технологияләре чынбарлыкка әверелгән. Иннополис – пилотсыз такси йөргән беренче Европа шәһәре, монда тәртипне күзәтергә дроннар ярдәм итә, кафега килгән кунакларга робот-официантлар хезмәт күрсәтә, роботлар курьер булып та эшли.

Зөя утрау-шәһәре

Казанны яулап алыр алдыннан 1551 елда Явыз Иван форпосты буларак нигезләнгән Зөя үзенең храмнары белән таң калдыра. Биредә Россиянең иң борынгы агач чиркәүләренең берсе – XVI гасырда төзелгән Троица чиркәве урнашкан. XVI гасыр Успение соборы һәм Зөя утрау-шәһәре монастыре ЮНЕСКО Бөтендөнья мирасы исемлегенә кергән. Утрауда «Татар бистәсе» археологик агач музее ачылган, ул илдә бердәнбер санала.

Иске Татар бистәсе

Казанның тарихи районы. Бистәгә татарлар шәһәрне Явыз Иван алганнан соң килеп урнашкан. Бу – шәһәрнең җирле халыкның үзенчәлекле татар мәдәнияте, үз традицияләре сакланып калган бер өлеше. Тыкрыкларында агачтан һәм таштан ясалган матур сәнгать әсәрләре байтак, бистәне борынгы мәчет манаралары бизи. Биредә әле дә иске татар шәһәре рухы яши.

Борынгы Болгар шәһәре

Дөньяда урта гасыр мөселман архитектурасының иң төньяк һәйкәле, XIII гасыр – XIV гасыр уртасындагы болгар-татар архитектурасының уникаль үрнәге. Безнең көннәргә кадәр сакланган Җәмигъ мәчете, Көнчыгыш төрбә, Кара пулат, хан мунчалары – юкка чыккан дәүләтләрдән (Идел буе Болгарстаны, Алтын Урда) калган бик аз сандагы җәүһәрләр. Хәзерге татарларның ата-бабалары ислам динен кабул иткән Болгарда дөньядагы иң зур Коръән саклана, ул безнең көннәрдә бастырылган. Болгар тарихи-архитектура комплексы территориясе ЮНЕСКО Бөтендөнья мирасы объекты булып тора.

Казан Богородица ирләр монастыре

Биредә, Кафедраль соборда, Изге Ананың Казан образы саклана. 1579 елда мондагы Мәгарә храмында могҗизалы Казан Изге Ана иконасы табыла.

ЮЛЛАРНЫҢ БАРЫСЫ

АКТИВ ҺӘМ КЫЗЫКСЫНУЧАННАР

«Бакыр тау» бакыр руднигы

Бакыр тавында җир астыннан бакырны XVIII гасырның беренче яртысында чыгара башлыйлар. Монда шахталар XI–XII гасырларда ук булган дигән фараз бар. Әле бүгенгә кадәр ике километрдан артык урында җир асты казылмалары яхшы сакланган. Киләчәктә монда геопарк булдыру планлаштырыла.
Сарман районы

Иске Казан

«Дәүләт тарих-мәдәният һәм табигать музей-саклаулыгы» һәм XIII–XV гасырлар уртасында Идел буе Болгарстанының соңгы башкаласы булган урында урнашкан шәһәрлек.
Биектау районы



Шөгердә нефть музее

Бу музейда үзеңне чын шахтадагы кебек хис итәргә була. Биредә XIX гасырның икенче яртысында эшчеләр битуминозлы комташ чыгарган. Шандор-тау эченә керә торган штольняларга экскурсия онытылмаслык тәэсирләр калдыра. Монда тагын безнең көннәргә кадәр сакланган битум заводы калдыкларын, беренче бораулау вышкаларын һәм башка раритетларны күрергә мөмкин.
Лениногорск районы

Ту-144 самолёты

Дөньяда тавыш тизлегеннән югарырак тизлеккә ия беренче пассажир лайнеры. Илебездә үз заманыннан алдарак пәйда булган өч самолёт сакланып калган, шуларның берсе – Казанда. Авиация вузы бинасы янында урнаштырылган Ту-144 очкычы уникаль интерактив техника музее булачак, дип вәгъдә итәләр. Пилот кабинасында инде симулятор урнаштырылган, аның ярдәмендә тавыш тизлегеннән югарырак тизлектә очарга мөмкин.
Казан, Яңа Савин районы

Фото: Әскәр Сабиров, eco.tatarstan.ru, iskekazan.tatar, vkgz.ru, КМТТУ – КАИ матбугат хезмәте

ДА ТАТАРСТАНГА ИЛТӘ

ӨЧЕН ЮЛ КҮРСӘТКЕЧЕ 7 ТОП

Идел-Кама саклаулыгы дендрарие

Төньяк ярымшарның уртача киңлекләрендә үсә торган агач һәм куакларның уникаль коллекциясендә 580 төр бар, алар белән нибары 1000 адым атлап кына да танышырга була. Төзекләндерелгән экологик сукмак «Америка», «Европа» «Азия» секцияләре аша уза, бу исә төрле континентлардагы үсемлекләрнең күпсанлы төрләре белән танышырга мөмкинлек бирә.
Яшел Үзән районы

Минзәләдә Екатерина күпере

Күпергә йөз яшьтән артык. Бу дөньяда, елга аша салынып, бер генә поезд да узмаган бердәнбер тимер юл күпере. 1914 елда шәһәрне тимер юл белән тоташтырырга җыенганда төзелгән. Әмма Беренче бөтендөнья сугышы башлана, һәм проект тормышка ашырылмый. Тимер күпернең бер заклёпкасы алтыннан диган легенда да бар.
Минзәлә районы

Идел сукмагы

Идел яры буйлап уза торган җәяүлеләр сукмагы. Чувашия чиге янында башлана, Ульяновск өлкәсе янында тәмамлана. Төп юлның озынлыгы 284 километр. Шулай ук берничә түгәрәк һәм радиаль маршрут бар, аларны да кертеп, Татарстанда сукмакның озынлыгы 360 километр тәшкил итә. 20 махсус саклана торган табигать территориясен һәм туристларда кызыксыну уятырлык 100 дән артык объектны берләштерә. Сукмак буйлап сәяхәтне теләсә кайсы ноктадан башларга һәм теләсә кайсы ноктада тәмамларга мөмкин.
Яшел Үзән, Югары Ослан,
Кама Тамагы районнары, Казан

АЛЕКСЕЕВСК РАЙОНЫ.
ГАСЫРЛАР АША СӘЯХӘТ

Фото: Александр Гайнетдинов, Александр Ефремов, Әскәр Сабиров

XI–XIII гасырларда Париж белән Лондоннан да зуррак булган, ә Константинопольдән үзенең масштаблары һәм халык саны ягыннан гына калышкан бөек шәһәр хәрабәләре арасында кайда йөрергә мөмкин? Өч мең ел элек билгесез скульптор ясаган таш сынны кайда күрергә була? Халыкара чаң кагу фестивалендә катнашу, бөтен халык ярдәмендә торгызылган чиркәү бизәкләре белән хозурлану өчен кая барырга? Безнең әбиләребез һәм хәтта аларның әниләре заманындагы кебек тукыма җитештерә торган уникаль туку фабрикасын кайдан табарга? Ниһаять, гүзәл Чулман буенда кайда рәхәтләнеп ял итеп була? Бәлки, гаҗәп тоелыр, әмма моның өчен Татарстанның бер генә төбәгенә бару да җитә – Алексеевск районы бу. Казаннан нибары йөз чакрымлап юл гына үтсә!

ЯҢАРТЫЛГАН ГЫЙБАДӘТХАНӘ

Воскресение чиркәвенең гөмбәзләре ерактан ук күренә. Алар, аяз көнне кояшта ялтырап, болытлы көн булганда яктылык һәм җылылык таратып, зәңгәр күктә йөзә кебек. Чаң какканда исә бөтен тирә-якка куаныч һәм бәрәкәт таралгандай була...

Храм – Алексеевское бистәсенең рухи үзәге һәм үзенә җәлеп итеп тора торган урыны. Ул үзе матур һәм мәһабәт, ә диварлары белән гөмбәзләрен бизәгән өч йөздән артык сурәт – диннән ерак булган кешеләрне дә битараф калдырмаслык чын сәнгать әсәрләре. Билгеле, чиркәүдә матурлык өчен генә ясалган сурәтләр булмый: һәр сызык, бизәк аерым бер мәгънәгә ия, шул рәвешле күз алдыбызда Инҗил җанлана.

Ялтырап торган тугыз гөмбәзе (тугыз фәрештә чины символы), унбер катлы бина кадәрле биеклеге һәм көймәдәй формасы... – традицион өслүбтә салынган гыйбадәтханә чынлыкта архитектура формалары һәм үлчәмнәре белән генә таң калдырмый. Аның диварлары гасырлар зирәклеген һәм күп буыннарның тормыш тәҗрибәсен саклыйдыр төсле. Бу гаҗәп, чөнки ул чагыштырмача яңа әле: Воскресение чиркәвенең югары гыйбадәтханәсе 2008 елда гына төзелгән һәм изгеләндерелгән.

Кемдер бу феноменны гади генә итеп аңлата: Алексеевское бистәсендәге бүгенге чиркәүнең прототибы Подольск губернасындагы кәшәнә булган, ул безнең көннәргә кадәр сакланмаган. Чынлыкта барысы да тирәнрәк, мәгънәлерәк. Халык үзе дә бу матур чиркәүне яңа төзелгән дип түгел, изге урында торгызылган борынгы гыйбадәтханәнең варисы дип саный. Бу - 1712 елда Алексеевское авылында агачтан салынган беренче гыйбадәтханәгә яңадан тормыш биргүгә тиң. Һәм инде икенчесенә – 1754 елда таштан салынганына да. 1836 елда төзелеп, 1938 елда ябылган һәм 1959 елда җимерелгән өченчесенә дә...

Воскресение чиркәвендә аеруча хөрмәт ителгән Ахтыр Мәрьям Ана тәресе, изгеләрнең җәсәде калдыклары саклана. Бирегә бөтен Россиядән гыйбадәт кылучылар агыла. Монда гаҗәеп дин тарихы музее да бар, аны һичшиксез карарга кирәк. Экспозиция атеизм канат җәйгән елларда ничек итеп иманны саклап калу, рухиятне торгызу турында. Биредә 1938 елда атып үтерелгән Алексеевское чиркәве рухание Дмитрий Тростянскийның фаҗигале язмышы хакында да сөйләячәкләр. Совет чорында җимерелгән гыйбадәтханәләр урынында табылган чиркәү кирәк-яракларын һәм репрессияләр куркынычы янаганда да гаиләләрдә сакланып калган бәһасез чиркәү китапларын, тәреләрне күрсәтәчәкләр. Катлаулы 90 нчы елларда гыйбадәтханә төзүне башлаучылар турында да бәян итәчәкләр. Аны төзүгә акчаны бөтен халык белән җыйганнар, иганәчеләр арасында дистәләгән төбәктән төрле конфессия вәкилләре дә байтак булган.

P. S. Гыйбадәтханәгә килгәч, чаң манарасына менәргә тырышыгыз. Иң зурысы – өч тонналы благовестник, аннан кала да дәү генә ундүрт чаң. Болар – чын могҗиза! Аларның сихри яңгырашы таң калдыра, сокландыра. Елга бер тапкыр бөтен илдән иң яхшы чаң кагучылар бирегә «Алексеевские перезвоны» Бөтенроссия фестивалена җыела.

Фото: Александр Ефремов, Айдар Мешәрәпов

Сары комташтан ясалган баш.

Болгар кызы.

Кистән – юлбасарлар коралы.

ДӘВЕРЛӘР. ЯДКӘРЛӘР. ЯЗМЫШЛАР

Сары комташтан әвәләп ясалган баш янына килүчеләрне карасу күз чокырлары белән бораулый һәм серле елмая. Джоконда ук булмаса да, әйләнә-тирәдәгеләргә тәэсире көчле аның. Бу башка инде өч мең (!) елдан артык. Эрмитаждамы әллә без? Юк, Татарстанның Алексеевское бистәсендәге туган якны өйрәнү музеенда.

– Күз алдына гына китерегез: исеме дә билгесез «микеланджело» үзенең әлеге сынын якынча Мисыр пирамидалары төзелгән дәвердә әвәләгән бит. Ул Алексеевское бистәсеннән ерак түгел, Березовая Грива утравында табылган, – дип сөйли музей директоры Ольга Кладова. – Галимнәр, әлеге табылдыкны беренче тапкыр күргәч, үз күзләренә үзләре ышанмаган. Тик тикшеренүләр бу шикләнүләрне юкка чыгарган – аңа өч мең елдан да ким түгел...

Бүген күпләр Алексеевскоега пирамидалар чорыннан калган шул таш сынны күрер өчен килә. Бер уңайдан, археологлар һаман баш ваткан табышмакны да чишәргә тырышалар. Нәрсә соң бу? Борынгы торакны бизәгән скульптурамы? Әллә җирле кабилә табынган потмы?..

Хәер, бирдә, Алексеевскоеда, мәртәбәле зур музейларны кызыктырырлык раритетлар берәү-икәү генә түгел. Борынгы заманда юлчыларны куркытыр өчен юлбасарлар файдаланган кистәнне сез тагын кайда күрә алыр идегез икән? Яки Демидов заводларында коелган туп ядрәсен? Ә бит ул монда бер дә очраклы гына килеп эләкмәгән – Алексеевское кайчандыр танылган рус эшкуарлары Демидовлар биләмәсе булган.

Музейда Идел буе Болгарстаны чоры табылдыклары да бар: биредә, бу якларда, урта гасырларда дәүләт үзәге булган. Витриналардагы күргәзмәгә куелган савыт-саба, бизәнү әйберләре – шул заман шаһитлары. Янәшәдә – XI гасырда яшәгән сөйкемле болгар кызы сурәте. Бервакыт ул яшәгән биләмәләргә илбасарлар ябырылган, халыкны үтереп, җәсәдләрен чокырга ташлаганнар... Мең елга якын чокырда яткан калдыкларны археологлар тапкан, шуларга таянып, белгечләр Болгар кызының кыяфәтен бик төгәл сурәтли алган...

Кызылармияче будёновкасы, «Смит-Вессон» револьверлары, «Наган»... Болары инде бөтенләй башка тарих: Алексеевское Гражданнар сугышында Колчак армиясе барып җиткән иң көнбатыш нокта булып исәпләнә.

Тагын бер сугыш – Бөек Ватан сугышы. Экспозициядә – якташларының фотосурәтләре, аларның шәхси әйберләре, бүләкләре. Илне фашизмнан саклаучылар, кайнар нокталарда сугышучылар, Россиянең киләчәге өчен бүген көрәшүче һәм һәлак булучылар турында хатирәләр мәңге яшәргә тиеш. Туган якны өйрәнү музее янында күптән түгел ачылган Сугышчан дан музее экспозициясе шушы игелекле миссияне үти. Монда барысы да хәрбиләрчә кырыс һәм күңелгә тиярлек моңсу. Бөек Ватан сугышы коралы янәшәсендә – махсус хәрби операция дроны, трофей кораллар янында – геройларның һәм инде мәңгелеккә китүчеләрнең фамилияләре... Беркем дә онытылмый.

Музейга махсус хәрби операция зонасыннан тапшырылган трофей.

Фото: Александр Ефремов, Айдар Мөшәрәпов, Анастасия Хатыйпова

ТАТАРСТАНДА ТИҢЕ ЮК КӘСЕП

Сәнгати тукучылык юнәлеше гомер-гомергә Россиядә халык иҗатының традицион төре булып саналган, һәм бу хәзер дә шулай. Әлеге һөнәрчелектә рус һәм татар халыкларының күп гасырлык тарихы, буыннан буынга күчеп килгән иҗат алымнары һәм бай тәҗрибәсе чагылыш тапкан. Алексеевское нәфис әйберләр туку фабрикасы Татарстанда рус бизәкле туку традицияләрен саклап калган һәм үстергән бердәнбер предприятие булып тора.

Фабрика тарихы элекке чорларга – узган гасыр башына ук барып тоташа. Революциягә кадәрге чорда ук биредә сәүдәгәр хатын Макариха предприятиесе эшли. Аннары, 1927 елдан, ул «Ударница» артеленә әйләнә. 2027 елда фабрика 100 еллык юбилеен билгеләп үтәчәк. Предприятие бу тиңсез сәнгатьнең бар гүзәллеген халыкка күрсәтеп кенә калмый, ассортиментын даими яңартып та тора. Осталар, тукымаларга күз явын алырдай ямь биргән челтәрле туку, бизәкләп һәм чүпләмләп туку техникаларын кулланып, югары сәнгать дәрәҗәсендәге эшләнмәләр җитештерә.

Кулдан тукып ясалган әйберләр матур да, нык та, чыдам да. Алар табигый мамык җепселләр, ярымйон һәм җитен җепләрдән эшләнә. Тукымаларның барысы да оригиналь, ә бизәкләр байлыгы ягыннан да, күңелне җәлеп итү җәһәтеннән дә соклангыч.

...Тарих төпкелләрендә калган тормыштан безнең көннәргә килеп җиткән рәсемле ак тукыманы кулың белән сыйпасаң яки битеңә тидерсәң, әйтерсең лә аның тын гына сулыш алуын тоясың, тукымадан искиткеч тынычлык һәм рәхәтлек бөркелә. Тукучының кул җылысы һәм күңелендәге гаҗәеп моңы сеңеп калган кебек аңа.

Алексеевское тукучыларының эшләнмәләре – челтәр бизәкле ашъяулыклар, сувенир сөлгеләр, төрледән-төрле тастымаллар, табигый тукымадан тегелгән киемнәр... Алар эш өчен дә, бәйрәм иткәндә дә кирәк, шулай ук республикабыздан бик яхшы бүләк һәм сувенир да булып тора.

Фабрика сезнең белән хезмәттәшлек итәргә әзер! Агач кул станокларында алтын куллы осталарыбыз ясаган сувенир җыелмаларына заказларны бик теләп кабул итәчәкбез.

Заман белән бергә атлап, предприятие туристлык өлкәсендә дә актив үсә. Биредә экскурсия программасы гамәлгә куелган. Фабрикага барып, профессиональ тукучыларның бик борынгыдан килгән туку эшчәнлеге процессын күзәтергә була. Аларның гаҗәеп осталыгын һәм туку станында эшләүнең катлаулы булуын күреп шаккатасың. Монда сезгә борынгы стан турында да, тукучылык эшенең нечкәлекләре, җитештерү серләре хакында да сөйләрләр. Шулай ук фабрикага нигез салучы ханым язмышын нечкәрәк белерсез, бизәкләрнең дә мәгънәләрен аңлатып бирерләр.

Фабрика истәлеге итеп, һәркем махсус фотозонадагы борынгы станок янында фотога төшә һәм, әлбәттә, үзен һәм якыннарын фирма кибетеннән алып кайткан сувенирлар белән сөендерә ала.

Предприятие җитештерү белән бәйле барлык нечкәлекләрне һәм үз тормышындагы мөһим вакыйгаларны Aleksfht телеграм-каналында актив яктыртып бара.

Алексеевское нәфис әйберләр туку фабрикасы
Татарстан, Алексеевское ш.т.б., Павелкин ур., 22

Тел.: +7 (84341) 25253
E-mail: afxt@alextkach.ru

Фото: Александр Ефремов. РЕКЛАМА

Аяк очында дулкыннар шавы, су кебек йотлыгып эчеп җибәрерлек саф һава һәм сихри тынлык... Әллә җәннәткә эләктекме соң? Шулай дияргә дә була. «Белка» ял базасы – Чулман буендагы җәннәт почмагы ул. Бер килсәгез, монда тагын-тагын киләчәксез әле.

ЧУЛМАН БУЕНДАГЫ ОҖМАХ

Мегаполислар ыгы-зыгысыннан һәм көндәлек мәшәкатьләрдән ялыкканнар өчен бу урынның аурасы теләсә нинди дарудан да шифалырак. Наратлар арасыннан сузылган аллея буйлап йөреп алгач, елга манзарасына хозурланып, беседкада утырып торасың, аннары баскычтан Чулман буена төшәсең... һәм бер атналык көч-куәт туплыйсың. Ә Чулманда көймәдә йөрү, учак янында кич утыру, мангал янында һуштан яздырырлык шашлык исен иснәп, авызыңа сулар килү – боларына ни диярсез? Мондый ләззәтне берниндә Анталияләрдә таба алмассың!

«Белка»да бик сирәк урыннарга гына хас аерым бер өстенлек бар: табигатьтә ял монда дүрт-биш йолдызлы кунакханә уңайлыклары белән берләштерелгән. Бассейн кирәкме? Алар монда икәү. Саунамы? Берсеннән-берсе иркен һәм берсеннән-берсе эссерәк. Зур бильярд уйнарга телисезме? Рәхим итегез! Су температурасы тән рәхәтләнеп ял итәрлек идеаль югарылыкта булган, ә үзе ачык һавада торган мунча мичкәсен дә сез монда гына табарсыз.

«Белка»да гаиләләр һәм зур компанияләр өчен коттеджлар иң талымлы зәвык ияләрен дә канәгатьләндерерлек. Аларның бизәлеше сыйфатлы; кухнялары, уңайлы йокы бүлмәләре һәм иркен кунак бүлмәләре бар. Нәкъ кунакханәдәге кебек ял итәргә теләүчеләр өчен – бар уңайлыклар да каралган һәм зиннәтле террасасы булган ике урынлы номерлар. Алардан Чулманның сихри манзарасы ачыла.

«Белка»ның даими кунаклары арасында гаиләләр дә (нәни туристларны балалар мәйданчыгы җәлеп итә), елгада кармак салырга яраткан балыкчылар да эреле-ваклы компанияләр дә булуга гаҗәпләнәсе юк. «Белка» – корпоративлар һәм гаилә бәйрәмнәре өчен дә идеаль урын. Банкет залы (монда андый зал да бар!) иркен һәм уңайлы. Анда күңелләрдә озак сакланырлык матур тантаналар оештыру өчен кирәкле бөтен нәрсә каралган.

«Белка»да узган ялның күңелле һәм онытылмаслык булачагы шик уятмый. Табигать, уңайлылык, менә дигән шартлар, тагын әле хезмәткәрләрнең профессиональлеге һәм кунакчыллыгы моңа гарантия булып тора. Бу урынга сорау зур булу да шуның белән бәйле. Яңа ел каникулларына, киләсе җәйге сезонга коттеджлар һәм номерларны инде бүген үк броньлап куялар. Отпусклар сезоны бетеп барган бу көннәрдә дә ял базасы буш тормый. Кармак тотып яр буенда утыру яки җирле аучы белән сыла балыгы тотарга төшү, ә аннары бассейнлы саунада ял итү – моннан да шәбрәк тагын ни була ала?

«Белка» ял базасы. Татарстан, Алексеевск районы, Речное авылы, Зур урам, 14А

Тел. 8 (927) 420-02-46 vk.com/bazaotdyxabelka

Фото: Александр Ефремов, Әскәр Сабиров. РЕКЛАМА

БИЛӘР – БӨЕК ХАННАР КАЛАСЫ

– Биләр шәһәренең XI–XIII гасырларда дөньяның иң зур шәһәрләре унлыгына керүен һәм, Париж, Лондон, Киев, Новгородларны артта калдырып, мәйданы буенча Константинопольдән соң Европада икенче урында торуын беләсезме? – дип сорады Биләр дәүләт тарих-археология һәм табигать музей-саклаулыгы директоры Зөфәр Шакиров. – Бу урта гасырлар мегаполисы монголларга кадәрге чорда Болгар шәһәреннән 60 тапкыр зуррак булган!

Бүген Биләр авылы янында урта гасырларда Көнчыгыш Европаның иң бөек шәһәрләреннән берсе саналган Биләрнең шанлы хәрабәләрен күреп була. Борынгы рус елъязмаларында ул «Болгарның бөек шәһәре» дип атала. Һәм, күп гасырлар үтсә дә, аның Кече Чирмешән елгасы үзәнендәге урыны космостан төшерелгән сурәтләрдә шактый ачык таныла. Европа елъязмаларында Биләр 970 елдан бирле телгә алына.

КӨЧ ТУПЛАУ УРЫНЫ ҺӘМ ВАКЫТ КИҢЛЕГЕ

– Без тарихтан ике елга арасында формалашкан күп цивилизацияләрне беләбез: Тигр һәм Евфрат елгалары арасында – Месопотамия, Хуанхэ һәм Янцзы арасында – Кытай, Һинд белән Ганг арасында – Һиндстан, – дип санап китә Зөфәр Шакиров. – Соңрак, урта гасырларда, Идел һәм Чулман елгалары арасында шундый ук үзенчәлекле һәм бай цивилизация формалашкан, татар халкы аның варисы булып тора.

Бер фараз буенча, Биләр борынгы болгар телендә «Бөек» дигәнне аңлата. Икенчесе буенча, «Ханнар каласы» дип тәрҗемә ителә: «билек» – ханлык, «бәклек» патшалыкны аңлата. Шулай ук болгарларда «биләр» сүзенең мәгънәсе «галим кеше» дигән фикер дә бар.

ИҢ БОРЫНГЫСЫ ҺӘМ ИҢ ЗУРЫСЫ

Зөфәр безне нindидер бик затлы таш бина хәрабәләре янына алып килә. Янәшәдә генә тагын берсе, кечерәге бар...

– Монда ислам дөньясы ойкуменасының* төньяк үзәге урнашкан булган, – ди ул. – Бу – Көнчыгыш Европаның иң борынгы һәм иң зур мәчете урыны. Ә бусы – мунчаныкы, – дип хәрабәләрнең кечерәгенә күрсәтә ул. Хыялны эшкә җиккәч, без тегесен дә, монысын да аермачык күрәбез сыман.

Борынгы Биләр Җәмигъ мәчете комплексы хәрабәләре – үз тирәсендә традицион ислам концепциясе торгызыла һәм үстерелә торган төп объект. Зурлыгыннан тыш, төп мәчетнең әһәмиятен төзелештә кулланылган материаллар да дәлилли. Шәһәр үзе агач һәм кирпечтән төзелгән, әмма төп мәчетне салу өчен, зур чыгымнарга карамастан, таш кайтартылган.

Мәчеттән бераз арырак – хәрби саклану үрләренең калдыклары, ерактарак – тагын берсе, алар бөтен шәһәрне уратып алган... Нинди зур булган бу мегаполис!

ШӘҺӘР ҺӘМ ШӘҺӘР ЧИТЕ

– Шәһәрлекнең мәйданы 620 гектар чамасы, – дип, төгәл саннар китерә Зөфәр. – Шәһәр чите белән бергә аның гомуми мәйданы 800 гектарга якынлаша.

Шәһәр территориясе үрләр һәм канаулар белән уратып алынган, алар аны эчке һәм тышкы өлешләргә бүлә. Эчке шәһәр – ике кат үр һәм канаулар белән, ә тышкысы өч кат ныгытма белән әйләндереп алынган. Әгәр барлык ныгытмаларны бергә сузсаң, аларның озынлыгы 40 чакрым булыр иде. Һәм бу ныгытмаларның барысы да кулдан төзелгән!

ШӘҺӘР ЦИВИЛИЗАЦИЯСЕ

Биләр мисалында төрки телле күчмәннәр традицияләренең ни рәвешле югары үсештәге утрак төрки-мөселман шәһәр цивилизациясенә әйләнүен күзәтеп була. Биләрдәге фәнни казынышлар үсешенең югары дәрәҗәдә булуын биредәге югары технологияле җитештерүләр дә дәлилләп тора.

БОРЫНГЫЛЫКНЫҢ ЮГАРЫ ТЕХНОЛОГИЯЛӘРЕ

Борынгылыкның югары технологияләренә дәлилләр эзләп, музейга керәбез. Ул зур түгел, ләкин бик... чын. Бу территориядә 60 елдан артык алып барылган казу эшләре үз җимешләрен китергән, һәм бу табылдыклар музейда кадерләп саклана.

– Биләр Бөек Ефәк юлының төньяк тармагындагы һәм Идел сәүдә юлындагы төп нокта була. Тораклыкларның урнашу тыгызлыгына карап бәя бирсәк, монголларга кадәрге чорда Идел буе Болгарстанының йөрәге Биләрдә булган! – ди Зөфәр зур горурлык белән. – Әгәр Болгар, мәсәлән, сәяси башкала, әмирләрнең бер резиденциясе булып исәпләнсә, Биләр, һичшиксез, металлургия, химия, зәркәнчелек, пыяла җитештерү тармакларында ул заманның иң алга киткән технологияләренә ия икътисадый үзәк булып тора.

Зөфәр безгә археологларның табылдыкларын күрсәтә: пломбалар һәм бизәнү әйберләре кою формалары, балчык савытлар, пыяла эшләнмәләр, яктырткычлар, барс сыны рәвешендә эшләнгән йозаклар, төрле йозаклардан бик кечкенә ачкычлар, бронза, бакыр, кургаш эшләнмәләр... Казу эшләре биредә 1967 елдан бирле бара, һәм шушы еллар эчендә шәһәр территориясенең нибары 0,04 проценты гына өйрәнелгән әле.

Әмма хәтта бу да Идел буе Болгарстанындагы шәһәр цивилизациясенең иң югары дәрәҗәсе турында сөйләргә мөмкинлек бирә.

АЛХИМИКЛАР ҺӘМ ХИМИКЛАР

Биләрдә химия савытлары табылу, аннары Биләр үзәгендә алхимия остаханәсе ачылу Идел буе Болгарстанында XII гасыр – XIII гасыр башында алхимия булганлыгы турында нәтиҗә ясау өчен этәргеч булып тора. Шул рәвешле, алхимия фәне үсешенең башлангыч этабын археология материалларына нигезләнеп өйрәнү өчен сирәк мөмкинлек туа!

Ә алхимиядән химиягә кадәр булган дәвамчанлыкка музей-саклаулыкның бөек химиклар тормышы һәм эшчәнлегенә бәйле объектлары дәлил: болар – Александр Бутлеров җирләнгән кәшәнә һәм Александр Арбузовның музей-йорты.

Фото: Александр Гайнетдинов. РЕКЛАМА

* Ойкумена – дөньяның кешелек тарафыннан үзләштерелгән һәм халык яшәгән өлеше.

– Бу – Көнчыгыш Европадагы иң борынгы һәм иң зур мәчет хәрабәләре, – ди Зөфәр Шакиров.



Күп гасырлар үтсә дә, Биләрнең урыны космостан төшерелгән сурәтләрдә шактый ачык таныла.

Алхимиядән – химиягә. Александр Арбузовның музей-йортында.

«БИЛӘР ТӘВӘ КОШЫ» ЭКОФЕРМАСЫ. ТӘВӘЛӘР КЕМ БЕЛӘН ДУС?

Биләргә килеп чыккансыз икән инде, биредәге тәвә кошлары белән танышмый китмәгез. «Ә анда тәвәләр бармыни?» – дип сорап та тормагыз. Грециядәге кебек, Биләрдә барысы да бар!

Страусларны Татарстан якларына Наталья Зиннәтуллина алып кайткан. Белеме буенча китапханәче булган бу ханымда көннәрдән бер көнне фермерлык белән шөгыльләнү теләге туа. Ул үз крестьян-фермер хуҗалыгын ачып җибәрә, бодай, арпа, көнбагыш үстерергә керешә... «Агростартап» грантын ота, бу исә хуҗалыкны үстерүгә бик ярдәм итә. Ә аннары тәвә кошлары белән мавыгып китә. Башта бер пар – Австралия, аннары алты Африка тәвә кошы сатып ала. Һәм халык, экзотик кошларны карарга дип, Биләргә тартыла башлый.

ГАИЛӘ СОВЕТЫ

2021 елда Зиннәтуллиннарның гаилә советында карар кабул ителә: КФХ базасында «Биләр тәвәсе» экофермасын ачыйк, дип килешәләр. Сигез миллион сумлык «Агротуризм» гранты бик ярап куя. Һәм менә Биләр экофермасында коңгырт, яшел һәм сары төстәге йомырка сала торган тәвә кошлары гына түгел, берсеннән-берсе кызыклы башка хайваннар да пәйда була. Шулай ук территориядә кар чанасы һәм квадроциклы булган туристларны ел әйләнәсе кабул итәрлек өйләргә ия ял базасы барлыкка килә.

АФРИКА ПЕРИСКОПЛАРЫ

– Африка страуслары иң зурлары һәм иң өлгерләре, – ди Наталья, озын муенлы җитез кошларны матур итеп түгәрәкләп туралган кишер белән сыйлаган арада. – Фотоаппаратыгызны да эләктерергә, томшыгы белән телефоныгызны да тартып алырга мөмкиннәр, димәк, уяу булыгыз!

Койма артыннан, су асты көймәсе перископлары кебек, чиратлашып тәвә башлары калкып чыга. Беләсездер, перископның төп максаты – берәр нәрсәне яшеренгән җирдән чыкмыйча гына күзәтү. Менә тәвәләр дә күзәтә. Бу шөгыльне ачыгавыз кунаклар кулыннан берәр нәрсәне эләктереп алган вакытка гына туктатып торалар.

ЧҮЛ СОЛТАННАРЫ ҺӘМ ҖӘМИЛӘ

Дөяләр вольерына: «Сак булыгыз! Дөяләр төкеренә!» – дип язылган такта беркетеп куелган. Чүл кораблары, һични белән кабартылмаган, табигый күпереп торган иреннәрен мыскыллы бер төстә очлайтып, кунакларга тәкәббер генә караш ташлый.

– Чынлыкта алар төкеренми, – дип, Наталья дөянең бу әдәпсез гадәте турындагы уйдырманы юкка чыгарырга тырыша. – Ләкин көтелмәгән хәлләр булмасын дип, кисәтеп куябыз. Аларны үртәргә ярамый. Үртәгәнне яратмыйлар. Менә бу ханымның, – Наталья Җәмиләгә ишарәли, – үпкәләп, төкерүгә охшаш бер гамәл кылганы бар.

ЯНУТ ФОКСИК

Экофермага килгән балалар Фоксикны ашатырга ярата икән. Әлеге җәнлекне кунакларның барысы да шундук үз итә. Фоксик: «Миңа бүген нинди тәмле әйбер алып килделәр икән?» – дип, сәйләндәй күзләре белән тутырып карый. Юмарт куллардан тәпиләре белән тәм-томны матур гына эләктереп ала да тешләре тезелеп киткән авызына тутыра да башлый. Һай тәмле! Ләззәтләнеп күзләрен кыса.

– Виноградны бигрәк ярата инде, – дип сөйли Наталья Фоксикның аппетиты турында. – Ләкин кабыгын ашамый, төкерә. Менә шундый талымлы ул безнең...

Фоксик виноградны кабыгыннан яшен тизлеге белән чистарта – һәм менә инде яңа җимеш сорый.

САЗ КОНДЫЗЫ ВАННАДА ЮЫНА

– Чөнки алар чисталык ярата, – ди Наталья, ваннада бер кондызның рәхәтләнеп коенып ятуын күзәтеп. – Гел юыналар, йоннарын чистарталар, җыеп әйткәндә, гигиена саклыйлар.

Әгәр бу пакьлек-сафлык картинасы белән бик ярашып бетмәгән ике сары теш булмаса, моңа ышанырга да мөмкин булыр иде. Мондый тешләре белән алар заманында Чехов үзенең бер әсәрендә сурәтләгән кечкенә шайтаннарга охшаган: «Кинәт лампа артыннан аңа шайтан үрелеп карады... Ләкин курыкмагыз, укучыларым. Шайтанның кем икәнен беләсезме?

Ул итек кебек кара йөзле, кып-кызыл күзле матур кыяфәтле егет.

Башында, өйләнмәгән булса да, мөгезләре бар. Прическасы à la Капуль. Тәне яшел йон белән капланган, үзеннән эт исе аңкып тора. Арка төбендә очы уклы койрык селкенә... Бармаклар урынына – тырнаклар, аяк урынына – ат тояклары. Тешләре сары...»

– Тешләре дә чиста, аларның төсе шундый, – дип тынычландыра Наталья. – Бернинди дә җен-пәриләр түгел, бик сөйкемле кондызлар.

ДИКОБРАЗЛАР ГАИЛӘСЕ ЗУРАЯ

Экофермада атлар да, кәҗәләр дә, сарыклар да, боланнар да, балаларны рәхәтләнеп атландырып йөртә торган Гоша кушаматлы ишәк тә бар.

Ә күптән түгел биредә чын могҗиза булган: дикобразлар гаиләсе ишәйгән. Нәни дикобразларның энәләре йомшак, нәфис. Һич тә эти дикобразныкы кебек каты түгел. Ул яңа туган балалары янына беркемне дә кертми. Якын килдеңме – энәләрен кабарта!

ПРОГРАММАНЫҢ КАДАГЫ

Экоферманың төп бизәге – Нюша кушаматлы дуңгыз. Минипиг токымыннан. Бу «кызый»га монда күп нәрсә рөхсәт ителә: ул вольердан чыгып, экоферма территориясендә үз иркендә йөри, башка хайваннарга кунакка керә ала. Һәм ул ашарга ярата. Ә кунаклар, бигрәк тә нәниләр, аны ашатырга атлыгып тора. Кишер кимергәндә, ул шундый кызык итеп мыркылдый. Тәмлетамак дуңгызкай шактый түгәрәкләнгән инде, үзе бик йомшак. Һәм бу барысына да ошый, шуңа күрә Нюша якын арада ябыгырга җыенмый. Т

Фото: Александр Гайнетдинов. РЕКЛАМА

Страусларны Татарстан якларына Наталья Зиннәтуллина алып кайткан.

Мондый тешләре белән алар кечкенә шайтаннарга охшаган...

Бар кунакларның күңелен яулап алган янут Фоксик виноград ярата.

Перископның төп максаты – берәр нәрсәне яшеренгән җирдән чыкмыйча гына күзәтү. Менә тәвәләр дә күзәтә.

– Чынлыкта алар төкеренми, – дип, Наталья дөянең әдәпсез гадәте турындагы уйдырманы юкка чыгарырга тырыша. – Ләкин көтелмәгән хәлләр булмасын дип, кисәтеп куябыз.

Нюша якын арада ябыгырга җыенмый.

ЭКОФЕРМАДА КЕМНӘР ЯШИ:

Бүген экофермада 27 төрдәге хайван бар. Алар арасында тәвә кошлары өч төрле: Көньяк Америка нандуы, Австралия эмулары һәм Африка страуслары.

ЭКОФЕРМАГА КҮПМЕ КЕШЕ КИЛӘ:

2021 ел– 3 000 кеше;
2025 ел – 19 000 кеше.

ЭКОБАЗАДА КҮПМЕ КЕШЕ ЯЛ ИТӘ:

2022 ел– 450 кеше;
2025 ел – 2040 кеше.

ПЛАННАР ҺӘМ НИЯТЛӘР:

- Туристларга фермер продуктларыннан ризыклар тәкъдим ителә торган кафе төзү.
- Экопаркның яңа җанварлары өчен иркен вольерлар кору.
- Ял базасын төзекләндерү эшләрен дәвам итү.

Татарстан – Россиянең алтын туристик маршрутында төп нокталарның берсе: 2025 елның беренче алты аенда гына да республикада 2,2 миллион кеше кунак булып киткән. Татарстан Республикасында туризм белән кунаклар кабул итү өлкәсен үстерүдә үзеннән шактый җитди өлеш керткән оешмаларның берсе – «Буревестник» ТК» ҖЧҖ. Ул туристларны истәлекле урыннарга йөртүне тәэмин итә. Предприятиенең эш тәҗрибәсе турында «Татарстан» хәбәрчесенә компания директоры Вячеслав Улитин сөйләде.

«БУРЕВЕСТНИК» КАНАТЛАРЫ: УҢАЙЛЫЛЫК ҺӘМ ЫШАНЫЧЛЫЛЫК

Дмитрий Сивков

– Вячеслав Михайлович, сезнең компания көчле җитештерү-техника базасына ия, һәм ул Россиядә шактый яхшы билгеле. Компания үз эшчәнлеген кайчан һәм ничек башлады? Шуны да искә алып узыйк әле...

– Безнең эшчәнлек 20 ел элек – 2004 елның көзендә башланды. Өч тотылган автобус белән биш кешедән торган штат бар иде. Бүген предприятие паркында 100 дән артык берәмлек транспорт исәпләнә. Бу – урта һәм югары уңайлылык классына караган заманча автобуслар, төрле сандагы туристларны сыйдыра ала торган микроавтобуслар, шулай ук премиум һәм бизнес-класстагы җиңел автомобильләр. Компаниянең автопаркы даими яңартылып тора: транспорт чараларының уртача яше – 2-4 ел тирәсе, машиналар әйдәп баручы дөнья җитештерүчеләреннән өр-яңа килеш сатып алына. Барлык транспорт чаралары да тәүлекнең теләсә кайсы вакытында, төрле һава торышы шартларында юлга кузгалырга әзер. Безнең компания үз алдына куелган иң катлаулы бурычларны тиз арада башкарып чыгарга сәләтле.

– Сезнең автобуслар үзләрен Татарстанда гына түгел, аннан читтә дә сынатмады, дип беләбез.

– Бу, чыннан да, шулай. Бүгенге көндә «Буревестник» транспорт компаниясе – республикада заказ буенча кешеләр йөртү ягыннан лидерлар арасында. Безнең автобуслар туристлар төркемнәрен бөтен Россия һәм якын чит илләр буйлап йөртә. Әмма эштәге иң зур уңышыбыз дип эре дөньякүләм һәм халыкара чараларны тәэмин итүне исәплибез. Болар – ФИФА Конфедерацияләр Кубогы, Россиядә 2018 елда узган футбол буенча дөнья чемпионаты, Казанда 2019 елда узган WorldSkills һөнәри осталык буенча дөнья чемпионаты, Красноярскида 2021 елда узган Кышкы Универсиада, узган елгы БРИКС илләре Уеннары һ.б. шундый мәртәбәле, колачлы чаралар.

Агымдагы елның май аенда «Буревестник» ҖЧҖ Россия һәм Ислам хезмәттәшлеге оешмасы илләренең «Россия – Ислам дөньясы: KazanForum 2025» Халыкара икътисади форумын транспорт белән тәэмин итте.

– Сезгә иң югары дәрәҗәдәге чараларны оештыручылар да ышанып карый, гадәти пассажирлар да зур хөрмәт белдерә. Интернетта аларның күпләгән рәхмәт сүзләрен табып укырга мөмкин. Уңайлылык белән ышанычлылык, хәвеф-хәтәрсез йөрүләрдән тыш, машина йөртүчеләрне исемләп атап чыгалар – бик тәртипле, игътибарлы, итагатьле, кеше хәленә керүчән, дип искә алалар...

– Хезмәт күрсәтүдә сыйфат билгесе, пассажирларга карата игътибарлылык, әдәплелек, тәртип белән эш итү, дисциплинаны бозмау, юллардагы куркынычсызлык – бу «Буревестник»ның төп эш кагыйдәләре. Компания штаты югары квалификацияле һәм тәҗрибәле машина йөртүчеләрдән тупланган, аларның белмәгән-йөрмәгән юллары юк диярлек. Ремонт базасы, эксплуатация хезмәте, җитештерү-техника бүлеге һ.б. юнәлеш белгечләре турында да шуны ук әйтергә була. Һәр хезмәткәр көченнән килгәннең барысын да эшли бездә. Шуңа да һәр сәфәр, маршруты һәм юл аралыгының озынлыгына карамастан, бик уңайлы шартларында уза. Без үзебезнең коллектив белән лаеклы рәвештә горурланабыз!

Инде сүземне йомгаклап, транспорт өлкәсендә хезмәт куючы барлык белгечләрне дә һөнәри бәйрәмнәре – Автомобиль һәм шәһәр транспорты хезмәткәрләре көне белән тәбрик итәм! Аларга ныклы сәламәтлек, эшләрендә зур уңышлар, уңайлы, яхшы сәфәрләр, төзек юллар һәм гаиләләренә иминлек насыйп булсын! Т

Фото: novoshishminsk.ru. РЕКЛАМА

игелекле эшләр

мәңгелек кыйммәтләр /

акыллы гамәлләр

Бу санда тәкъдим итәбез:

Онытылмас исемнәрне **ничек** искә алабыз

Альберт Әсәдуллин **ни өчен** Татарстанга сирәк килә

Касай авылының үзенчәлеге **нәрсәдә**

Исәнбаевлар йорты **ничек** сакланган

ГАБДУЛЛА ЗӨЛКАРНӘЙ: ЗАМАН ТАЛӘП ИТКӘН ГЕРОЙ

Айдар Шәйхин

Габдулла Зөлкарнәй исемен мин ялгыш кына күреп алдым. Казанның Горький паркы эргәсендәге Туганнар каберлегендә җирләнгән шәхесләрнең берсе ул. Революционерлар, Гражданнар сугышы каһарманнары һәм Һади Такташ, Галиәсгар Камаллар белән бер зиратта соңгы урынын тапкан кеше турында нишләп бик аз беләбез соң?

Драматург, язучы, җәмәгать эшлеклесе. ТатРАБИС (Татар совет сәнгатькәрләренең профессиональ союзы) рәисе. Габдулла Зөлкарнәев җир йөзендә 30 ел гына гомер кичерә, әмма үзеннән соң эз калдырырга өлгерә.

БИОГРАФИЯГӘ ШТРИХЛАР

Габдулла Галим улы Зөлкарнәев тумышы белән Татарстан кешесе түгел. Ул 1905 елның 3 октябрендә хәзерге Казахстанның Петропавловск шәһәрендә ат белән йөк ташучы гаиләсендә туа. Ун яшендә Петропавловск шәһәрендә беренче баскыч татар мәктәбенә укырга керә һәм аны 1919 елда тәмамлый.

Әтисе вафат булгач, гаилә терәге булып калган Габдулла 15 яшеннән тимер юлда кара эшче булып көн күрә. Тәрҗемәи хәле турындагы язмага ышансак, 1922–1924 елларда аның консерв заводында себерүчеләр (метельщиклар) артелендә эшләве билгеле. Бу елларда ук комсомолга кабул ителә. Анна-

Габдулла Зөлкарнәев коллегалары арасында.

Фотолар ТР Милли музее фондыннан

ры ул тагын бер ел туган шәһәрендә Салым идарәсенең курьеры булып хезмәт куя да, ниһаять, Казанга күчеп китә.

1925 ел. Татар республикасының беренче юбилее, яңа совет дәүләте тарихының биш еллык этабына йомгак ясала торган вакыт. Габдуллага нибары 20 яшь. Ул Казан сәнгать техникумының театр бүлегенә укырга керә. Техникумда укуын тәмамларга өлгерми, Кызыл Армиягә мобилизацияләнә һәм Одесса шәһәренә, 151 нче дивизиянең 153 нче полкына җибәрелә. Гаскәри хезмәтен тәмамлап, 1929 елда Казанга кайта һәм техникумда укуын дәвам итә. Шул ук елны аны РАБИСның өлкә бүлегенә эшкә чакыралар, җаваплы сәркатип вазыйфасына билгелиләр. 1929 елда ул партиягә кабул ителә.

Зөлкарнәевнең җәмәгать эше дә бара. Мәсәлән, ул Яңа Татар бистәсендәге татар клубында драма түгәрәген җитәкли. Татар академия театры янындагы колхоз театрында сәяси җитәкче (политрук) вазыйфасын башкара һәм татар театры музее өчен тарихи материаллар туплау белән шөгыльләнә. 1931 елда театр техникумында белем алуы тәмамлана, аңа «Актёр һәм клуб инструкторы» квалификациясен раслый торган диплом тапшырыла.

Ниһаять, 1930 елда ул сәнгать хезмәткәрләренең Х съездында ТатРАБИС үзәк комитеты рәисе итеп сайлана, ягъни республика профсоюзлары җитәкчесе була. Бу вазыйфасын ул 1934 елның 15 гыйнварына кадәр башкара.

Тормышының соңгы этабында – янә Кызыл Армия сафларында. Запастагы офицерны мобилизациялиләр һәм Татар укчы полкына взвод командиры итеп билгелиләр. Шул ук вакытта, әдәбият-сәнгать кешесе буларак, ул хәрби часть клубы мөдире булып та тора.

Аның бу дәвердәге эшчәнлеген хезмәттәшләре яхшы сүзләр белән искә ала. Зөлкарнәевнең тәртипле, пөхтә кеше булуына, эшне нәтиҗәле итеп оештыра белүенә игътибар итәләр.

ТАТРАБИС ҖИТӘКЧЕСЕ

РАБИС һөнәри берләшмә, ягъни профсоюз буларак 1919 елда ук оештырыла. Ул бөтен СССРдан йөз меңгә якын сәнгатькәрне, театр, музыка, кино, фотография, әдәбият әһелләрен берләштерә. Аның «Рабис» исемле журналы да чыга, даими съездлары уза. Оешма үзенә сәнгать эшлеклеләренең матди хәлен яхшырту, хезмәт хакларын арттыру кебек зур максатлар куя. Сәнгатькәрләрнең һөнәри берләшмәсе сәнгать оешмаларының эшен тикшерә, ара-тирә җаваплы кешеләрен инспекция өчен җибәрә. РАБИСның ОГПУ белән хезмәттәшлегә турында да язалар. Әлбәттә, РАБИС идеологик нигездә корылган оешма була. Аның үзәк комитетын



Габдулла Зөлкарнәевнең хатыны – актриса Әминә Вәлиева.



АВТОБИОГРАФИЯ

Командира взвода [illegible] полка

Зулкарнаева Абдуллы [illegible]

Я, родился в 1905 году Октября [illegible] дня в г. Петропавловске в семье чернорабочего (ломового извозчика).

10 лет. поступил учиться в Тат. школу I ступ. г. Петропавловска и окончил ее в 1919 г. (14 лет)

После смерти отца работал на железной дороге в качестве чернорабочего с 20 по 22 г. с 1922 г. по 24 год работал в Консервном Заводе в артели улицы метельщиков, с 24 по 25 г. работал курьером Налогового Управления в г. Петропавловске, с 25 г. поступил учиться в Техникум Искусства г. Казани не окончив уч. зав. по мобилизации был взят в Красную Армию в г. Одессу в 153 пол. в 151 дивиз. 1929 г. вернулся из Красной Армии и продолжал учение в Т. И. и после чего взяли на работу 1929 г. в качестве Ответ. Секретаря Обл. Отдела Рабиса. 1930 г. на Х С'езде Работников Искусства в Т. Р. выбрали Пред. Правления Татрабиса. Работал по 15/I-34 г. С 15/I-34 г. мобилизован в ряды Красной Армии, в настоящее время работаю в качестве Командира взвод.

В 1923 г. вступил в комсомол, в 1926 г. вступил кандидатом ВКП(б), в 1929 г. вступил в члены Партии.

Работал во всех общественно партийных организациях в качестве Секретаря Комсомола, руководителем Политкружка, Руководителем Драматических Кружков и начал с 1928 г. драматическую работу, тип произведение [illegible] "На границе", "Нож против ножа" и "Тайна раскрыта" и пол "Вихрь" в академическом Театре, кроме этого [illegible] клубных и репертуар малых форм ставил во всех рабочих клубах Т. Р.

28/IV-36 г. Зулкарнеев.

Подпись т. Зулкарнаева заверяю. Уполномоченный ЦК Рабис по ТР



АВТОБИОГРАФИЯ

Амины Валеевны Валеевой.

Родилась в 1910 году, 25 Мая в г. Актюбинске (ныне Казакско[illegible]

Отец мой, примерно, до 1913 года занимался торговлей дегтем и древесным углем. В 1913 г. мой отец умер, и я осталась 3-х лет. До 1918 года воспитывалась у матери, а далее у брата партийца-наборщика и в Детском Доме (I год). С 1923 года воспитывалась у зятя Тарпищева, партийца, и в 1925 г. поступила в Москве на фабрику "Красный Текстильщик" в качестве ученицы Фабзавуча. В начале 1927 года поехала в Донбасс, где поступила на работу на Электростанцию Штерстроя. Проработав там I год, поехала в Казань, где поступила учиться в Татарский Театральный Техникум. В последнем училась 2 года и ныне перешла на 3-й курс.

Валеева А. август 1929 г.

җитәкләгән Яков Боярский болай дип яза: «Әгәр хакимият пролетариат кулында булса, пролетариат социалистик җәмгыять төзесә генә рәссам, сәнгать эшлеклесе чын ирекккә, эчке иҗат хөрлегенә ия була». РАБИСның Татарстандагы бүлеге дә шундый үзенчәлекле «ирек» шартларында эшләп килгән.

ЗӨЛКАРНӘЕВ, ТАТРАБИС ҖИТӘКЧЕСЕ БУЛАРАК, ТАТАРСТАННЫҢ БАРЛЫК СӘНГАТЬ ОЕШМАЛАРЫ БЕЛӘН ЭШЛИ, МӘДӘНИ ТОРМЫШНЫҢ НИЧЕК КАЙНАГАНЫН ЯХШЫ БЕЛӘ. МУЗЕЙДА САКЛАНГАН ДОКУМЕНТЛАР АРАСЫНДА АНЫҢ, МӘСӘЛӘН, ТАТАР ДӘҮЛӘТ ТЕАТРЫНЫҢ КОЛХОЗЛАРДА ЭШЧӘНЛЕГЕ ТУРЫНДА ОТЧЕТЛАРЫ, БИХИСАП КОМАНДИРОВКАЛАРГА ЮЛЛАМАЛАРЫ, ҖЫЕЛЫШ ҺӘМ КИҢӘШМӘ БЕРКЕТМӘЛӘРЕ БАР.

ҮКЕНЕЧЛЕ ФАҖИГА

1934 елның башында Кызыл Армия Зөлкарнәевне мобилизацияли. Ул ТатРАБИСтагы вазыйфасын калдыра һәм Казанда укчылар полкында хезмәт итә. Әлбәттә, ул инде командир була, аны «һөнәри хәрбиләр» сафына кертергә ярыйдыр. Сәнгать эшендә тәҗрибәсе зур булганга, аңа кызылармиячеләрнең мәдәни тормышы өчен җавап бирү дә йөкләнә. Шушы эш аны харап итә дә инде.

1935 елның 6 сентябре. Габдулла Зөлкарнәев, Казан хәрбиләрнең сәнгать үзешчәннәрен җитәкләүче буларак, Куйбышев шәһәрендә узасы смотрга барырга тиеш. Юлга кузгалганда, ул утырган автомобиль һәлакәткә очрый. Габдулла машина йөртүчене этеп чыгарырга өлгерә, машинадагы башка пассажирлар да исән кала. Әмма драматург үзе кузов астына тәгәри…

Габдулла Зөлкарнәев белән хушлашу мәрасимен Кызыл армия йортында 9 сентябрьдә үткәрәләр. 30 яше тулыр-тулмас һәлак булуы Казан җәмәгатьчелеген тетрәндерә. Аны, күренекле сәнгать хезмәткәре һәм хәрби кеше буларак, Туганнар каберлегендә җирлиләр.

Кабер ташына «хатыны, улы Ренат һәм кызы Риммадан» дип язылган. Гаилә башлыгы һәлак булгач, хатыны һәм сабый балаларына персональ пенсия билгеләнә. Хөкүмәтнең аларга игътибары тулысы белән аклана, чөнки бу нәселдән тәрбияле, зыялы кешеләр чыга.

Зөлкарнәевнең хатыны Әминә Вәлиева 1910 елның 25 маенда Актүбә шәһәрендә туган. Әтисенең күмер һәм дегет сатып көн күрүе, 1913 елда үлеп, балаларын ятим калдыруы билгеле. Әминәгә 8 яшь чакта энисе дә үлеп китә, кызны башта абыйсы тәрбияли, бераздан бер елга балалар йортына тапшырыла. 1925 елда Әминә Мәскәүдәге «Красный текстильщик» заводына килә һәм фабрика-завод өйрәнчелегендә укый башлый. Ике елдан Донбасска китә һәм Штерстрой электр станциясендә эшли. Ниһаять, сәнгатькә һәм татар тормышына тартылуы нәтиҗәсендә, 1928 елда Казанга күчеп килә һәм татар театр техникумына укырга керә. Татар театрында озак еллар артистка булып хезмәт итә. Ире һәлак булгач, яңадан кияүгә чыкмый, гомерен балаларына багышлый.

Зөлкарнәев комсомол бюросы коллективы белән.



ONTЬLMAS ISTƏLEK.

Min iptaş Aʙdulla Zelqarnajef ʙelən ʙerence martəʙa 1930 ncь jьlnьꞑ fivral' urtalarьnda tanьştьm. Mine Tatar Davlət Akademiə direksiəse kymәklәşy frontьna jardəm ity nigezendə Narkompros tarafьnnan cьqarьla torqan çide xudoƶestvo ʙrigadasьnьꞑ ʙersenə xudoƶestvo çitəkcese itep ʙilgeləgən ide. Teatrdan mandat alьp taqajen itelgən ʙrigadamьz ezləp, teatr texnikumьna kittem. Ul kennərdə texnikum grazdannar corьnlaqь suqьşь ştapqa əverelgən, Bylmələrdə çide ʙrigadanьꞑ çьr-ʙiylərgə ripetitsiələr ʙara, terle ʙesedalar ytkərelə, Ojьştьru xuçalьq eşləre ʙelən caʙьp jeryce keşelər ʙelən tulь ide. Texnikum konsəleriəsennan soraşqannan soꞑ sez eşləjəcək 4 nce ʙrigadanьꞑ çitəkcese, dip ozьn ʙujlь jəş kenə ʙer jeget ʙelən tanьştьrdьlar. Ul jəş jeget Ƣaʙdulla Zelqarnaj ide. Ul kiragennan artьq eşkə cumьl çide ʙrigadanь ojьştьrьp cьqaru ştaʙьnda, texnikumnьꞑ xuçalьq eşlərendə aktif eş alьp ʙara. ikencedən tizden avьllarqa cьqacaq ʙrigadanьꞑ çitəkcese həm artist ide. Ocencedən şuşь dyrt tatar ʙrigadasьna "Serlər ciçelde" digən əsəren aşьqьc reveştə jazdьrtqan caqь ide. Bez ip. Zelqarnajef ʙelən Narkompros taqajen itkən srokta ʙrigadanь ʙeten jaqtan xəzerləp, martnьꞑ ikence kenendə Mamadьş, Saʙa, Təkəneş rajonnarьna cьqьp kittek. Avьllarda ʙezgə eş kyp ide. Ber jaqtan avьlnьꞑ jarlь, ʙatrak, urta xəlle krəstiənnəre kymәklәşy intuziazmasь ʙelən qaʙьnьp, kolxoz ojьştьru eşendə qajnasalar, ikence jaqtan kymәklәşygə qarşь kytərelgən mulla, kulak həm alar qojrьqlarьnьꞑ qatь reveştə kərəş acqan caqlarь ide. Bezneꞑ ʙurcьʙьz, ʙer spektakl ujnav ʙelən genə ciklənmicə, hər avьlda stina gazetasь cьqaru, sel'sovet kooperatsiə eşlərenə qatnaşu, spektakl allarьnnan partiə, provitelstvonьꞑ terle qararlarьn massaqa çitkery eşleren də alьp ʙara idek. Menə şuşь zur məs'yl ʙurьclarnь tormьşqa aşьru vazifasь ʙilgele ʙrigadanьꞑ çitəkcese ip. Zelqarnajef estendə ide. Ul avьlqa ʙarьp teşy ʙelən, avьl aktifьnьꞑ ajrьm utьrьşьn ytkərə, stina gazetasьn cьqaruda çitəkcelek itə. Avьldaqь terle çiteşsezleklər tur...

Габдулланың улы Ренат Зөлкарнәев – атаклы травматолог һәм ортопед. Нәкъ менә ул әтисенең мирасын Татарстан Милли музеена китереп тапшыра. Аның балалары да медицина өлкәсендә зур уңышларга ирешә.

КЕЧЕ ФОРМАЛАР ДРАМАТУРГЫ

Драма түгәрәкләрен җитәкләгәндә, Зөлкарнәев бер проблемага игътибар итә: хәрби темага, Гражданнар сугышы тарихына багышлап язылган татарча драма әсәрләре аз. Бу, гомумән, шул чорда күтәрелгән проблемаларның берсе. Аны хәл итәр өчен әдәбиятка «ударникларны» һәм хәрбиләрне җәлеп итәргә карар кылына. 1930 елда исә ТатЛОКАФ – Кызыл Армия һәм флот язучыларының Татарстан оешмасы барлыкка килә. Әйе, хәрби темага иҗат итүчеләрне берләштерү һәм бергәләп үстерү максатыннан ул елларда Кызыл Армия, флот язучыларының аерым әдәби оешмасы төзелә.

Бердәм язучылар берлеген оештыру карары барлыкка килгәнче, ягъни 1932 елга кадәр ЛОКАФның Татарстан бүлеге яхшы гына эшләп ала. Аның җитәкчелегендә Кави Нәҗми, Газиз Иделле һәм Мирсәй Әмир тора. ТатЛОКАФ «Штурм», «Манёвр», «Кызыл Армия ударниклары» һәм «Сакта» исемле әдәби альманахлар бастырырга өлгерә. Чыннан да, оешмага каләм тибрәтүчеләр җәлеп ителә, Мәскәүнең дә ярдәме була: ЛОКАФ бөтенсоюз оешмасы буларак эшли, ил буенча аңа 2500 хәрби кеше һәм 120 «коралсыз» язучы керә.

Зөлкарнәев шушы оешманың идея юнәлешенә дә килеп кушыла. Мәсәлән, аның «Пычакка – пычак» дигән инсценировкасы кызылармиячеләрнең эстрада сәхнәләре өчен махсус языла. 1931 елда исә ул «Штурм» исемле ТатЛОКАФ альманахында басыла.

1932 елда Татар академия театрында Зөлкарнәевнең дүрт пәрдәлек «Өермә» драмасы буенча спектакль куела. Спектальнең режиссёры Сөләйман Вәлиев-Сульва була, ә музыкаль бизәлеш өчен Салих Сәйдәшев җавап бирә. Өч пәрдәлек «Ана» драмасы, «Повар» комедиясе, «Ил чигендә» драмасы, кече формадагы төрле инсценировкалары бар. 1930 елда «Серләр чишелде» исемле драмасы аерым китап булып басыла. Бу пьесаларының геройларына гына игътибар итегез: урта хәлле крестьяннар, авыл советы идарәсе әгъзалары, комсомоллар, кулаклар, авыл куштаннары һәм башкалар. Шушы исемлектән үк әсәрнең темасы һәм юнәлеше аңлашыладыр.

Зөлкарнәевнең әсәрләре беренче чиратта эшче театрларда, күчмә һәм колхоз сәхнәләрендә уйнала. Аның төп өстенлеге – кече театр формалары өчен исәпләнгән сценарийлар язуы. Ул елларда бу проблема да күтәрелә. Аңлашыла ки, академия театры зур формалар белән эшли һәм шуңа исәпләп репертуарны формалаштыра. Әмма 1930 нчы елларда татар театр сәнгатендә дәүләт тарафыннан гамәлгә куелган зур театрлардан башка, бихисап җирле театр түгәрәкләре, клублардагы берләшмәләр һәм колхоз театрлары да бар. Аларга күп кеше таләп ителгән пьесалар белән эшләү бик уңайсыз. Шуңа да матбугатта «кече формаларны үстерү» таләбе яңгырый. Үзе дә драма түгәрәкләрендә һәм клубларда эшләгән кеше булгач, Зөлкарнәев бу проблеманы яхшы аңлый һәм чишелешенә үз өлешен кертә.

Габдулла Зөлкарнәйнең иҗат мирасы бай түгел, булганы да бүгенге укучыга билгесез. Зөлкарнәев-драматург белән 1920–1930 нчы еллардагы әдәби барышны һәм театр тарихын җентекләп өйрәнгән галимнәр генә таныштыр, дип уйлыйм. Озак яшәмәгән һәм иҗат потенциалын тулысы белән ачарга өлгермәгән әдипләр турында шуны гына әйтеп була: гомере озынрак булса, әле язар, үзен төрле яктан күрсәтер иде. Шунысын да онытмыйк: Татарстан Милли музее фондында Габдулла Зөлкарнәевнең моңарчы басылмаган һәм куелмаган драма әсәрләре дә саклана. Аларны өйрәнү бу драматургның иҗатын тирәнрәк күзалларга мөмкинлек бирәчәк.

«Онытылмас истәлек». Таҗи Гыйззәт язмалары.

www.protatarstan.ru
ТАТАРСТАН
«Нәкъ казан артында бардыр...»
Сайттагы яңалык
Яңалыклар

Реклама 16+

АЛЬБЕРТ ӘСӘДУЛЛИН: «ТУГАН ШӘҺӘРЛӘРЕМ ИКӘҮ – КАЗАН ҺӘМ ЛЕНИНГРАД»

Фото: Альберт Әсәдуллин архивыннан алынды

Евгения Чеснокова

Кайчандыр Ленинград сәнгать академиясендә укыр өчен яраткан Казанын ташлап китәргә мәҗбүр булган Сукно бистәсе малаеның тавышы бүген бөтен дөньяга мәгълүм, аны халык бик ярата. Әңгәмәдәшебез – җырчы, Россиянең – атказанган, Татарстанның халык артисты Альберт Әсәдуллин.

КАБАТЛАНМАС ТАМАША

– Альберт Нуруллович, быел Казан 1020 еллыгын билгеләп үтә. Ә сез туган шәһәрегезнең меңьеллыгында чыгыш ясавыгызны хәтерлисезме әле?

– Әлбәттә! Ул вакытта Казанда берничә концерт мәйданчыгы эшләде, шулай да төп мәйдан Кремль янындагысы иде. Ак ташлы Кремль диварлары фонында бәйрәм концерты – бу искиткеч, кабатланмас тамаша! Гаять зур, колачлы! Артистлар белән тамашачыларны берләштергән искиткеч рәхәт

Әнисе һәм апалары белән, 1952 ел.

Орфей ролендә.

һава торышын һәм гаҗәеп мохитне онытып буламыни?!

Мин биючеләр белән чыгыш ясадым. Барысы да бик яхшы әзерләнгән, яктылык та, тавыш та искиткеч иде! Габдулла Тукай шигыренә язылган «Тәфтиләү»не а капелла җырладым, тамашачылар алкышка күмде. Тагын берничә җыр башкардым, шул исәптән Besame Mucho дигән хитны да.

Егерме ел үтте инде, ә бу соклангыч манзара әле һаман күз алдымда тора!

РОКТАН – ТАТАР ҖЫРЫНА

– Сезнең репертуарда татар җырлары берничә елдан соң гына пәйда булды бит?

– Сүз дә юк, мин Ленконцертта эшли башлаганда, без бары тик рус телендә генә җырлый идек. Ә менә Бөтенсоюз эстрада артистлары конкурсында Гран-при откач, «Алтын Орфей» лауреаты булгач һәм үз коллективым белән чыгыш ясый башлагач... Мин хәтта төгәл хәтерлим: бу 1980 ел иде, Донецкидагы гастрольләр вакытында кинәт залдан язу килде: «Зинһар, татар телендә берәр җыр башкарыгыз әле!» «Бик рәхәтләнеп!» - дим. Үзем исә эчемнән тиз-тиз генә белгән татар җырларымны барлыйм...

Музыкантлар, әлбәттә, моңа әзер түгел иде, һәм мин а капелла «Әниемә хат» җырын җырладым. Ул концертта иң кайнар алкышлар татарча җырымнан соң яңгырады. Аннары мин бу җырны, үз әниемә багышлап, программага да кертә башладым. «Залда татарлар бармы?» – дип сорый идем. Бер яки ике кул гына күтәрелсә дә, мин: «Сезнең өчен татарча җыр башкарырга телим. Һәм барыгыз өчен дә, әлбәттә», – дип, аны башкара идем.

– Әйдәгез бераз үткәнгә әйләнеп кайтыйк һәм ничек сәхнәгә килеп эләгүегезне, күп кенә конкурслар лауреаты булуыгызны искә төшерик. Сез бит Казаннан Ленинградка архитекторлыкка укырга киткәнсез...

– Мин чыннан да Сәнгать академиясендә укыдым. Тик нәкъ менә диплом проектын ясар вакыт җиткәч чирләп киттем һәм үпкә ялкынсынуы белән хастаханәгә эләктем. Анда бер айга якын яттым. Терелеп чыккач, безнең остаханә җитәкчесе, Ленинградның атаклы архитекторы профессор Александр Владимирович Жук миңа: «Алик, син хәзер диплом эшен дәвам итә алмыйсың, сиңа башта тернәкләнеп бетәргә, ныклап аякка басарга кирәк», – диде.

Тик бу академиядәге мәҗбүри тәнәфес вакытында яшәр өчен ничектер акча эшләргә кирәк бит. Ул вакытка минем гаиләм, кечкенә улым бар иде инде. Сәнгать академиясеннән чыгып барганда, күрәм, вестибюльдә миңа каршы Ленконцерт администраторы Юра Белишкин килә. Минем зарымны тыңлады да: «Борчылма, әйдә безгә», – диде. Һәм мин Ленконцертка, «Веселые голоса» ансамбленә килеп эләктем. Бик шәп ВИА иде ул!

Ә аннары миңа «Поющие гитары» ансамбле җитәкчесе Анатолий Васильев игътибар итте. Җитмешенче еллар уртасында Александр Журбин музыкасына «Орфей һәм Эвридика» дип аталган беренче совет рок-операсын куярга җыенгач, алар бик озак Орфей ролен башкаручыны эзләгән булып чыкты. Музыка инде бар, ә спектакльдә җырларлык кеше юк. Җырларга гына түгел, нәкъ менә музыкаль спектакльдәге тулы бер партияне башкарырга кирәк. Анда вокалист булу гына аз, ышандырырлык итеп рольгә дә керергә кирәк.

Режиссёр Марк Розовский килә, солистларны карый – берсе дә ошамый... «Алар барысы да багана кебек басып тора, ә миңа табигать баласы, Маугли кирәк», – дип аңлата ул. Шунда бер дусты аңа Пушкиндагы Офицерлар йортында оештырылган бию кичәләрендә Альберт исемле татар егете җырлавын, аның югары ноталарны җиңел алуын әйтә...

«Орфей һәм Эвридика» премьерасы Ленинградта 1975 елның июлендә булды. Әлбәттә, беренче совет рок-операсындагы бу төп роль миңа моңарчы күрелмәгән танылу китерде!

– Ул еллар... һәм рок-опера?

– Юк, билгеле, ул вакытта спектакльне рок-опера дип атарга ярамый иде. Ленконцерт парткомы катгый: юк дигәч юк. Сәнгать советының бер утырышы, икенчесе үтә... Икенчесеннән Анатолий Васильевны да, Саша Журбинны да куып чыгара язалар. Һәм менә өченче утырышка әлеге спектакльгә либретто язган драматург Юрий Димитрин килә. Урыныннан торып баса да: «Без, музыка культурасы эшлекләләре, Бертольд Брехтның кем икәнен барыбыз да яхшы беләә», – ди. Барысы да бер-берсенә карашып ала, башларын кага. Ул дәвам итә: «Бертольд Брехтның

бөтен дөньяга танылган «Трёхгрошовая опера» пьесасы бар. Һәм менә Бертольд Брехт, антифашист, коммунист (бу сүзләр вакытында худсоветта барысының да иңнәре турая төшә), үз пьесасына зонг җырларын керткән – алар ярдәмендә спектакльдә катнашучылар, үз образларыннан чыгып, алдагы күренешне йомгаклый, аңа фәлсәфи аңлатма бирә һәм киләсе күренешне алдан хәбәр итә. Безнең спектакльдә дә нәкъ шулай! Бу – Бертольд Брехт принцибы. Әлбәттә, бу рок-опера түгел, бу зонг-опера!» – ди.

Барысы да килешә: «Бу бит бөтенләй башка нәрсә! Әлбәттә, Бертольд Брехт, зонглар!» – диләр. Шул рәвешле «Орфей һәм Эвридика» зонг-операсы исемен раслыйлар. Ләкин ярты елдан соң ук инде афишаларда «рок-опера» дип бастыра башладылар. Бу инде бүтән беркемне дә хафаландырмады, чөнки без Ленконцертка искиткеч күп акча эшли башладык! Бөтен ил буйлап спорт сарайларында дүрт, биш, алтышар мең тамашачы каршында чыгыш ясадык... Һәм алар шыгрым тула иде! Киевта, хәтерлим, динамикларны тышкы якка чыгардылар, чөнки халык бина тирәсендә басып тора... Атлы милиция саклады хәтта! Сез мондый хәлне бүген беркайда да күрә алмыйсыз! Ул чагында бу үзенә күрә бер мәдәни шартлау булды!

Мондый уңыштан соң, аңлашыла инде, мине конкурсларга җибәрә башладылар. Беренчесе 1976–77 елларда «С песней по жизни» Бөтенсоюз конкурсы иде. Анда без Роза Рымбаева белән җиңүче булдык. 1978 елда мин Сочида Бөтенроссия вокал конкурсында Гран-при алдым, ә 1979 елда СССРның төп конкурсы – Бөтенсоюз эстрада артистлары конкурсында Гран-при яуладым. Шуннан соң мине автомат рәвештә Болгариядәге «Алтын Орфей» халыкара конкурсына җибәрделәр. Анда, әлбәттә, Орфей барырга тиеш иде!

Ләкин мин Гран-при алмадым... Анда, ул вакытлардагыча, барысы да алдан ук хәл ителгән иде – болгар егете җиңде. Бик яхшы вокалист. Мин бер баскычка түбәнрәк булып чыктым, ләкин барыбер лауреат бит. Хәтерлим, болгар җырын җырладым, аннан Led Zeppelin төркеменең «Күккә баскыч» җырына охшатып баллада ясадым. Бик югары ноталар алдым! Халык аягүрә басып кул чапты! Шул уңыштан соң, миңа үз ансамблемне бирделәр. Һәм аның белән инде татар җырларын да җырлый башладым.

ПАКЬЛӘНҮ ЯҢГЫРЫ

– Сәхнәдә татарча җырлый башлагач, сез театрлаштырылган уникаль «Мәһди» спектаклен тудырдыгыз, аны кайвакыт татар рок-фолк-операсы дип атыйлар...

– Әйе, ләкин бу әле соңрак булды. Татар телендә нииндидер әһәмиятле әсәр иҗат итү идеясе туды, әмма мин җыр артыннан җыр бара торган гадәти программа эшләргә теләмәдем. Мин бит профессиональ сәхнәдә чын-чынлап нәкъ менә музыкаль спектакль жанрында, «Орфей һәм Эвридика»да пәйда булдым. Үземнең студентларыма, шәкертләремә хәзер гел әйтәм: вокалист үзен бөтен тулылыгында күрсәтә алган иң бөек жанр – музыкаль спектакль ул. Опера, оперетта, мюзикл, рок-опера, сюита, симфоник спектакль... Боларда актёр уникаль образ тудыра ала.

Шуңа күрә минем максат концерт кына түгел, ә сюжетлы тамаша кую иде. Нигезендә татар халык җырлары булуын теләдем. Тамырларга кайтасы килә иде. Нәтиҗәдә спектаклебез Коръәннең «Рәхмәтле һәм Рәхимле Аллаһ исеме белән...» сүзләреннән башланып китә. Аннан соң бер мосафир пәйда була, ул уйларында моннан мең ел элеккеге чорга, Бөек Болгар заманына әйләнеп кайта, аннары халыкның мең еллык тарихы күрсәтелә. Асылда бу моноспектакль иде. Моно-рок-фолк-опера.

Башта минем төп бурычым винил диск яздыру булды. Һәм ул килеп тә чыкты. Бөтен материал студиядә Виктор Динов тарафыннан яздырылды. Аннары, спектакльдәге һәр номер мөстәкыйль булсын өчен, клиплы фильм төшерү идеясе туды. Бу идея белән мөрәҗәгать иткәч, дустым, телевидение режиссёры Леонид Александренко, «Мәһди»не сәхнәдә куярга кирәк, диде.

Ә ничек? Акча каян алырга? Ул: «Мәчеткә бар», – диде. Шулай итеп, мин Равил хәзрәт Гайнетдин белән очраштым. Ул материалның барысын да тыңлады һәм: «Бу бит искиткеч! Мондый бөек вакыйгага иң яхшы бүләк тагын нинди булырга мөмкин?!» – дип сокланды. «Нинди вакыйгага?» – дим. «Ничек, сез белмисезмени?..»

Һиҗри исәп буенча Ислам дине кабул ителүгә 1100 ел тула икән. Кайвакыт кешеләр махсус нииндидер датага әсәрләр яза, мин исә бу хакта белми дә идем. Ә Равил хәзрәт: «Бу сезнең эшегезнең әһәмиятен тагын да арттыра. Моны сезгә Аллаһы Тәгалә Үзе җибәргән!» – диде.

Һәм менә 1989 елның августында, бу бәйрәмгә бөтен дөньядан күренекле мөселман әһелләре җыелган Казанда, Үзәк стадионда спектакль куйдык. Режиссёры Дамир Сиразиев, берничә номерның музыка авторы Мәсгудә Шәмсетдинова иде. Минем өч искиткеч дустым, композиторлар Андрей Сикле, Андрей Андерсен һәм Сергей Сушко бик зур эш башкарды.

Мин стадион уртасында, яшел келәмдә Кәгъбә образы торачак, дип уйладым. Аның сызымнарын үзем сыздым, мин бит архитектор. Лазерлы зур шоу уйланылган иде, Ленинградтагы фирма белән сөйләштем, һәм алар ике фура белән гаять зур лазер җайланмаларын алып килде. Бу фантастика

Әтисе белән, 1983 ел.

Әнисе белән.

иде! Бик зур вакыйга, бигрәк тә ул заман үлчәмнәре буенча! Финалда ялтырап торган яшел лазер нуры Сөембикә манарасы буйлап әкрен генә һаман өскәрәк үрмәләде... Һәм аның түбәсендә кинәт балкып киткәндәй булды. Аннан соң – ярымай куелган урында. Иң очында. Менә шундый могҗиза!

Көне буе яңгыр яуды, ә спектакль башланырга бер сәгать кала туктады, болытлар стадион өстендә нәкъ түгәрәк буенча таралды да, йолдызлы күк йөзе ачылды. Могҗиза!

Ә финал күренешендә, мин «Фатыйха» сүрәсен укыганда, тагын яңгыр ява башлады. Һәм барыбыз да бу пакьләнү, сафлану, гөнаһлардан арыну, яңарудыр, дип ышандык.

КҮПКЫРЛЫЛЫК ҺӘМ ҮЗЕНЧӘЛЕК ТУРЫНДА

– Сез үзегезнең укучыларыгызны еш телгә аласыз. Кайда укытасыз?

– Герцен исемендәге Россия дәүләт педагогика университетында. Анда Музыка, театр һәм хореография институты бар, мин вокал кафедрасы профессоры булып торам. Мине укытырга чакырганда: «Аңлагыз, мин вокаль педагогика буенча бер генә брошюра да укымадым бит», – дип карыштым. Әмма институт директоры Ирина Аврамкова: «Консерватория тәмамлаган профессорлар күп, ә безгә сезнең тәҗрибәгез кирәк, сез аны яшьләргә тапшырыгыз», – диде. Менә шуның белән инде 15 ел шөгыльләнәм.

– Шәкертләрегезне нәрсәгә өйрәтәсез?

– Артист бриллиант кебек булырга тиеш. Төрле рольләрне бик шәп башкару өчен, аның төрле ялтыравыклы кырлары булу зарур. Кырлары никадәр күбрәк булса, артист шулкадәр баерак, тамашачы өчен шулкадәр кызыклырак.

– Заманча яшь башкаручылар турында нәрсә әйтә аласыз?

– Хәзер талантлар азрак, дип әйтә алмыйм. Материалда әдәпсезлек, күп булу, җирәнә җиткереп эшләмәү хафаландыра. Поэзия исә – бөтенләй берни турында да түгел, кайчак мәгънәсе юк. Күңел сафлыгы юк, җырларда йөрәк юк, ниндидер шаблоннар гына.

Миңа үпкәләмәгез, әмма бервакыт мин татар эстрада музыкасы турында, ул хәзер бертөрле генә, дип әйттем. Дөресен әйтәм, ничек бар – шулай. Әгәр бу татар җырына русча шигырь куйсаң, ул рус җыры булачак. Әгәр фин теленә алыштырсак, финнарныкы булачак. Тик татар җыры пентатоника, безнең матур мелизмнар белән сугарылган булырга тиеш бит. Алар нәрсәсе беләндер блюз әсәрләренә охшаган. Ни өчендер, бөек Пол Маккартни, Джон Леннон үз иҗатларында шотланд, инглиз халык җырларын файдаланырга оялмаган. Моны рок-музыкага керткән. Ә татар җыры гармониясе, көе буенча рус җырыннан берни белән дә аерылмый икән, бу – аяныч.

«ХАЛЫК КАРШЫНДА МИНЕМ НИНДИ ГАЕБЕМ БАР?»

– Соңгы тапкыр Казанда кайчан чыгыш ясадыгыз?

– 2024 елның язында минем 75 яшемә багышланган юбилей туры узды. Концертлар Казанда гына түгел, Чаллыда, әти-әниемнең туган җире Балтачта, Бөгелмәдә, Түбән Камада булды...

– Монда тагын концертлар белән кайту планы юкмы соң?

– Бар, ләкин берәү дә чакырмый. Ни өчен икәнен аңламыйм. Бәлки, мине чит кешегә саныйлардыр, чөнки бик күптәннән Петербургта яшим. Ләкин иҗатчының кайда яшәве мөһим түгел бит. Бөек биюче Нуриев күп еллар буе чит илдә яшәгән һәм иҗат иткән, әмма аның татар икәнен һәркем белә, Татарстанда аның белән горурланалар.

М. Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет театрында «Шагыйрь мәхәббәте» операсында Шүрәле образында.

Казанның 1000 еллыгы уңае белән уздырылган концертта.

Иң мөһиме, кеше Ватанын йөрәгендә саклап яшәсен һәм аны данлап иҗат итсен. Минем ике туган шәһәрем бар, берсе – мин физик яктан туган Казан. Балачагым үткән Сукно бистәсеннән бернәрсә дә диярлек калмавын күрү моңсу булса да, ул барыбер минем туган шәһәрем булып кала... Ә икенче туган шәһәрем – Ленинград, мин анда артист буларак дөньяга килдем.

Бәлки, Татарстан Мәдәният министрлыгында яшь артистларны гына кайгырталардыр. Гәрчә нормаль дөньяда бер концертта яшьләр дә, үзләрен яхшы хис иткән һәм яшьләрне күп нәрсәгә өйрәтә алырлык өлкәннәр дә булырга тиеш. Чыгышларым башкару осталыгында берни дә югалтмавымныраслый – вокал ягыннан да, актёрлык буенча да. Күпсанлы премияләр – моңа дәлил. Узган ел эчендә генә дә мин дүрт бөтенроссия вокал һәм актёрлар премиясенә лаек булдым.

Минем күп кенә танышларым: «Менә 30 августта – Республика көнендә – читтән килгән артистлар чыгыш ясый, ә нигә сез юк?» – дип сорый. Мин моңсу гына елмаям. Мин татар җырларын җырларга бик яратам, аларны рус тамашачысына җырлаганда, кешеләр елый, аңлыйсызмы? Әмма Татарстанга чакырмыйлар, гәрчә артистлар катнашындагы чаралар бик күп булса да.

Тик беләсезме, мин моның белән ничектер килештем инде. Чакырмыйлар икән, чакырмасыннар, ярар. Аллаһка шөкер, мине ярата торган үз тамашачым бар, спектакльләр, концертларым бар.

– Ә сезне хәзер кайда күрергә мөмкин?

– 8 сентябрьдә Санкт-Петербургның Нева проспектындагы «Колизей» залында соло концертым узды. Беренче бүлектә этнотөркем белән чыгыш ясадык, дөнья халыклары җырларын башкардык: татар, рус, карел, һинд, әрмән... Һәр җыр – кечкенә генә спектакль. Икенче бүлектә джаз-бэнд белән җырладым. Совет һәм Америка джазын.

Тагын әле мин Петербургның Рубинштейн урамындагы искиткеч «Зазеркалье» музыкаль театрында уйныйм. Идеясен театрга мин үзем алып килгән «Зәңгәр кош» мюзиклында минем өч ролем бар. Аларның берсе – Тылсымчы. Мин аңа Яктылык дигән исем бирдем. Ул балалар белән Зәңгәр кошны эзли һәм аларның бәхеткә юлын яктырта. Бу гаҗәеп матур, образлы спектакль, музыкасы – искиткеч шәп. Киләсе спектакль – 20 сентябрьдә.

Әйе, мин исән, мин эшлим. Миңа 76 яшь. Нибары 76. Мин кайчандыр үземә планка куйдым – «минус егерме» дип яшим. Минус егерме ел.

– Үзегезне формада тоту өчен махсус нәрсәдер эшлисезме?

– Искитәрлек берни дә юк. Ураза тота башладым, инде өч ел. Бию студиясенә йөрергә яратам. Кызганыч ки, еш кына дәресләрне калдырам, әмма Латин Америкасы биюләрен яратам. Бачата, сальса, Аргентина тангосын...

Һәм, әлбәттә, мин Аллаһы Тәгаләгә ышанып яшим! Ни эшләсәм дә, барыннан да элек мин Аңа багышлыйм! Ул миңа зур бүләк – Тавыш бирде, Аллаһка шөкер, мин аны югалтмадым. Моннан илле ел элек җырлаган ноталарны да җырлый алам. Бу сирәк күренеш, диләр. Һәм бу мактану түгел, бары факт кына.

Мин көн дәвамында биш вакыт намазны да укырга тырышам һәм һәрвакыт: «Йа Раббым, Аллаһым, миңа биргән бөек бүләгең өчен рәхмәт сиңа, минем тавышым Сине данлар өчен һәм кешеләрне сөендерү өчен... Үзең миңа биргән гомер буена җитсен иде ул», – дип телим.

МАДЬЯР МЕЛАНХОЛИЯСЕ, ЯКИ БУКЕР БЕЛӘН НОБЕЛЬ АРАСЫНДА 10 ЕЛ

Луиза Янсуар

Быелгы Нобель исемлекләре дә, ниһаять, игълан ителде. Әдәбият буенча озын исемлекләрдә берничә ел дәвамында исеме чагылгалап киткән бер автор бар иде. Әмма шулай да ул чын-чынлап җиңәргә мөмкин «уенчылар» арасында әллә ни каралмады. Шулай да быелгы Нобель – аныкы: мадьяр, ягъни венгр язучысы Ласло Краснохоркаи турында бара сүз. Аның эпик иҗатын кайбер әдәбият галимнәре «мадьяр эпикасы», «мадьяр меланхолиясе» дип бәяли.

КИНО ҺӘМ ӘДӘБИЯТ

Киң катлам сәнгать сөючеләргә аның исеме, бәлки, беренче чиратта әдип буларак билгеле дә түгелдер. Күпләр аны Венгрия һәм Европаның автор киносы, арт-хаус вәкиле, дөньякүләм танылган режиссёр Бела Тарр автордашы, аның атаклы фильмнарының сценарийларын язучы буларак белә, мөгаен. Әлеге фильмнар – күп кенә кинофестивальләрдә яңгыраган, интеллектуаль сәнгать тарафдарларын тетрәндергән тасмалар: «Проклятие», «Последний корабль», «Сатанинское танго», «Человек из Лондона», «Туринская лошадь» һ.б.

Бүгенге көндә Ласло Краснохоркаи рус теленә өч китабының тәрҗемәсе һәм «Иностранная литература», «Нёман» журналларында басылган кыска хикәяләре белән билгеле. Шулай ук «Сеанс» киноальманахында аның «Самое позднее – в Турине» эссесы дөнья күрде. «Иностранная литература» журналы 2013 елдагы май санында язучы белән Оксана Якименко

Фото: goodfon.ru, polyandria.ru, corpus.ru

эшләгән күләмле һәм гаять кызыклы әңгәмәне дә укучыларына тәкъдим итте. Ул чагында Оксана Якименко әңгәмәсен бик конкрет сораудан башлаган иде:

– Ни өчен сезне рус теленә тәрҗемә итмиләр?

– Моны сез миннән сорыйсызмы? - дип елмая Краснохоркаи. - Минем өчен бу – четерекле тема. Һәрвакыт уйлый идем: мине тәрҗемә итәр тел, иң беренче чиратта, рус теле диеп. Әгәр дә рус әдәбиятын укымаган булсам, беркайчан да яза башларга батырчылык итмәс идем. Кафкадан кала, мине язу эшенә килергә өндәгән язучылар – Толстой белән Достоевский. Алар булмаса, язарга башыма да килмәгән булыр иде. Беренче романымны («Сатанинское танго». – **Авт.**) аларның бик зур тәэсире нәтиҗәсендә иҗат иттем. Әйбәт буржуаз гаиләдә үскән яшүсмер, кинәт кенә, гыйсъянга бирелеп, атам йортын ташлап чыгып киттем. Нәкъ менә Достоевский каһарманнары кебек, тормышның иң төбенә төшеп карыйсым килде – анда чын дөреслек белән ихласлык яшеренеп ята булып тоелды чөнки. Чыннан да, ул вакытта әле тормышның бер читендә, коточкыч фәкыйрьлектә яшәп тә, иң асыл, «череклек» бозып таркатмаган сыйфатларны саклап яшәп яткан кешеләрне очрата ала идең... Мин терлек асрый торган фермада да җигелеп эшләдем, сыерлар да карадым, басуда да тир түктем, – нәрсә белән генә шөгыльләнмәдем... Унтугыз яшьтә, университеттан чыгып, армиягә бардым, аннан соң Венгрия буйлап йөрергә чыгып киттем...

Рус теленә тәрҗемә итмәүләре яхшыдыр да. Берлинда яшәгәндә, Сорокин дигән язучы белән таныштым, ул миннән ник тәрҗемәләрем булмавын төпченде. Мин көлдем: рус укучыларында «бик әйбәт венгр язучысы бар икән, әмма, тәрҗемәләре булмагач, аны укырга хыялланырга гына кала инде» дигән иллюзия калсын.

40 ТАН АРТЫК ТЕЛГӘ ТӘРҖЕМӘ ИТЕЛГӘН ӘДИП

Бүгенге көндә Краснохоркаины инде бөтенләй тәрҗемә ителмәгән дип әйтеп булмый. Китапларының икесе – «Сатанинское танго» белән «Меланхолия сопротивления» Corpus нәшриятында басылып чыкты, «Гомер навсегда» дигәне – Поляндриядә. Хәзерге вакытта Поляндрия аның «Возвращение барона Венкхейма» китабын әзерли, дип ишетеп беләбез.

Асылда, дөнья күләмендә аның исеме китап укучыларга бик яхшы билгеле, ул 40 тан артык телгә тәрҗемә ителгән автор. Моннан тыш, язучыны премияләр белән дә даими «иркәләп» кенә торалар: үзләрендә ул Аттила Йожеф, Тибор Дери, Дьюла Круди, Шандор Мараи исемендәге премияләр һәм Венгриянең Лайош Кошут исемендәге милли премиясе лауреаты. 2013 елда дөнья күләмендә «иң яхшы тәрҗемә ителгән китап» өчен бүләкләнде, 2015 елда Халыкара Букер премиясенә лаек дип табылды. Букер белән Нобель арасында – 10 ел.

2008 елдан Ласло Краснохоркаи Берлин университетына профессор буларак эшкә чакырыла. Ул вакытын нигездә язу эшенә һәм сәяхәтләргә багышлый. Краснохоркаи Монголия, Кытай, Японияне урап кайткан, Атлантиканы йөзеп чыккан, Европа белән АКШны гизгән кеше.

СЬЮЗЕН ЗОНТАГ ЛАСЛО КРАСНОХОРКАИНЫ «АПОКАЛИПСИСНЫҢ ВЕНГР МАСТЕРЫ» ДИП АТЫЙ, ЯЗУЧЫ ИҖАТЫН ГОГОЛЬ ҺӘМ МЕЛВИЛЛ КОЛАЧЫ БЕЛӘН ТИҢЛӘШТЕРӘ. КРАСНОХОРКАИНЫҢ ЯЗУ ӨСЛҮБЕН ЕШ КЫНА ГОГОЛЬНЕҢ «МЁРТВЫЕ ДУШИ» ӘСӘРЕ БЕЛӘН ДӘ ЧАГЫШТЫРАЛАР.

УТОПИЯ, АНТИУТОПИЯ ҺӘМ ЧЫНБАРЛЫК

Асылда Краснохоркаины интеллектуаль, элитар мохиткә нәкъ менә Тарр белән төшергән фильмнар һәм Зонтаг соклануы, канаты астына алуы таныта. Милан Кундера популярлыгы чорлары бераз сүлпәнәя төшеп килә, аны безнең мадьяр каһарманыбыз алыштыра. Краснохоркаи образы бу чорның таләпләре белән ымсынуларына да бик тәңгәл килеп тора: скептик һәм хакимияткә каршы бунтарь, ялгызак, аутсайдер, үз эчке фәлсәфәсе һәм зирәклегенә таянып яши торган аскет һәм визионер.

Аны күбрәк утопия һәм антиутопия вәкиле буларак күрсәтергә яраталар. Хәтта Википедия дә шундый бәяләмә бирелгән: «Краснохоркаи кешеләрнең бу дөньядагы яшәешен абсурд һәм гротеск дәрәҗәсенә җиткереп сурәтли, эчке дөнья белән тышкы дөнья арасындагы бәйләнешләрнең тулаем өзелүенә ишарә итә, шуңа да әсәрләре үзенә күрә бер утопик, антиутопик кыйссаларны хәтерләтә».



Әмма мин, киресенчә, Краснохоркаи әсәрләреннән безнең бүген инде логик аң белән ваемлап җиткерә алмый торган шаккаткыч чынбарлыгыбыз саркылып тора, дияр идем. Аның моңлы, сагышлы эпик «киндерләреннән» баш калкыткан каһарманнар үз гади, үтә гадәти генә зарлары белән кинәт миф образларына әверелеп киткәндәй тоела. Аларның тавышы мәңгелеккә барып бәрелә дә кире әйләнеп кайта, кайтаваз булып, тынгы тапмый, өзгәләнеп кайтарыла да кайтарыла...





«Минем күзләрем белән органикам шундый итеп яратылган инде: барысын да күрәм (хәтта күрергә ярамаганны да) һәм тән тирем белән, аңа нидер кабып, ялкынсынып киткән шикелле тоям, – ди Краснохоркаи. – Ахры, шуңа мин язучыдыр да инде».

КАСАЙ – ӨМЕТ УТЫ КАБЫНГАНДА...

КАСАЙ

Көннәр матур булганда дип, республикабызның иң ерак районнарының берсенә – Әгерҗегә юл алдык. Октябрь кояшының җылы нурларына сөенеп бара торгач, озын юлны сизми дә калдык.

Әгерҗе районында Иж-Бубый кебек танылган авыллар бар. Ә менә Касай авылын алай белүче юк. Югыйсә биредә дә бик борынгы, тарихлы бина сакланып калган. Аннан бигрәк Касай үзенең бердәмлеге, олы йөрәкле кешеләре белән сокландырды. Авылның бер үзенчәлеге – монда халык олы мичләрне сүтмәгән. Кайсы йортка керсәң дә, мич коймагы, башка камыр ашлары пешерәләр.

Руфия Фазылова

Фото: Лилиана Вәлитова

ФАҖИГАЛЕ ТАРИХ...

Касай – бер урамлы авыл. Биредә мәктәп тә, балалар бакчасы да, кибет тә юк, хәтта мәчет тә. Социаль объектлардан фәкать клуб кына бар. Җирле халык белән нәкъ шунда очраштык та. Без киләсен белеп, авыл апалары (хәер, арада берничә ир-ат та бар) клубка җыелган иде.

– Ярты авыл сезне көтә анда, – дип каршы алды безне Кадыбаш авыл җирлеге башлыгы Хәлил Закиров. Чынлап та шулай булып чыкты. Касайда илле алты кеше гомер кичерә, шуның нәкъ яртысы клубта иде. Нигездә, барысы да лаеклы ялдагы апалар, абыйлар.

– Без кунаклар бик яратабыз, Казаннан кадәр журналистлар килә дигәч сөенештек, – диде алар.

Клуб – авылның үзәге.

Авыл апалары безне көткән.

Апалар тезелешеп утырды. Һәркайсының үз язмышы, үз тарихы... Сүзне беренче булып шушы авылда туып-үскән Дания апа Фәтхиева алды:

– Мин Касайда туган бала, хәзер инде күрше Кадыбаш авылында яшим. Утыз сигез ел мәктәптә рус теле һәм әдәбияты укыттым. Шул исәптән Касай балаларына да, чөнки алар Кадыбаш урта мәктәбенә йөреп укыды. Бүген дә шулай. Туган авылым турында нәрсә дим... Мондагы кебек дус, тату, күңелле яшәүче авыллар тагын бармы икән? Касайның тарихын өйрәндем: биредә халык дини булган, чөнки 1849 елда авылга указлы мулла итеп Габделҗәббар Гобәйдуллинны җибәрәләр. Ул бик абруйлы, укымышлы кеше була. Аның исеме архив документларында берничә тапкыр телгә алына. Габделҗәббар хәзрәт Касайга килгәндә егерме дүрт яшендә була. Өйләнә, хатыны Фатыйха белән ун бала табалар. Ни аяныч, хатыны яшьли мәрхүм була, нәтиҗәдә, Габделҗәббар хәзрәт яңадан өйләнә. Бибизәйнәп белән яңадан алты балалары туа. Авыл халкы хәзрәтне бик ихтирам итә: ул кешеләргә аң-белем дә бирә, азык белән дә ярдәм итә. Революция вакытында да авыл кешеләре өчен бик зур яхшылыклар эшли, үзе аздан гына үлемнән кала. Габделҗәббар хәзрәт 80 яшендә бакыйлыкка күчә. Аның эшен беренче хатыныннан туган улы Габдулла дәвам итә. Ул авылда мәчет салдыра, 1934 елда күрше Кадыбаш авылына мәктәп эшләтә. 1986 елга кадәр менә шул бинада эшләдек. Аннан соң инде ике катлы заманча мәктәп бинасы салынды.

Габделҗәббарның улы Габдулла эшләткән мәчет бинасы Касайда сакланмаган. Совет хакимияте килгәч, башта аның манарасы юк ителә, тора-бара Аллаһ йорты үзе дә яраксыз хәлгә килә. Әмма ни хикмәт, шушы нәселнең балалары әле дә авылга ярдәм итә икән. Габделҗәббар Гобәйдуллинның бер оныгы Венера Хәйретдинова бүген Казан шәһәренең Лицей – инженерлык үзәген җитәкли. Касайда тумаса да, ата-бабаларының рухын зурлап, бирегә еш кайта. Касайлылар Венера Кәшфиевнага бик рәхмәтле, аны зур хөрмәт белән телгә алдылар.

– Ә менә клуб бинасы элеккеге зират урынында, – дип сүзгә кушылды Фәнирә апа Нәбиуллина. – 1921 елгы ачлык елларында авылда ятимнәр йорты ачыла. Мәрхүм булган балаларны шушы урынга күмәләр. Соңрак инде, 1980 нче елларда әлеге урынга клуб төзиләр. Хәтерлим, мәрхүм Шамил абый табылган сөякләрне зиратка алып барып күмеп йөрде. Авыл әнә шундый фаҗигаләр дә күрде, кызым. Ул сабыйлар кичерсен инде безне...

МӘҢГЕЛЕК ЙОРТ

Олы тарихлы Касай бүген утыз хуҗалыкка калган. Әле егерме-утыз ел элек тә авыл бермә-бер зуррак булган. Җирле халык моның сәбәбен колхоз таркалуда күрә. Авылда «Байрак» исемле колхоз 1931 елда оеша. 1937–1938 елларда инде колхоз алдынгылар рәтендә йөри, чөнки авылда халык бердәм һәм бик тырыш була.

– 1936 елда ашлык уңмый, илдә ачлык башлана, – дип истәлекләр белән бүлеште клубка җыелган апалар. – Касайда ярдәм көтеп тормыйлар. Колхоз рәисе Хөрмәт Гатауллин белән Гыйлаҗ Садыйков, ир-егетләрне, атларны җыеп, Сарапул аракы заводына эшкә китәләр. Нәтиҗәдә, авылдагы гаиләләр ачлык сизми, һәм колхоз үзе дә сакланып кала. 1937 елда тормыш җайлана башлый. Елына күрә яхшы уңыш җыела, һәм колхоз үзенең беренче йөк машинасын сатып ала. 150 йорт исәпләнгән Касайда тимерче алачыгы, пилорама һәм икмәк пешерү цехы барлыкка килә. Балалар бакчасы ачыла. Кыскасы, Бөек Ватан сугышына кадәр Касай аягында нык тора. Аннан инде сугыш башлана.

Шунысына игътибар иттек: авыл апалары тарихны яхшы белә. Бер-берсенә ярдәм итә-итә, колхоз рәисләренең исемнәрен дә искә төшерделәр, мәктәп укытучыларын да телгә алдылар. Күренеп тора: мондый сөйләшүләр беренче генә түгел.

– Моның кадәр тарих белән сезгә китап язарга кирәк, – дибез апаларга.

– Касайның тарихын өйрәндем: биредә халык дини булган, – ди Дания Фәтхиева.

1886 елда сәүдәгәрләр Габделсәгыйрь һәм Мәхмүт Бәшәровлар салдырган йорт.



– Яздылар инде, тиздән авылыбыз турында китап дөнья күрергә тиеш...

Клуб янәшәсендә ике катлы таш бина бар. Аның үзенчәлекле, тарихи бина булуын еракган ук чамаларга була. 1886 елда сәүдәгәрләр Габделсәгыйрь һәм Мәхмүт Бәшәровлар салдырган йорт икән бу. 200 еллык бина үз тарихында ниләр генә күрмәгән: кибет, медпункт, башлангыч мәктәп тә булган. Хәзер исә аның бер бүлмәсе гыйбадәтханә урынына хезмәт итә – Гает бәйрәмнәрендә авылдашлар бирегә җыела икән.

– Әлеге йорт авылыбызның йөзек кашы, – дип сөйләде Касай клубы җитәкчесе Гөлназ Шәрәфиева. – Абыйлы-энеле Бәшәровлар бик хәлле, укымышлы кешеләр булган. Үз акчаларына мәдрәсә салдырганнар. Авыл кешеләренә даими ярдәм итеп торганнар. Бәшәровлар, тире җыеп, шуны эшкәртү белән шөгыльләнгәннәр. Бу йортны эшләтергә осталарны Сарапулдан ук чакыртканнар. Ул шулкадәр нык бина: измәсенә йомырка сарысы кушып төзегәннәр. Уйлап карагыз әле: стеналарның калынлыгы бер метрдан артык! Без аны мәңгелек йорт, дип атап йөртәбез.

1930 нчы елларда, илдә барган сәяси вакыйгалар аркасында, Бәшәровлар авылдан чыгып качарга мәҗбүр була. Ни аяныч, сөргендә Касай сәүдәгәрләре озак яшәми, мәрхүм була. Дөрес, соңрак, дөньялар үзгәргәч, Габделсәгыйрьнең улы Касайга кайта. Әлеге таш йорт тирәсендә озак кына уйланып йөри, бабаларының каберенә бара. Кызганыч, атаклы нәселнең дәвамчылары белән ара өзелә. Данлы нәселнең бердәнбер шаһиты булып әлеге йорт тора.

ҺӘР ГАИЛӘ ҮЗЕНЧӘ БӘХЕТЛЕ...

Касайда беренче башлангыч мәктәп 1918 елда эшли башлый. Әмма укучылар саны азаю сәбәпле, 2008 елда мәктәп ябыла. Касайның өч баласы хәзер Кадыбаш урта мәктәбендә белем ала. Шул исәптән Закировларның төпчекләре Зәлинә дә. Гаиләдә өч буын бергә яши: 70 яшькә җиткән Мөнзилә апа белән Рәхимҗан абый, аларның уллары Ришат белән киленнәре Айгөл. Аларның ике уллары төп йорттан чыгып киткән, берсе Ижевскида, берсе Казанда яши.

– Без инде үзебез дәү әни, дәү әти, – дип елмайды Ришат. – Ике оныгыбыз бар. Айгөл Кадыбаш ФАПында фельдшер ярдәмчесе булып эшли, мин исә газчы, авылдашларга хезмәт күрсәтәм.

Закировлар күп итеп мал, кош-корт асрый. Яшелчә бакчалары бик зур. Җәе буе шуннан кереп тормыйлар. Мөнзилә апа балаларының төп ярдәмчесе икән, ә менә Рәхимҗан абый инсульт кичергән, күбрәк ятып тора.

– Мин аш-су бүлмәсенә хуҗа, – диде Мөнзилә апа. – Балалар тышта эшли. Оныкларны да бергә үстердек. Кияүгә чыкканда Айгөлгә

Өч буын бергә яшәүче Закировлар.

унсигез тулган гына иде, бездә үсте дисәм дә була. Авылдан китәбез, димәделәр, рәхмәт яусын.

Бу гаиләнең хатын-кызлары аш-суга оста икән. Бик тәмле итеп бавырсак пешерәләр, заказга да эшлиләр. Кыскасы, тиктормас, эш сөючән кешеләр.

Касайның тагын бер хөрмәтле гаиләсе белән таныштык – Земфира һәм Илһам Әхмәтҗановлар. Гаилә башлыгы озак еллар колхозда механизатор булып эшләгән, хәзер инде лаеклы ялда. Земфира апа исә егерме елга якын социаль хезмәткәр булып эшли, гади итеп әйткәндә, ялгыз әбиләрне карый. Йорт-җирләре көләп тора, ник бер артык нәрсә аунап ятсын!

Әхмәтҗановлар ике ул үстергән. Төпчеге – Динар менә инде өч ел махсус хәрби операция зонасында икән. Нәкъ без барган вакытта ялга кайткан иде. Сөйкемле, зифа буйлы бу егет белән дә аралашып алдык. Сер бирмәде ул: барысы да яхшы, диде. Елмаеп кына тора. Илһам абый улы кайтканчы дип, ишегалдына беседка ясап куйган. Шунда самовар куеп чәй эчәләр икән. Земфира апа улын көн саен тәмле камыр ризыклары белән сыйлый.

– Аллаһы Тәгаләдән көн саен балама саулык, озын гомер сорыйм, – диде ана кеше. – Хәере белән дөньялар тынычлансын да, улыбыз, башка егетләребез дә сау-сәламәт туган җирләренә әйләнеп кайтсын.

Амин... Барыбыз да шушы теләктә без.

«ӨЙЛӘНДЕМ, КИЧЕРЕГЕЗ»

Революциягә кадәр Касайда бер меңгә якын кеше яшәгән. Авыл һөнәрчелек белән дан тоткан. Итекчеләр, атаклы балта осталары, мич салучылар күп булган. Иң кадерлесе – аларның эшләре әле дә авылда сакланган.

Мич турында аерым язасы килә, чөнки бүген авылларда бу бик сирәк күренеш. Ә Касайда һәр ике йортның берсендә олы мич сакланып калган.

– Менә бусы Хәбибрахман абый Гәрәев салган мич, – диде Сабит Шакиров. – Хәбибрахман абыйның мич чыгарганын бик кызыксынып карап тордым, ул чакта дүртенче сыйныфта укый идем. Шуның җылысында үскән буын без. Һәм хәзер дә сафта ул: атнага бер ягыла. Җәмәгатем коймак, шәңгә перерә. Мичебез дә үзебез белән бергә картайды.

88 яшен тутырган Фәнирә апа Нәбиуллина да гомер буе мичле өйдә яшәгән. Иренмичә хәтта мичтә коймак та пешереп күрсәтте. Дөресрәге, килене Нурия апа камыр куйды, Фәнирә апа пешерде. Ул коймакның тәме әле дә тел очында тора... Әниле-кызлы кебек яшәүче бу хатын-кызларны күреп ис китте! Бер-берсенә булган мөнәсәбәтләре, уңганлыкларына күз тимәсен.

Әхмәтҗановларның йорт-җирләре көләп тора.

Сабит Шакиров: «Мич җылысында үскән буын без».

Фәнирә апаның язмышы турында әсәр язмалы. Әтисе сугышта исән калып та, ятим үскән бала ул. Аның тарихын Фәнирә апа болай дип сөйләде:

– 1937 елда Касайда туганмын. Әти сугышка киткәндә дүрт яшьтә булганмын. Башлангыч сыйныфларны Касай мәктәбендә укыдым, ә менә бишенчегә Кадыбаш мәктәбенә киттем. Анда бер классны өч ел укырга туры килде, чөнки кар төшү белән, әни өйгә алып кайтып китә. Ни өчен дигәндә, урманнан чана белән утын ташыйсы бар. Өйдә ир кеше булмагач, бөтен эшне үзебезгә башкарырга туры килде. Җиде классны барыбер тәмамладым инде. Сигезенчегә Исәнбай мәктәбенә бардым. 1953 ел иде ул. Әмма бер чирек укыгач, кайтып киттем, чөнки акча түләргә куштылар. Сугышта этиләре үлгән балалар бушка укый, ә минеке хәбәрсез югалды. Кулыбызда бер документ та юк. Шулай итеп, үзебезнең «Байрак» колхозына эшкә кердем, бухгалтериядә табельләр тутырып тордым. Аннары күрше егетенә кияүгә чыктым, өч бала үстердек. Бабай белән егерме сигез ел гына яшәп калдык. Ике улым да яшьли мәрхүм булды, кызым исә гаиләсе белән яши. Әле бәхетемә киленем Нурия булган, аның белән сүзсез дә аңлашабыз...

Сугыш беткәннән соң Фәнирә апаның этисе исән икәнлеге ачыклана. Әнисе район кешеләре аша ирен эзләтә. Нәтиҗәдә, Кыргызстанда яши, өйләнгән, ике баласы бар, дигән хәбәр алалар. Күрсәтелгән адрес буенча Кыргызстанга хат язалар. Аеруча Фәнирә апаның әбисе (әтисенең әнисе) каты тора: «Улым, ничек инде исән булып та туган ягыңа бер кайтып килмисең? Без бит монда күпме күз яше түктек. Әгәр үзең кайтмасаң, судка бирәм...» Озакламый югалган солдаттан җавап хаты килә: «Кичерә күрегез мине... Шулай килеп чыкты. Зинһар, судка бирмәгез. Исән булсам, ничек тә кайтып күрермен. Сугышта каты яраландым мин, бер күзсез калдым. Аннан соң хезмәт армиясендә булдым, комбайнда эшләдем. Шуннан инде өйләндем. Ачу сакламагыз, кичерегез...»

– Әти үлгәч, сеңлем әби белән Кыргызстанга барды, – диде Фәнирә апа. – Әби этине кичерде бугай. Хәер, әни дә үпкә сакламады кебек, эти турында ялгыш кына да начар сүз әйткәне булмады. Әни каенанасы белән утыз ел бергә яшәде, бик хөрмәтләп соңгы юлга озатты. Әни үзе 92 яшенә җитте.

...Менә шундый язмышлар. Әлбәттә, олы тарихлы авылның бетеп баруы бик начар. Ләкин киләчәккә өмет уты бар әле: Касайда 6000 баш сыерга исәпләнгән зур ферма төзелергә тиеш. Инде эшләр башланган. Ә бу инде яңа эш урыннары, авыл җанлану дигән сүз. Шулай булгач, өметне җуймыйк.

Әниле-кызлы кебек яшәүче Фәнирә һәм Нурия Нәбиуллиналар.

ТАРИХ БИТЛӘРЕННӘН

– Төрле вакыттагы документларда авылның исеме аерыла. Инкыйлабка кадәрге чыганакларда ул «Көек», «Илморза», «Иске Тогуз» исемнәре белән телгә алына. Соңрак Көек Ишморза, Косово, Косаев, Косаева, Косаел һәм Касаево (Касай) вариантларын очратырга мөмкин.

Гипотезаларның берсе буенча, Касай исеме Касыйм исеме белән бәйле. Касай – гарәп исеменең диалект варианты, ул сүзгә-сүз – «бүлүче, билгеләүче, таратучы», ә күчерелмә мәгънәдә «юмарт» дигәнне аңлата. Икенче гипотеза буенча, Кисай – татар морзаларының ыру исеме. Чыгышлары морза булган кешеләрдә Кисай, Кисаев фамилиясе хәзерге вакытта да Кырым татарларында очрый. Авылның берничә тапкыр янып бетүе турындагы риваять тә игътибарга лаек. «Янган утын» сүзе татарча «кисәү» дигәнне аңлата. «Кисәү авылы» дигән атама шуннан килеп чыккан һәм акрынлап Касайга әйләнгән дигән фараз да бар.

Авыл Илморза елгасы буенда урнашкан. Халкы татарлар, тик алар өч катлауга карый: типтәрләр, башкорт вотчинниклары һәм башкорт дәүләт крестьяннары. Бу җирлек турында иң кызыклы һәм киңәйтелеп әйтелгән фикерләрнең берсе 1892 елда төзелгән Сарапул өязенең Хуҗалык исемлегендә очрый. Бу документ нигезендә Касай 1785 елда Куян авылыннан – башкортлар һәм типтәрләр, Көчек авылыннан кайчандыр казак-татар гаскәренә караган дәүләт крестьяннары күчеп килгәч төзелгән, дип барыла. Шул ук вакытта Р. Мәрданов һәм И. Һадиевның Әгерҗе төбәге тарихы турындагы китабында 1622 елгы Җир грамотасында, ә аннары 1702 елгы грамотада Касай турында мәгълүмат бар, дип искә алына. Шулай итеп, авылның дүрт гасырдан артык тарихы бар, дип уйларга мөмкин.

«Касай тарихы» китабыннан



ЙОСЫПОВЛАР. ГАСЫРЛАР АША КИЛГӘН ЗИННӘТ (0+)

Казанга Россиянең иң кыйммәтле сынлы сәнгать коллекцияләренең берсе килде. Ул кайчандыр князь Йосыповларныкы булган. «Эрмитаж-Казан» үзәгендә тәкъдим ителгән күргәзмәдә антик чордан алып XX гасыр башына кадәрге 400 сәнгать әсәре катнаша. Экспозициядә – Көнбатыш Европа һәм рус сынлы сәнгате, графика, скульптура, гамәли сәнгать әсәрләре... Биредә Тьеполо, Риччи, Верне, Буше, Ланкре, Робер, Кече Тенирсны һәм XVII–XIX гасырларның танылган рәссамнарының эшләрен, шулай ук Йосыповларның портретлар галереясын, княгиняның гардеробы предметларын, зәркән эшләнмәләрен һәм морзаларның башка шәхси әйберләрен күреп булачак. Күргәзмәдә XVIII–XIX гасырлардагы рус аксөякләре атмосферасын тоясың.

17 октябрьдән. Көн саен 10:00 дән 18:00 гә кадәр (җомга көнне – 11:00 дән 20:00 гә кадәр)
Дүшәмбе – ял көне «Эрмитаж-Казан» үзәге, 3 нче кат; «Казан Кремле» музей-тыюлыгы.

АЛТЫН УРДАГА СӘЯХӘТ (0+)

XIV гасырдагы Алтын Урда шәһәренә «барып кайтасыгыз», анда яшәүчеләренең көнкүреше һәм үзенчәлекле архитектурасы белән танышасыгыз, сәүдә элемтәләре һәм акча сугу эшчәнлеге турында беләсегез килсә, «Мухшы Олысы. Алтын Урда патшалыгының олыс шәһәре данлыклы булган...» күргәзмәсенә килегез. Күргәзмәдәге раритетлар алты гасыр элек булган чорга карый. Алар борынгы Наровчат (Наручат) шәһәре урнашкан урында табылган, элек бу шәһәр «Мохши, яки Нуриҗан» исеме белән билгеле булган. Бүген ул – археологик мирасның уникаль объекты, федераль дәрәҗәдәге тарих һәм мәдәният ядкәре.

Көн саен 10:00 дән 18:00 гә кадәр
(җомга көнне – 11:00 дән 20:00 гә кадәр)
Дүшәмбе – ял көне
Татарстан Республикасы һәм татар халкы дәүләтчелеге тарихы музее, «Казан Кремле» музей-тыюлыгы.

ЧУЛПАН ИСЕМЛЕ ЙОЛДЫЗ (12+)

Хыяллар канат куя, диләр. Яшь төзүче Хәйдәр авылдан Казанга килә, ул хыялдагы йолдызына таба очарга да әзер, чөнки кечкенәдән галәмгә очарга омтыла торган була. Әмма бервакыт шәһәр ыгы-зыгысы уртасында ул Мәскәү рәссамы Чулпанны очрата. Шул мизгелдә аның күккә ашкан хыяллары җирдәге мәхәббәткә әверелә. «Хыял артыннан» – дуслык, ихлас хисләр һәм хыялның тормышны хәрәкәткә китерә торган көчкә әйләнүе турындагы музыкаль спектакль. Сәхнәдә 60 нчы еллар атмосферасы җанлана: дәртле биюләр, җырлар, юмор һәм дулкынландыргыч драматик мизгелләр.

22 октябрь, 18:30; 23 октябрь, 18:30; 24 октябрь, 18:30
Зур зал. К. Тинчурин исем.
Татар дәүләт драма һәм комедия театры
Казан, Татарстан ур., 1

афиша

Фото: kazan-kremlin.ru, tinchurinteatr.ru, tatfil.ru, kamalteatr.ru

ХАЛЫКЧАН СТИЛЬДӘГЕ ДЕФИЛЕ (0+)

XIX гасырның икенче яртысы – XX гасырда татарлар, руслар, марилар, мордвалар, удмуртлар, чувашлар ничек киенгән? Моны «Казанның Идел буе: халык мәдәнияте образлары» күргәзмәсендә күреп була. Костюмнар музейларда, шәхси коллекцияләрдә сакланып калган үрнәкләрне җентекләп өйрәнгән осталар тарафыннан эшләнгән. Проектта Идел буе төбәкләренең төрле дәрәҗәдәге 100 дән артык музее, галимнәр, тикшеренүчеләр, культурологлар катнашкан. Экспозициядә киемсалым, бизәнү әйберләре, аксессуарлардан тыш, Идел буе халыкларының шул чордагы музыка уен кораллары һәм көнкүреш әйберләре тәкъдим ителә.

Көн саен 10:00 дән 18:00 гә кадәр
(җомга көнне – 11:00 дән 20:00 гә кадәр)
Дүшәмбе – ял көне.
Кабул итү урыннары Күргәзмә заллары. «Казан Кремле» музей-тыюлыгы



МИЛЛИ МОҢНАР (6+)

Матур костюмнар, дәртле биюләр, күңелгә үтеп керә торган халык көйләре... Айдар Фәйзрахманов җитәкчелегендәге ТР Дәүләт фольклор музыкасы ансамбле тарафыннан әзерләнгән яңа концерт программасы берәүне дә битараф калдырмый. Ансамбль үзе музыка өлкәсендәге уникаль күренеш булып тора – коллективның барлык әгъзалары профессиональ дәрәҗәдә җырлый, бии, берничә уен коралында уйный. Аларның кулларында гармун, курай, кубыз һәм гөслә, саз, думбра, ятаган, җәя кебек борынгы уен кораллары да гаҗәеп моңлы яңгырый. Бик тәфсилләп тупланган һәм җентекләп өйрәнелгән фольклорны, бай музыкаль мирасны ансамбль халыкка мавыктыргыч тамаша рәвешендә тәкъдим итә.

6 декабрь, 18:00
Г. Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясе
Казан, Павлюхин ур., 73

МАЙЯ ПЛИСЕЦКАЯНЫҢ АК МАГИЯСЕ (0+)

XX гасырның бөек балеринасы узган һөнәри юл – ул үз-үзеңне җиңеп, алга бару һәм новаторлык тарихы, анда классик традиция куәтле индивидуальлек белән кушыла, ә бию эчке ирек теленә әйләнә. Бахрушинский театры музее фондларыннан тупланган күргәзмә балет легендасының иҗади мирасы белән танышырга чакыра. Экспозициянең алты бүлеге 200 дән артыграк экспонатны үз эченә ала: фотографияләр, костюмнар, декоратив-гамәли сәнгать предметлары, Майя Плисецкаяның сынлы сәнгатьтәге һәм скульптурадагы портретлары, шулай ук уникаль архив материаллары. «Майя Плисецкаяга багышланган күргәзмәнең Кабул итү урыннарындагы Күргәзмә залларында ачылуы – безнең өчен генә түгел, бөтен Казанның мәдәни тормышы өчен аерым бер игътибарга лаек мәдәни вакыйга. Бөек балерина, көч, грация һәм эчке хөрлек символы сәхнә чикләренә генә сыймый торган мирас калдырып китте. Бахрушинский театры музее белән хезмәттәшлек нәтиҗәсендә, безнең бүген шушы мираска кагылу мөмкинлеге бар», – ди «Казан Кремле» музей-тыюлыгы директоры Илнур Рәхимов.

15 октябрьгә кадәр. Көн саен 10:00 дән 18:00 гә кадәр
(җомга көнне – 11:00 дән 20:00 гә кадәр)
Дүшәмбе – ял көне
Кабул итү урыннары Күргәзмә заллары. «Казан Кремле» музей-тыюлыгы

ТАГЫН БЕР КАТ МӘХӘББӘТ ХАКЫНДА (16+)

Ир-ат белән хатын-кыз арасындагы мәхәббәт нәрсә ул? Мәхәббәт гөнаһта яши аламы? Шушы гади һәм катлаулы сораулар Илгиз Зәйниев куйган «Сөяркә» спектаклендә күтәрелә. Театр күренекле татар драматургы Туфан Миңнуллинның иң гадәти булмаган пьесасына мөрәҗәгать итәргә булган. Пьесаны беренче тапкыр Марсель Сәлимҗанов Камал сәхнәсендә 1996 елда куйган иде. Мәхәббәт һәм тәкъвалык каршылыгы ул вакытта ук тамашачылар каршына күп сораулар куйды, алар бүген дә җавапсыз кала. Димәк, премьера!

18, 19 октябрь, 11 сәг.
Көнчыгыш зал. Г. Камал исем. Татар дәүләт Академия театры
Казан, һ. Такташ ур., 4

Башкалабыз Казанда сакланып калган, тарихлары милли мәдәниятебезнең асыл затлары белән бәйле агач йортлар белән таныштыруны дәвам итәбез. «Казанның агач йортлары» проектын «Татарстан» журналы «Татар ядкәрләре» шәхси оешмасы белән берлектә эшли.

Фото: Александр Ефремов

БИСТӘ БИЗӘГЕ: ИСӘНБАЕВЛАР ЙОРТЫ

Луиза Янсуар, Фәнзилә Җәүһәрова

Иске Татар бистәсендәге матур агач корылмаларның тагын берсе — Каюм Насыйри урамы, 33 адресы буенча урнашкан Исәнбаевлар йорты.



МӨӘЗИННӘР МИХРАБЫ

XIX гасыр ахырында төзелгән бу тарихи йорт 1856 елдан күрше Апанай мәчете мөәзине Мостафа Исәнбаевка карый. 1889 елда биләмәне аның улы, шулай ук азанчы Ибраһим мирас итеп ала.

Халык төзелеш сәнгате традицияләрен саклап салынган йортның өске каты – агачтан, хуҗалык хезмәтләрен башкару өчен булган ярымподвал өлеше кирпечтән салынган.

Йорт үзе турыпочмаклы, яны белән урамның кызыл сызыгына ук чыга. Урам ягында өч тәрәзәсе бар, аскы катның түбән тәрәзәләре бизәлмәгән. Төп торак йортның тәрәзәләре, кәрнизе, мезониндагы кечкенә тәрәзәләре купшы итеп бизәлгән, диварлары, почмаклары тар такта белән «чыршылап» тышланган.

ЯҢАРГАННАН СОҢ...

Бу йорт рәссам Рушан Шәмсетдинов исеме белән дә бәйле. «Мин шушы йортта тудым, шушында үстем, хәзер дә биредә яшим, эшлим. Безгә бигрәк тә җәй айларында күп кенә туристлар килә, барысын да кабул итәбез, чәйләр эчерәбез», – ди ул.

Совет заманында бу йортта барлыгы 12 гаилә яшәгән. Хәтта ишегалдындагы мунчага да бер гаиләне кертүләрен искә ала Рушан әфәнде.

2012–2013 елларда бинада Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов карары нигезендә реставрация эшләре уздырыла. Яңартудан соң, элеккеге соры тондагы буяулар ачык яшел, кызыл төсләргә алмаштырыла.

Биредә хәзер кечкенә генә көнкүреш музее урнашкан. Бина төбәк әһәмиятендәге мәдәни мирас объекты исәпләнә.





«ТАТАРСТАН» ЖУРНАЛЫН САТЫП АЛЫРГА

ozon.ru

market.yandex.ru

tatmedia.shop/ru

«ТАТАРСТАН» ЖУРНАЛЫНДА РЕКЛАМА БИРЕРГӘ

Рәссам Л. Гамбургер эше. 1925 ел

«Татарстан» журналының реклама бүлеге:

тел.: (843) 222-09-79, 8-9600-487-900, 8-9033-132-741

«ТАТАРСТАН» ЖУРНАЛЫ ЯҢАЛЫКЛАРЫН УКЫРГА

protatarstan.ru

t.me/pro_tatarstan

vk.com/protatarstann

Реклама 16+